МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ФЕДЕРАЛЬНОЕ АГЕНТСТВО ПО ОБРАЗОВАНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ВЫСШЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«Тобольская государственная социально-педагогическая академия
им. Д.И.Менделеева»

Филологический факультет

Кафедра татарского языка, литературы и методик преподавания

**К.С.САДЫКОВ, Ф.С. САЙФУЛИНА, М.С.ХАСАНОВА**

# СБОРНИК ПРОГРАММ И МЕТОДИЧЕСКИХ ПОСОБИЙ ДЛЯ ШКОЛ ТЮМЕНСКОГО РЕГИОНА С ЭТНОКУЛЬТУРНЫМ КОМПОНЕНТОМ ОБРАЗОВАНИЯ

**Работа выполнена в рамках гранта
департамента образования и науки Тюменской области на тему:
«ПОВЫШЕНИЕ КАЧЕСТВА ЭТНОКУЛЬТУРНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
В УСЛОВИЯХ ПОЛИКУЛЬТУРНОЙ СРЕДЫ ТЮМЕНСКОЙ
ОБЛАСТИ»**

**ТОБОЛЬСК 2009**

## СОДЕРЖАНИЕ

ПРОГРАММА ПО РОДНОМУ (ТАТАРСКОМУ) ЯЗЫКУ И ЛИТЕРАТУРЕ ДЛЯ ШКОЛ ТЮМЕНСКОГО РЕГИОНА С ЭТНОКУЛЬТУРНЫМ КОМПОНЕНТОМ ОБРАЗОВАНИЯ 3

ПРОГРАММА ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ 3

ПРОГРАММА ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ 26

ОЦЕНКА ЗНАНИЙ УЧАЩИХСЯ 5-11 КЛАССОВ ПО РОДНОМУ ЯЗЫКУ И ЛИТЕРАТУРЕ ......................................................................................62

СБОРНИК ПРАВИЛ ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ 69

УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКОЕ ПОСОБИЕ “ЛИТЕРАТУРНОЕ КРАЕВЕДЕНИЕ 101

УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКОЕ ПОСОБИЕ “ТАТАРСКОЕ УСТНОЕ НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО” 155

**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**
**ФЕДЕРАЛЬНОЕ АГЕНТСТВО ПО ОБРАЗОВАНИЮ**
**ГОСУДАРСТВЕННОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**ВЫСШЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**
«Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И.Менделеева»

Филологический факультет

Кафедра татарского языка, литературы и методик преподавания



**К.С. САДЫКОВ, Ф.С. САЙФУЛИНА, М.С. ХАСАНОВА**

# ПРОГРАММА ПО РОДНОМУ (ТАТАРСКОМУ) ЯЗЫКУ И ЛИТЕРАТУРЕ ДЛЯ ШКОЛ ТЮМЕНСКОГО РЕГИОНА С ЭТНОКУЛЬТУРНЫМ КОМПОНЕНТОМ ОБРАЗОВАНИЯ

**ТОБОЛЬСК 2009**

УДК 37.022
ББК 73.268.3(2Р632.2)
С 14

Утверждено на заседании кафедры
татарского языка, литературы и МП
«25» сентября 2009 г.

Программа предназначена для учителей родного (татарского) языка и литературы средних общеобразовательных и основных школ Тюменского региона с этнокультурным компонентом образования / составители К.С.Садыков, Ф.С.Сайфулина, М.С. Хасанова. – Тобольск: Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева, 2009.

**Составители:**
**К.С.Садыков,** кандидат педагогических наук, доцент
**Ф.С. Сайфулина,** доктор филологических наук, доцент
**М.С.Хасанова**, кандидат филологических наук, доцент

**Рецензенты:**
**Т.Н.Галиуллин,** доктор филологических наук, профессор
Казанского государственного университета им.Ульянова (Ленина)
**А.Ш.Юсупова,** доктор филологических наук, доцент
Казанского государственного университета им. Ульянова (Ленина)

© Садыков К.С., Сайфулина Ф.С., Хасанова М.С., 2009
© Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева

**ТОБОЛЬСК 2009**

# ПОЯСНИТЕЛЬНАЯ ЗАПИСКА

Родной (татарский) язык и литература являются составной частью многонациональной культуры Тюменского региона и в системе образования области занимают особое место, потому как сибирские татары – носители данной культуры по численности занимают второе место после русских и являются коренным народом Западной Сибири. Преподавание родного языка и литературы осуществляется на основе Конституции, Законов РФ «Об образовании», «О национально-культурной автономии» и Закона Тюменской области «Об основах функционирования образовательной системы в Тюменской области».

Формирование личности средствами родного языка предопределяет формирование культуры ученика. При этом важным аспектом является формирование культуры жить в многонациональном регионе и стране. Изучение родного языка и литературы является важным фактором не только сохранения единого образовательного пространства, но и гармонизации межнациональных отношений.

В условиях современного полиэтничного общества роль языка и языкового образования трудно переоценить. Язык воспринимается не только как средство общения и интерпретации действительности, но и как выразитель национальной и этнической идентичности, языковое поведение становится составной частью и индикатором социального потенциала личности, уровня ее культуры, средством социализации личности в обществе. Ведущая роль при этом принадлежит родному языку. Несомненно, «владение родным языком, умение общаться, добиваться успеха в процессе коммуникации являются теми характеристиками личности, которые во многом определяют достижения человека практически во всех областях жизни, способствуют его социальной адаптации к изменяющимся условиям современного мира»[1].

***Содержание*** обучения родному (татарскому) языку и литературе в школах Тюменского региона включает следующие компоненты:

* общие сведения о языке и литературе;

* знание системы языка, особенностей ее функционирования;

* знания, связанные с отражением в истории языка, литературе культуры народа;

* умения и навыки в различных видах речевой деятельности, культурно-речевые умения и навыки;

* аспекты, связанные с духовной культурой и историей народа.

**Задачами** обучения родному языку являются:

- формирование национального самосознания, уважение к родному языку, осознание красоты, выразительности, эстетических возможностей родной речи;

---

[1] Примерная программа основного общего образования по русскому языку для образовательных учреждений с русским языком обучения // ЕГЭ 2009. Русский язык. ГИА.ЕГЭ. Нормы оценки знаний. / Авт.-сост. А.Ю. Бисеров. М.: Эксмо, 2009. 336с.

- формирование языковой компетенции, предполагающей знание самого языка, его устройства и функционирования, языковых норм;
- развитие способности речевого самосовершенствования;
- формирование способности анализировать и оценивать различные языковые явления в текстах разных функциональных стилей литературного языка;

Диалекты сибирских татар, территориально отдаленные от среднего и западного диалектов, в становлении и развитии норм татарского национального литературного языка активного участия не принимали. Литературный татарский язык, сформированный без учета особенностей диалектов сибирских татар, отличается от языка татар-аборигенов Западной Сибири фонетически, лексически и морфологически. Более того, Тюменская область является полиэтничным регионом, территорией смешанного типа с точки зрения современного этнического состава и культуры. В результате длительных межэтнических, территориально-хозяйственных, культурных и языковых контактов на территории Тюменской области сформировался полилингвизм с явным доминированием русского языка. Под влиянием русского языка оказались все национальные языки региона, в том числе и язык сибирских татар, являющихся коренными насельниками. По мнению составителей программы, важный фактор повышения эффективности обучения родному языку в полилингвальной среде – умелое сочетание традиционного системного и функционально-коммуникативного подхода к изучаемым языковым и речевым единицам с учетом региональных речевых и культурных особенностей и сопоставительного анализа грамматической системы, взаимовлияния контактирующих русского и татарского языков. Задачи оптимизации языкового образования в широком смысле и прогнозирования влияния русского языка на родную речь учащихся-татар должны быть в центре методической мысли учителей родного языка Тюменского региона.

Региональная программа по родному (татарскому) языку составлена на основе “Программы по татарскому языку для татарской средней общеобразовательной школы. 5-11 классы”, утвержденной Министерством образования Республики Татарстан (Казань: Мәгариф, 2003). Авторы-составители сочли необходимым к расположению основного материала в программе применить системно-структурный подход, который обычно реализуется в программах по татарскому языку для татарских школ.

Особенностью настоящей программы является ее ориентация на интенсивное речевое развитие учащихся. Усиленное внимание к речевому аспекту в изучении родного языка определяет и оригинальную структуру данной программы: в ней не только представлена система понятий, подлежащих изучению, но с учетом психологических и педагогических показателей детей выделены темы для развития коммуникативных способностей учащихся. Программа реализует культуроведческий аспект в обучении родному языку, что предполагает достаточно широкое использование сведений по истории языка, включении сведений о татарских ученых-лингвистах, материалов по этимологии, истории региона и др.

**Художественная литература** составляет веками накопленную по зернышкам умственную и духовную сокровищницу народа. Конечно, духовное богатство не ограничивается словесным искусством. Составляющий строительный материал литературных произведений – язык сам напоминает безграничное море. Только количество одних слов в нем доходит до ста тысяч. Духовное сокровище народа многогранно. Оно отражено в фольклоре: пословицах и поговорках, песнях и лиро-эпике (баитах), обрядах, обычаях и традициях, поведенческих принципах, исторических преданиях, сценическом и прикладном искусстве, ювелирном мастерстве, народной философии и др.

Задачами обучения татарской литературе являются:
- формирование системных знаний по истории татарской литературы, в том числе региональной литературы;
- знание основных текстов художественных произведений татарской литературы;
- формировать умения использования теоретических знаний в практической деятельности: анализировать художественные тексты, выделить особенности творчества того или иного писателя;
- владеть навыками раскрытия важнейших идейно-эстетических концепций литературы разных периодов; анализа системы образов, сюжетных линий, выявления темы, проблемы, выделения основной идеи, сюжетно-композиционных особенностей, определения жанровой характеристики литературно-художественных произведений.

В программу отобраны лучшие образцы устного народного творчества, произведения поэтов и прозаиков татарского народа. Программа основана на историко-эстетическом принципе. В каждом классе, прежде всего, изучаются образцы произведений фольклора, объясняется их поэтико-философское значение, рекомендуется сохранить в памяти произведения устного народного творчества, записывать их, прививается интерес к ним.

Затем рассматриваются литературные произведения, связанные с фольклором. К ним примыкают в исторически-хронологическом порядке произведения, отражающие различные стороны жизни народа. Этот принцип является основным для 5 класса: в учебник-хрестоматию, открывшийся образцами устного народного творчества, включено больше произведений, связанных с фольклором. С этой точки зрения его можно назвать учебником-хрестоматией, раскрывающей связь фольклора с литературой, как введение в курс литературы в среднем звене.

В этом курсе (V-VIII классы) изучение творчества видных писателей углубляется из года в год. При переходе в старшие классы включаются все новые их произведения. Каждая новая ступенька освежает память учащихся, протягивает нити связи и, таким образом, стремится создать целостный взгляд на творчество писателей.

Вместе с тем в среднем звене задачей является ознакомление с как можно большим количеством писателей. Даются произведения до сих пор незнакомых

учащимся новых (в том числе региональных) писателей. В их расположении есть внутренняя логика, в определенной степени тематическая и жанровая последовательность. Учитель может при необходимости включить в список другие художественно совершенные литературные произведения, или заменить другими. Он может также изменить количество часов на изучение той или иной темы – увеличить или уменьшить. Но это должно найти отражение в тематическом плане, утвержденном методической комиссией или районным отделом (комитетом) образования перед началом учебного года или четверти.

Предлагаются следующие виды работ над художественными текстами:

1) подробное изучение текста (чтение и анализ);

2) общее рассмотрение (чтение и обмен мнениями);

3) самостоятельное изучение (внеклассное чтение).

Произведения первого вида изучаются и анализируются под руководством учителя. При изучении других – более активны самостоятельные действия учащихся. Третьи осваиваются учащимися самостоятельно. Но во всех трех видах внимание обращается на чтение текста. Это – в полном значении уроки литературного чтения.

При чтении текста на уроке в сознание учащихся проникает образное мышление автора. Потому что при чтении изображенные явления постоянно зрелищно предстают перед слушателем. Процесс чтения является упражнением для умственной деятельности, помогает развитию мыслительной способности.

В программе наряду с произведениями небольшого объема предложены повести и романы. С рассказами можно ознакомиться на уроке, стихотворения можно прочитать даже несколько раз. При работе над произведением большого объема приходится чередовать чтение на уроке с домашним, можно предложить пересказ некоторых разделов отдельным учащимся.

В старших классах (IX-XI), для достижения основной цели изучения художественной литературы, в программу вводятся поочередно темы монографического и обзорного характера. Если такое чередование, во-первых, дает возможность ознакомления учащихся с лучшими произведениями литературного искусства, во-вторых, дает понять и определить место в историко-литературном процессе этих произведений. Монографические произведения дают возможность на примере творчества одного писателя показать всесторонний охват жизненных событий. Некоторые из этих тем открывают широкий путь к подробному изучению окружающей жизни и литературного наследия писателя, другие не ставят такой задачи, более кратки. Однако, в конечном счете, и они дают возможность взглянуть на жизнь и новые стороны человеческого характера и психологии. Задачей и в тех, и в других является глубокое усвоение текста литературного произведения.

В отдельных случаях предлагается изучить на выбор одну из монографических тем. Учитель учитывает уровень готовности класса, желание и заинтересованность учащихся, наличие данного произведения в школьной библиотеке.

Обзорные темы знакомят с особенностями того или иного периода, литературными течениями и направлениями, с различными группами писателей,

литература данного периода дает сведения о наиболее важных задачах и характерах людей. Некоторые самые значимые произведения изучаемого периода предлагаются учащимся для самостоятельного ознакомления.

Программа предусматривает при изучении литературного произведения постоянное внимательное отношение к развитию устной речи и культуре письма учащихся. Учитель вправе и должен пользоваться различными видами устных и письменных работ. Одной из задач учителя является и поддержка стремления учащихся к самостоятельному литературному творчеству.

В основу региональной программы положены “Программы по татарской литературе для татарских средних школ. 5-11 классы”, утвержденные Министерством образования Республики Татарстан (Казань: Мәгариф, 2000) с включением авторов и произведений региональной татарской литературы Тюменской области.



# Туган тел (татар теле) буенча программа

## Ү СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

***Кереш дәрес.*** Туган тел турында әңгәмә. ***– 1 сәгать***

***Башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау (8 сәгать).***

**Исем.** Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Күплек һәм берлек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. ***– 2 сәгать***

**Фигыль.** Хикәя фигыль. Үткән, хәзерге, киләчәк заман фигыльләр. ***– 2 сәгать***

**Алмашлык.** Зат алмашлыклары. ***– 1 сәгать***

**Җөмлә.** Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәкләре. ***– 2 сәгать***

Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боеру җөмләләре. ***– 1 сәгать***

***Фонетика (26 сәгать).***

**Фонетика турында төшенчә.** Сөйләм аппараты. Авазларның ясалышы. ***– 1 сәгать***

**Сузык авазлар.** Аларның саны һәм составы. ***– 1 сәгать***

Үзенчәлекле сузык авазларны дөрес әйтергә өйрәтү. Рус теленнән кергән [о], [ы] һәм [е] авазлары. Аларның кулланылышы. ***– 1 сәгать***

Сузыклар таблицасын төзү. Сүздәге сузык авазларга характеристика бирү. ***– 1 сәгать***

**Тартык авазлар.** Аларның саны һәм составы. ***– 2 сәгать***

Үзенчәлекле тартык авазларны дөрес әйтергә өйрәтү.

[к], [г] һәм [къ], [гъ] тартыклары. ***– 1 сәгать***

[һ] һәм [х] тартыклары. ***– 1 сәгать***

[н] һәм [ң] тартыклары. ***– 1 сәгать***

[w] һәм [в] тартыклары. ***– 1 сәгать***

[ц] һәм [ч] тартыклары. ***– 1 сәгать***

Тартыклар таблицасын төзү. Сүздәге тартык авазларга характеристика бирү. ***– 1 сәгать***

**Иҗек.** Сүзләрне иҗекләргә бүлергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Басым.** Сүзләрне дөрес басым белән әйтергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Интонация.** Интонациянең төп өлешләре. Интонациянең төрләре. ***– 1 сәгать***

**Орфоэпия.** Орфоэпия турында төшенчә. Авазларның дөрес әйтелеше буенча күнекмәләр булдыру. ***– 2 сәгать***

**Графика.** Графика турында төшенчә. Авазларны язуда күрсәтү. Сузык аваз хәрефләре. Тартык аваз хәрефләре. ***– 2 сәгать***

**Орфография.** Орфография турында төшенчә. Сузык һәм тартык авазларның язуда хәрефләр белән бирелеше. Аваз һәм хәреф. Алфавит. Сузык

һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес язу. Башка телләрдән кергән сүзләрнең дөрес язылышы. *– 2 сәгать*

Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләрен өйрәтү. *– 1 сәгать*

Орфографик сүзлектән файдаланырга өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Фонетик анализ. *– 1 сәгать***

**“Фонетика” бүлеге буенча белемнәрне гомумиләштерү, системага салу дәресе *– 1 сәгать***

**“Фонетика” бүлеге буенча белемнәрне тикшерү дәресе *– 1 сәгать***

## *Лексика (13 сәгать).*

**Лексика турында төшенчә.** Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Татар теленең сүзлек байлыгы. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Бер мәгънәле сүзләрне күп мәгънәле сүзләрдән аера алу. *– 1 сәгать*

**Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе**. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аера алу. *– 1 сәгать*

**Омонимнар.** Омоним сүзләрне күп мәгънәле сүзләрдән аерырга өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Синонимнар**. Синонимнарның мәгънәви һәм стилистик яктан аермаларын күрергә өйрәтү. Сөйләм төзегәндә синонимнардан файдалана белергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Антонимнар**. Антонимнарның сөйләмдә кулланылышын күзәтү. *– 1 сәгать*

**Фразеологик әйтелмәләр**. Сөйләм төзегәндә фразеологизмнардан файдалана белелергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы**. Гомумтөрки сүзләр. Алынма сүзләр. Гарәп, фарсы алынмалары. Рус алынмалары. Рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр. Гомумтөрки һәм алынма сүзләрне аерырга өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Кулланылыш өлкәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы**. Гомумхалык сүзләре. Әдәби тел сүзләре. Диалекталь сүзләр. Профессиональ сүзләр. Терминнар. *– 1 сәгать*

**Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы**. Актив һәм пассив кулланылышлы сүзләр. Искергән сүзләр: историзмнар, архаизмнар. Неологизмнар. *– 1 сәгать*

**Сүзлекләр**. Аңлатмалы, фразеологик, синоним, омоним, татарча-русча, русча-татарча һ.б. төр сүзлекләр. Аларның төзелеш принциплары. Сүзлекләрдән файдалану юллары. *– 1 сәгать*

**Лексик анализ. *– 1 сәгать***

**“Лексика” бүлеге буенча белемнәрне гомумиләштерү, системага салу дәресе *– 1 сәгать***

**“Лексика” бүлеге буенча белемнәрне тикшерү дәресе *– 1 сәгать***

## *Сүз ясалышы (5 сәгать)*

**Сүз ясалышы турында төшенчә.** Сүз төзелеше. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч, мөнәсәбәт белдерүче һәм бәйләгеч кушымчалар. Аларны сүзгә ялгау тәртибе. ***– 2 сәгать***

**Сүз ясалыш ысуллары.**

Сүз ясагыч кушымчалар ялгау. ***– 1 сәгать***

Сүзләрне кушу. Кушма сүзләр. Парлы сүзләр. Тезмә сүзләр. ***– 1 сәгать***

Сүзләрне кыскарту. ***– 1 сәгать***

### *Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 2 сәгать*

### *Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре (13 сәгать).*

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 2 сочинение, 1 изложение яздырыла.

Сөйләм төрләре: сыйфатлама, хикәяләү, хөкем йөртү. Төрле типтагы текстлар белән таныштыру.

Текст, аның билгеләре. Текст темасы. Төп фикер. Текстның атамасы. План төзү. Планга нигезләнеп сөйләм төзү.

Сыйфатлама характерындагы текст төзү. Пейзаж сүрәтләнгән картина буенча сочинение яздыру.

Монологик һәм диалогик сөйләм. Төрле типтагы сорау һәм җавап репликаларын кулланып, көндәлек тормыш белән бәйле ситуацияләргә диалог төзү.

Хат турында төшенчә. Шәхси, эш хатлары яздыру күнекмәләрен булдыру.

Укылган яки тыңланган себер халык авыз иҗаты текстының (әкият, риваять, легенда) эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү.

Текстны тыңлап, эчтәлеген укытучының сораулары буенча эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

Әйтелеше һәм язылышы ягыннан аермалар булган сүзләрдән диктант язу.

Терәк сүзләр ярдәмендә текст төзү.

Я.Зәнкиевның балалар өчен язган берәр хикәясе буенча хөкем йөртү тибындагы сочинение язу.

Укучы сайлап алган текстны интонацион кисәкләргә бүлеп сәнгатьле итеп уку.

### *5 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар*

Исәннәшү, танышу, саубуллашу. Аралашу әдәпләренә өйрәтү.

Уку-язу әсбаплары. Китап – белем ачкычы.

Көзге табигать. Табигать күренешләрен күзәтеп, кайбер закончалыклар һәм алар арасында бәйләнеш турында нәтиҗә ясарга өйрәтү.

Минем якын дусларым.

Чыршы бәйрәме.

Кышкы каникулда.

Минем әнием (әбием).

Безнең авыл.

Яраткан фәнем.

Ашханәдә үзенне ничек тотарга?

Бакчадагы язгы эшләр.

Я.Зәнкиев – минем якташ язучым.

## *5 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- башлангыч сыйныфларда алган белемнәрен тирәнәйтеп, таныш модельләр нигезендә гади һәм кушма җөмләләр төзү; җөмләдә баш кисәкләрне табу; иярчен кисәкләрдән аергыч, тәмамлык һәм хәлне билгеләү;
- әйтү максатыннан чыгып, җөмләнең ахырында тиешле тыныш билгеләрен кую;
- сузык һәм тартык авазларны аера белү. Авазларга характеристика бирү;
- авазларны дөрес әйтү; сүзләрне дөрес басым белән әйтү;
-татар алфавитын яттан белү;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү; сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләрен белү;
- бер мәгънәле сүзләрне күп мәгънәле сүзләрдән аера алу;
- сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аера алу;
- омоним, синонним, антоним сүзләрне, фразеологизмнарны аера белү; сөйләм төзегәндә алардан файдалану күнекмәләре булдыру;
- алынма сүзләрне таный белү;
- татар теленең сүзлек составын кулланылыш өлкәсе һәм дәрәҗәсе ягыннан характерлау;
- орфографик, орфоэпик, аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, фразеологизмнар сүзлекләреннән файдалана белү.
-сүзгә фонетик анализ ясый алу;
- сүзнең лексик мәгънәсен билгели белү;
-сүзгә лексик анализ эшләү;
- сүз ясалыш ысулларын белү;

# ҮI СЫЙНЫФ
***(68 сәгать)***

***Кереш дәрес.*** Татар телем – туган телем. ***(1 сәгать).***
***Алдагы сыйныфта үткәннәрне кабатлау (4 сәгать).***

***Морфология (46 сәгать).***

**Морфология** турында төшенчә. Сүз төркемнәре турында төшенчә. ***– 1 сәгать***

**Исем.** Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. ***– 1 сәгать***

Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Исемнәрнең ясалышы. Ясалышы ягыннан исемнәрнең төрләре: тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма исемнәр. ***– 2 сәгать***

Исемнәрне морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Фигыль.** Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Боерык фигыль, аның мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Хикәя фигыль, аның мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. Үткән, хәзерге, киләчәк заман фигыльләр. ***– 3 сәгать***

Шарт фигыль, аның мәгънәсе, төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Затланышсыз фигыль формалары. ***– 1 сәгать***

Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, заман формалары. ***– 1 сәгать***

Хәл фигыль, аның мәгънәсе, төрләре. ***– 1 сәгать***

Исем фигыль, аның мәгънәсе. ***– 1 сәгать***

Инфинитив, аның мәгънәсе. ***– 1 сәгать***

Ярдәмче фигыльләр. ***– 1 сәгать***

Фигыльләрнең ясалышы. ***– 1 сәгать***

Фигыльләрне морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Сыйфат.** Сыйфатның грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре. ***– 1 сәгать***

Сыйфат дәрәҗәләре. ***– 1 сәгать***

Сыйфатларның ясалышы. ***– 1 сәгать***

Сыйфатларны морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Сан.** Санның грамматик мәгънәсе. ***– 1 сәгать***

Сан төркемчәләре. Төп, тәртип, җыю, өлеш, бүлем саннары. ***– 2 сәгать***

Саннарны морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Рәвеш.** Рәвешнең грамматик мәгънәсе. ***– 1 сәгать***

Рәвеш төркемчәләре. Саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама, вакыт, урын, сәбәп-максат рәвешләре. ***– 2 сәгать***

Рәвешләрне морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. ***– 1 сәгать***

**Алмашлык.** Алмашлыкның грамматик мәгънәсе. ***– 1 сәгать***

Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Күрсәтү алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше. ***– 1 сәгать***

Тартым алмашлыклары. ***– 1 сәгать***

Сорау алмашлыклары. *– 1 сәгать*

Билгеләү һәм билгесезлек алмашлыклары. *– 1 сәгать*

Юклык алмашлыклары. *– 1 сәгать*

Алмашлыкларны морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Бәйлек һәм бәйлек сүзләр.** Аларны практик куллану. Морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Теркәгеч.** Аларны практик куллану. Синоним теркәгечләрдән урынлы файдалану. Теркәгечләрне морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Кисәкчә.** Аларны сөйләмдә куллану. Кисәкчәләрне морфологик яктан тикшерергә өйрәтү. *– 1 сәгать*

**Хәбәрлек сүзләр.** Аларны практик куллану. *– 1 сәгать*

**Ымлык һәм аваз ияртемнәре.** Аларны сөйләмдә куллану. Татарча аваз ияртемнәрен һәм ымлыкларын русча бирелештән аера белү. *– 1 сәгать*

***Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать***

***Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре (14 сәгать).***

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 2 сочинение, 2 изложение яздырыла.

Укытучы укыган текстка план төзү. Планга нигезләнеп сочинение язу.

Хикәяләү характерындагы текст төзү. “Туган як табигатен саклау” темасына сочинение-хөкем йөртү яздыру.

Диалогик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы сорау һәм җавап репликаларын кулланып, мәктәп тормышы белән бәйле ситуацияләргә диалог төзү.

Мәкалә турында төшенчә. Газета стиле белән таныштыру. “Яңарыш”, “Себер иле” газеталарына мәкалә язып җибәрү.

Себер халык авыз иҗаты әсәрләрен туплап, “Халкымның хәзинәсе” дигән темага әңгәмә үткәрү.

Бәйрәм белән котлап открытка язу.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

Терәк сүзләр ярдәмендә текст төзү.

Әдәби әсәрдән өзекне укып, эчтәлеген эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү, әсәр буенча фикер алышу.

***6 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар***

Җәйге каникулларда

Кешенең тышкы кыяфәте.

Минем якын туганнарым.

Минем көндәлек режимым.

Китапханәдә.
Без яшәгән як табигате.
Төмән – өлкәбезнең башкаласы.
Безнең өлкәдә үсүче файдалы үләннәр.
Яңа ел бәйрәменә әзерләнү.
Кышкы табигатьне яратам.
Минем абыем – ил сакчысы.
Минем яраткан татар җырчым.
Әмәл – яз бәйрәме.
Татар телендә язылган яраткан әдәби әсәр.
Табиб янында.

### *6 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- морфология һәм сүз төркемнәре турында аңлатма бирә белү;
- бары сүз төркемнәренә морфологик анализ ясый белү;
- бары сүз төркемнәрен ясалышы ягыннан характерлый белү;
- ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне аеру;
- исемнәрне килеш, тартым белән төрләндерә белү;
- фигыль төркемчәләрен аера белү;
- фигыльләрне зат-сан, заман белән төрләндерү;
- затланышлы һәм затланышсыз фигыль формаларын аеру;
- сыйфатның морфологик билгеләрен, дәрәҗәләрен аера белү;
- санның төркемчәләрен аеру;
- рәвешнең төркемчәләрен аеру;
- алмашлыкларның төрләрен белү;
- бәйлек, теркәгеч, кисәкчәне аеру, урынлы куллану белү;
- хәбәрлек сүз, ымлык һәм аваз ияртемнәрне аеру һәм практик куллану;
-бирелгән текстта сүзләрне төркемнәре ягыннан тану;

## ҮII СЫЙНЫФ

***(68 сәгать )***

***Кереш дәрес.*** Татар теленең әһәмияте.***– 1 сәгать***

***Кабатлау – 2 сәгать.***

**Синтаксис турында төшенчә.** Синтаксик берәмлекләр. Җөмлә. ***– 1 сәгать***

**Сүзтезмә. *– 3 сәгать***

**Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. *– 2 сәгать***

**Җөмләнең баш кисәкләре.** Ия, хәбәр. Аларның төп билгеләре. Ия белән хәбәрнең җөмләдә урыны. ***– 3 сәгать***

**Җөмләнең иярчен кисәкләре.** Аергыч. Аергычның аерылмыш белән бәйләнеше. ***– 2 сәгать***

Тәмамлык. Туры һәм кыек тәмамлык. ***– 2 сәгать***

Хәл. Урын, вакыт хәле. ***– 2 сәгать***

Сәбәп, максат хәле. ***– 2 сәгать***

Рәвеш, күләм хәле. ***– 2 сәгать***

Шарт хәле, кире хәл. ***– 2 сәгать***

**Җөмләнең модаль кисәкләре.** Эндәш сүзләр, кереш сүзләр. Алар янында тыныш билгеләре. Эндәш һәм кереш сүзләрне дөрес интонация белән әйтергә һәм укырга өйрәтү.  ***– 2 сәгать***

**Җөмләдә сүз тәртибе.** Җөмләдә сүзләрнең туры һәм кире тәртибе. ***– 1 сәгать***

**Җөмләнең аерымланган кисәкләре.** Хәлләрнең аерымлануы. Аныклагычларның аерымлануы. Алар янында тыныш билгеләре. – ***3 сәгать***

**Тиңдәш кисәкләр**. Гомумиләштерүче сүзләр. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.– ***3 сәгать***

**Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.** ***– 2 сәгать***

**Тулы һәм ким җөмләләр.** Аларның сөйләмдә кулланылышы. ***– 2 сәгать***

**Бер составлы җөмләләр.**

Бер составлы фигыль җөмләләр, аның төрләре. – ***3 сәгать***

Бер составлы исем җөмләләр. ***– 1 сәгать***

***Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать***

***Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре*** – ***24 сәгать .***

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 2 сочинение (1 – өй сочинениесе), 2 изложение яздырыла.

Әдәби әсәр буенча берәр персонажны характерлау тибында сочинение язу.

Сыйфатлама характерындагы текст төзү. “Татарларның тарихи өс-баш киемнәре” темасына доклад язу.

Диалогик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы сорау һәм җавап репликаларын кулланып, “Себер татарларының йолалары” дигән темага диалог төзү.

Терәк сүзләр ярдәмендә текст төзү.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

Гариза турында төшенчә. Аны язу күнегүләре.

Әдәби әсәрдән өзекне укып, эчтәлеген эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү, әсәр буенча фикер алышу.

### *7 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар*

Җәй калдырган тәэсирләр.

Безнең бакчадагы җиләк-җимешләр.

Әтинең профессиясе.

Сыйныфташымда кунакта.

Татар халкының йолалары: каз өмәсе.
Татар композиторлары.
Спорт – минем дустым.
Йорт хайваннары.
Тубыл – Төмән өлкәсенең иске шәһәре.
Безнең мәктәпне кемнәр тәмамлаган?
Татарларның тарихи өс-баш киемнәре.
Әбием (бабайым) миңа ни сөйли?
9 Май – Җиңү бәйрәме.
Алда җәйге каникуллар.

### *7 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- синтаксис һәм синтаксик берәмлекләр, җөмлә турында аңлатма бирә белү;
- җөмләдән сүзтезмәләрне аерымлый алу; сүзтезмәләрне характерлау;
- әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аерымлый алу; җөмлә ахырында тыныш билгеләрен дөрес куерга өйрәнү;
- җөмләнең баш, иярчен, модаль кисәкләрен аера белү;
- җөмләдә эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре;
- җөмлә кисәкләренең аерымлануы;
- аерымланган аныклагычлар һәм хәлләр янында тыныш билгеләрен куя белү;
- тиңдәш кисәкләр, гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләрен куя белү;
- җөмләдә сүзләрнең туры һәм кире тәртибендә урнашуы;
- гади җөмлә модельләрен аера белү, төрле типтагы җөмләләр төзи алу;
- гади җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру.

## ҮIII СЫЙНЫФ
***(68 сәгать)***

***Кереш дәрес. – 1 сәгать***
***Кабатлау. – 4 сәгать***

**Кушма җөмлә турында төшенчә.** ***– 1 сәгать***
**Тезмә кушма җөмләләр.** Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. ***– 2 сәгать***
**Иярченле кушма җөмләләр.**
Иярченле кушма җөмләләрнең төзелеше ягыннан төрләре. Иярченле кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. ***– 2 сәгать***
Иярчен ия, иярчен хәбәр җөмләләр. ***– 2 сәгать***
Иярчен аергыч, иярчен тәмамлык җөмләләр. ***– 2 сәгать***

Иярчен вакыт, иярчен урын җөмләләр. *– 2 сәгать*

Иярчен рәвеш, иярчен күләм җөмләләр. *– 2 сәгать*

Иярчен максат, иярчен сәбәп җөмләләр. *– 2 сәгать*

Иярчен шарт, иярчен кире җөмләләр. *– 2 сәгать*

Иярченле җөмләләрдә тыныш билгеләренең куелышы. *– 2 сәгать*

**Катлаулы җөмләләр.**

Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Тиңдәш ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Бер-бер артлы ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

Катнаш кушма җөмлә. *– 1 сәгать*

**Тезем.** Теземнең төрләре. *– 1 сәгать*

**Пунктуация.** Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре. Аеручы һәм аерымлаучы тыныш билгеләре. *– 1 сәгать*

Нокта, сорау, өндәү билгеләренең куелышы. *– 1 сәгать*

Күп ноктала, куштырнаклар куела торган очраклар. *–1 сәгать*

Өтер, нокталы өтер, ике нокта куела торган очраклар. *– 2 сәгать*

Сызык, җәяләрнең куелышы. *– 2 сәгать*

**Туры һәм кыек сөйләм.** Диалог. Монолог. Туры сөйләм янында тыныш билгеләренең куелышы. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү. *– 2 сәгать*

### *Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать*

### *Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре – 24 сәгать*

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 2 сочинение (1 – өй сочинениесе), 2 изложение яздырыла.

“Президент белән очрашсам...” темасына хөкем йөртү тибындагы текст язу.

Диалогик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы сорау һәм җавап репликаларын кулланып, “Яраткан шигырем” дигән темага диалог төзү.

“Татар җырчылары, композиторлары” дигән темага проект-презентация төзү һәм аны яклау.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

Утырыш беркетмәсе турында төшенчә. Аны язу күнегүләре.

Әдәби әсәрдән өзекне укып, эчтәлеген эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү, әсәр буенча фикер алышу. Әсәргә рецензия язу.

Терәк сүзләр ярдәмендә текст төзү.

### *8 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар*

Көзге үзгәрешләр.
Күчмә кошлар.
Президент белән очрашсам...
Татар халкының туй йолалары.
Татар җырчылары.
Татарларның тарихи җырлары.
Ни өчен спорт белән шөгыльләнү кирәк?
Безнең тирәдә яшәүчеерткыч хайваннар.
Театрда, кинода.
Укытучы профессиясе.
Татар халык ашлары.
Сабантуй калдырган тәэсирләр.
Яраткан шигырем.

### *8 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- кушма җөмлә турында төшенчә бирә белү; гади һәм кушма җөмләләрне аерымлый алу;
- тезмә кушма җөмләләрнең төрләрен аерымлау;
- тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен куя белү;
- иярченле кушма җөмләләрнең төзелеше ягыннан төрләрен билгели алу;
- иярченле кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләрен билгеләү;
- иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләренең куя белү;
- кушма җөмләләрне катлаулы җөмләләрдән аеру юлларын белү;
- катлаулы җөмләләрнең төрләрен аерымлый алу, аларга схема төзи белү;
- кушма, катлаулы җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру;
- теземнең төрләрен аера белү;
- пунктуация турында аңлатма бирә алу;
- аеручы һәм аерымлаучы тыныш билгеләрен дөрес куярга, куелышын аңлата белү;
- туры сөйләм янында тыныш билгеләренең куелышын белү;
- туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерә алу.

## IX СЫЙНЫФ

***(68 сәгать)***

***Кереш дәрес - 1 сәгать***

***Алдагы сыйныфларда үзләштергәннәрне тирәнәйтеп кабатлау, гомумиләштерү (22 сәгать)***

**Фонетика, фонология.** Аваз һәм фонема. Аваз үзгәрешләре. Фонетик анализ. ***– 4 сәгать***

**Орфоэпия, орфография.** Сузык һәм тартык авазларның дөрес әйтелеше һәм язылышы. *– 2 сәгать*

**Лексикология.** Сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләре. Татар теленең сүзлек байлыгы. Омоним, синоним, антоним сүзләр. Фразеологик әйтелмәләр. Алынма сүзләр, аларның чыганаклары, үзләштерелеше. Гомумхалык сүзләре. Әдәби тел сүзләре. Диалекталь сүзләр. Профессиональ сүзләр. Терминнар. Актив һәм пассив кулланылышлы сүзләр. Лексик анализ. *– 4 сәгать*

**Лексикография.** Сүзлекләрнең төрләре, төзелеш принциплары. *– 1 сәгать*

**Сүз ясалышы.** Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Сүз ясалыш ысуллары. *– 1 сәгать*

**Морфология.** Мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре. *– 4 сәгать*

**Синтаксис.** Синтаксик берәмлекләр. Сүзләр арасында бәйләнеш: ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Бәйләүче чаралар. *– 2 сәгать*

Гади җөмлә төрләре. Кушма җөмлә төрләре. Җөмләләрдә тыныш билгеләренең куелышы. *– 4 сәгать*

### *Стилистика һәм сөйләм культурасы (12 сәгать)*

**Әдәби тел һәм аның стильләре**. Язма һәм сөйләмә стиль. *– 1 сәгать*

**Функциональ стильләр**. Матур әдәбият стиле, аның лексик, грамматик үзенчәлекләре. *– 1 сәгать*

Көндәлек матбугат стиле һәм аның үзенчәлекләре. *– 1 сәгать*

Фәнни стиль, аның грамматик һәм лексик үзенчәлекләре. *– 1 сәгать*

Эш кәгазьләренә хас стиль үзенчәлекләре. *– 1 сәгать*

Эпистоляр стиль, аның телебез тарихында тоткан урыны. Үзенчәлекләре. *– 1 сәгать*

**Лингвистик стилистика**. Тел берәмлекләренең сөйләм оештыруда роле. Лексик стилистика. Сүзләрнең бер-бере белән лексик-семантик бәйләнеше. *– 2 сәгать*

**Грамматик стилистика**. Сүз кисәкләрен, сүзләрне, җөмләләрне грамматик яктан дөрес куллану. *– 2 сәгать*

**Сөйләм культурасы**, аның нигезләре. Сөйләмгә куела торган таләпләр. *– 2 сәгать*

### *Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать*

### *Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре – 30 сәгать*

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 3 сочинение (1 – өй сочинениесе), 3 изложение яздырыла.

Монологик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы җөмләләрне кулланып, “Минем булачак профессиям” дигән темага монолог төзү.

“Бөек Ватан сугышында катнашучы татар язучылары” дигән темага доклад язу, чыгыш ясау.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

“Татарларның мәкаль-әйтемнәре” темасына материаллар җыйнап, кечкенә альбом төзү (мәкаль-әйтемнәр алфавит тәртибендә урнаштырыла).

Белешмә турында төшенчә. Аны язу күнегүләре.

Я.Зәнкиевның “Иртеш таңнары” әсәреннән өзекне укып, эчтәлеген эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү, аның буенча фикер алышу. Укылган өзеккә рецензия язу.

Терәк сүзләр ярдәмендә текст төзү.

### *9 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар*

Бакчадагы эшләр.

Бездә кышлаучы кошлар.

Татар халкының дини йолалары.

Татар рәссамнары.

Татарларның мәкаль-әйтемнәре, табышмаклары.

Минем булачак профессиям.

Себер татарларының ашлары.

Бөек Ватан сугышында катнашучы татар язучылары.

Б.Сөләйманов – җирле шагыйрь.

Тубыл шәһәренә экскурсиягә бардык.

Безнең тирәдәге табигать матурлыгы.

Безнең авыл (шәһәр) исеме кайдан килеп чыккан?

### *9 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- фонетика, фонология турында аңлатма булдыру;
- аваз һәм фонеманы аера белү;
- аваз үзгәрешләрен (сингармонизм: рәт, ирен гармониясе, тартыклар ассимиляциясе, авазларның кыскаруы һ.б.) билгели алу күнекмәләре булдыру;
-сүзгә тулы фонетик анализ ясый алу;
- сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен билгели белү;
-сүзгә лексик анализ эшләү;
- сүзлекләрдән куллану юлларын тирәнәйтү;
- сүз ясалыш ысулларын белү;
- мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- гади, кушма җөмлә төрләрен билгели алу;
- тыныш билгеләренең куелышын белү, аңлатып бирә алу;
-язма һәм сөйләмә стиль, функциональ стильләр турында төшенчә булдыру;
- тел берәмлекләренең сөйләм оештыруда ролен ачыклау;
- сөйләмгә куела торган таләпләрне белү.

# X СЫЙНЫФ

***(34 сәгать)***

***Кереш дәрес.*** Милли телне саклау, үстерү проблемалары. ***– 1 сәгать***

**Татар теле һәм язуының тарихы.**

Төрки халыклар өчен гомуми булган борынгы әдәби тел (V-X гасырлар). Рун язуы турында төшенчә. ***– 1 сәгать***

Төрки халыклар өчен гомуми булган иске төрки тел (X-XV гасырлар). Гарәп язуының төрки халыкларда кулланыла башлавы. Гарәп графикасы. ***– 1 сәгать***

Иске татар әдәби теле (XVI-XIX гасырлар). ***– 1 сәгать***

Хәзерге милли татар әдәби теленең формалашуы. ***– 1 сәгать***

Татар язуын латин графикасына күчерү (1927-1939 еллар). ***– 1 сәгать***

Кириллицага нигезләнгән графикага күчү. ***– 1 сәгать***

Татар теле буенча эшләүче галимнәр. ***– 3 сәгать***

***Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать***

***Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре – 21 сәгать***

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 3 сочинение (1 – өй сочинениесе), 3 изложение яздырыла.

Монологик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы җөмләләрне кулланып, “Күренекле татар кешесе” дигән темага монолог төзү.

“Рәсәй Федерациясендә яшәүче төрки халыклар” дигән темага доклад язу, чыгыш ясау.

“Татарларның ырымнары, сынамышлары” темасына материаллар җыйнап, кечкенә альбом төзү (материал алфавит тәртибендә урнаштырыла).

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

Реферат турында төшенчә. Аны язу күнегүләре.

Б.Сөләймановның шигырен сәнгатьле итеп укып, эчтәлеге буенча фикер алышу. Укылган әсәргә рецензия язу.

Терәк сүзләр ярдәмендә зур күләмле текст төзү.

***10 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар***

Рәсәй Федерациясендә яшәүче төрки халыклар.

Татар халкының йолалары, бәйрәмнәре.

Күренекле татар кешесе.

Татарларның мәкаль-әйтемнәре, ырымнары, сынамышлары.

Казан – Татарстанның башкаласы.

Казан буенча интерактив экскурсия.

Бөек Ватан сугышында катнашучы якташларым.

Б.Сөләйманов – себер татарлары язмышын кайгыртучы.

Безнең тирәдәге табигать матурлыгы.

Я.Зәнкиев романнарында себер татарларының йолалары чагылышы.

***10 нче сыйныфны тәмамлаган***
***укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре***

- татар теле һәм язуының тарихын белү;

-төрки халыклар өчен гомуми булган борынгы әдәби тел үзенчәлекләрен белү;

-рун язуы турында төшенчә бирә алу;

- төрки халыклар өчен гомуми булган иске төрки теле үзенчәлекләрен белү;

- гарәп язуының төрки халыкларда кулланыла башлавы турында тарихи белешмә бирә алу;

- гарәп графикасы, аның татар теле үсешендә ролен ачыклау;

- иске татар әдәби теле үзенчәлекләрен белү;

- хәзерге милли татар әдәби теленең формалашуы турында аңлатма бирү;

- кирилл графикасының ролен ачыклау;

-татар тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәр биографиясе, хезмәтләре белән таныш булу.

## XI СЫЙНЫФ
***(34 сәгать)***

***Кереш дәрес.*** Телнең иҗтимагый әһәмияте. Тел – төп аралашу чарасы. ***– 1 сәгать***

**Тел гаиләләре турында төшенчә**. Алтай гаиләсе, һинд-европа, фин-угор тел гаиләләре. Татар теленең генеалогик классификациядә урыны. ***– 2 сәгать***

**Татар этнонимы**, терминның килеп чыгышы, мәгънәсе. Татар халкының яшәү урыннары (таралышы). Себер татарлары, Идел татарлары, Кырым татарлары, Литва татарлары, Добруджа татарлары. ***– 2 сәгать***

**Татар теленең диалектлары**. ***– 2 сәгать***

**Тел сәясәте**. Хәзерге Рәсәй Федерациясендә тел ситуациясе (торышы).
***– 1 сәгать***

***Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау, гомумиләштерү, системага салу дәресләре – 3 сәгать***

***Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре – 23 сәгать.***

Уку елы барышында кимендә 3 диктант, 4 сочинение (1 – өй сочинениесе), 3 изложение яздырыла.

Монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен тирәнәйтү. Төрле типтагы җөмләләрне кулланып, “Кем ул татар кешесе?” дигән темага монолог төзү.

“Татар этнонимының килеп чыгышы” дигән темага доклад язу, чыгыш ясау.

Сюжетлы рәсем буенча хикәя төзү.

“Минем мәктәбем” темасына материаллар җыйнап, проект-презентация төзү.

Үтелә торган тема буенча дәресне конспектлау.

Укучы сайлавы буенча берәр шигырьне сәнгатьле итеп укып, эчтәлеге буенча фикер алышу. Укылган әсәргә рецензия язу.

Терәк сүзләр ярдәмендә зур күләмле текст төзү.

***11 нче сыйныфта укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү өчен тәкъдим ителгән темалар***

Тел – кешеләр арасында төп аралашу чарасы.
Татар халкының формалашуы.
Татар этнонимының килеп чыгышы.
Себер татарларының яшәү урыннары.
Себер татарларының этник составы.
Кем ул татар кешесе?
Татар тарихын язучы галимнәр.
Татар һәм рус, башка халыклар арасында мөнәсәбәт.
Себер татарларында кунак чакыру йоласы.
Я.Зәнкиевнең романнарында татар халык мәкальләре.
Себер татар халык йоласы – кузайтын.
Минем сайлаган профессиям.
Минем мәктәбем.
Соңгы кыңгырау: алда безне ни көтә?

***11 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның тел осталыклары һәм күнекмәләре***

-телнең иҗтимагый әһәмиятен ачыклап бирә алу;
- телне кешеләр арасында төп аралашу чарасы буларак дәлилләү;
- тел гаиләләре турында төшенчә булдыру;
-алтай гаиләсе, һинд-европа, фин-угор тел гаиләләрен характерлап бирә алу;
-татар теленең генеалогик классификациядә урынын билгели алу;
-татар этнонимының, терминның килеп чыгышын, мәгънәсен аңлатып бирә алу;
- татар халкының яшәү урыннарына карап төркемнәре турында белү;
-татар теленең диалектлары турныда белү;
-хәзерге Рәсәй Федерациясендә тел ситуациясен характерлау. Тел турындагы законнарны белү.

# Татар әдәбияты буенча программа

## V СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 50 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 12 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 6 сәгать**

**Халык авыз иҗаты**. Фольклор турында төшенчә. Аның жанрлары. Әкиятләр. Алардагы фантастик, тылсымлы сюжетлар. Тылсымлы, хайваннар турындагы һәм тормыш-көнкүреш әкиятләре арасындагы аерма турында кыскача аңлатма бирү.

Уку һәм анализлау өчен:

*"Таңбатыр"* әкияте. Аны уку. Текстка якын итеп балалардан сөйләтү. Әкият героеның сыйфатларына игътибар итү. ***– 4 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

*"Үги кыз"* әкияте. Укып чыгу, сөйләү. Герой холкындагы гаделлек, тугрылык. ***– 2 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

*"Чакмакташ", "Гөлчәчәк", "Солдат балтасы".* Башка халыклар әкиятләре (укучылар һәм укытучы сайлавы буенча). Балалардан үзләре белгән әкиятләрне сөйләтү.

Уку һәм анализлау өчен:

"Әтәч белән Төлке", "Ай белән Кояш". Әкиятләрдә кешегә хас сыйфатларның һәм фикер йөртүнең хайваннарга, табигать җисемнәренә үзенчәлекле төстә күчерелүе. Балалардан хайваннар турында үзләре белгән яки уйлап чыгарган әкиятләрен сөйләтү. ***– 2 сәгать***

***Региональ компонент:*** *"Аю, бүре, төлке", "Курбала", "Торна балалары"* (Л.Хәбибуллина "Туган як әдәбияты", 1нче том. – Төмән, 2002. – Б. 57-63). Тапкырлыкка корылган әкиятләрдә тормышчанлык, акыл көченең өстенлеген күрсәтү. Тормышның мәгънәсе һәм кызыклыгы байлыкта гына түгеллеген раслау. Көнкүреш әкиятләренең тәрбияви көче. ***– 2 сәгать***

Мәзәкләр. Алардагы тапкырлык, юмор, кимчелекләрне тәнкыйтьләү, тирән мәгънә, хикмәтлелек.

Уку һәм анализлау өчен:

*"Ишәк өстендә", "Шайтан ни төсле", "Былтыргы "А", "Кичке аштан соң", "Улы һәм атасы"*. Мәзәкләрне уку, сөйләү, хикмәтен аңлату. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

***Региональ компонент:*** *"Телме, башмы гаепле", "Юеш сөлге", "Табагач"* (Л.Хәбибуллина "Туган як әдәбияты", 1нче том. – Төмән, 2002. – Б.87-88).

Дәрестән тыш уку өчен:

**К. Насыйри**. Хикәяләр *("Иске мәдрәсәдә", "Патша белән карт", "Аңгыралык бәласы" h.б.)*

Уку һәм анализлау өчен:

**Г.Тукай**. *“Исемдә калганнар”*. Балачак хатирәләренең самимилеге, төгәллеге. Авыр язмышны оптимистик рухта сурәтләү. Биография һәм автобиография турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

*“Шүрәле”* поэмасы. Уку, эчтәлеген сөйләү. Поэманың әкиятләр җирлегендә иҗат ителүе. Авыл егетенең тапкырлыгы. Табигать күренешләренең җасвирланышы. Поэманы гүзәл иткән элемент-чаралар. Чагыштыру һәм эпитетны аңлату. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Тукай**. *“Пар ат”*. Лирик геройның татар мәдәнияте үзәгенә омтылуы. Казанга зур өметләр баглавы. Шигырьдәхис-кичерешләр, уй-фикерләр тасвирлану. Шигъри сөйләм турында төшенчә. ***– 1 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Г.Тукай**. *“Таз”, “Сабыйга”*.

Уку һәм анализлау өчен:

**Ф.Әмирхан**. Язучы турында белешмә. *“Нәҗип”*. Хикәянең сюжеты. Нәҗип кичерешләренең самимилеге, кичерешләрдәге борылышлар. Хикәя турында төшенчә. ***– 3 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Ибраһимов**. Язучының кыскача иҗат биографиясе белән таныштыру. *“Алмачуар”*. Авыл малаеның табигатькә якынлыгы, атка мәхәббәте, аңа бәйле хыяллары, хыялның җимерелүе. Пейзаж турында төшенчә. ***– 3 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**Һ.Такташ**. Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә. “*Ак чәчәкләр*”, *“Урман”* (өзек). Табигать күренешләренең төгәл чагылдырылуы. Шагыйрь күңелендә дөньяга соклану, яшәү куанычы хисләренең тууы. Җанландырылган табигать образлары. Лирик герой турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Һ.Такташ**. *“Картайдым шул”, “Пи-би-би-бип”*.

Укып фикер алышу өчен:

**Ә.Еники**. Тәрҗемәи хәле турында кыскача белешмә. *“Курай”* (баштагы ике кисәк). Әсәрне уку, эчтәлеген сөйләү. Әсәрнең халык иҗаты белән уртаклыгы. Курай һәм курайчы образы: моңның кеше күңеленә тирән тәэсирен ачу. ***– 2 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**Г.Кутуй**. Язучының тормыш юлы. *“Сагыну”*. Лирик герой кичерешләрендә Туган ил образы. Нәсер турында төшенчә. Инверсия. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**М.Җәлил**. *“Җырларым”*. Шагыйрьнең эчке ышанычы, өметләре, Шигъриятне зурлавы. *“Ана бәйрәме”, “Кызыл ромашка”*. Фаҗига, драматизм белән батырлык, фидакарьлекнең үрелеше, Табигатьнең боларга актив мөнәсәбәте. Предметларны. Табигатьне җанландырып сурәтләү. Рифма турында төшенчә. ***– 3 сәгать***

<u>Дәрестән тыш уку өчен</u>:

**С.Хәким**. *“Колын”.*

***Региональ компонент:*** **Я.Зәнкиев**. *“Кайчыколак”, “Кылый күз”* (укытучы һәм укучылар сайлавы буенча).

<u>Укып фикер алышу өчен</u>:

**А.Алиш**. Язучының тәрҗемәи хәле турында төшенчә бирү. Әкиятләре турында гомуми фикерләр, халык авыз иҗатына якынайткан яклары. А.Алиш әкиятләрендәге образлар системасы, төп мотивлар, детальләр байлыгы, җанлы һәм җансыз табигатькә мәхәббәт тәрбияләү чаралары. ***– 3 сәгать***

<u>Уку һәм анализлау өчен</u>:

**М.Кәрим**. *“Озын-озын балачак”* (өзекләр). Әсәр героеның табигать һәм кешене аңлаудагы үзенчәлекле юлын сурәтләү. Тормыш закончалыкларын, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлау-аңлатуда Олы инәй образының роле. ***– 3 сәгать***

<u>Укып фикер алышу өчен</u>:

**Ш.Галиев**. Балалар өчен шигырьләре. Балалар дөньясының конкрет вакыйгаларда, предмет-сыйфатларда чагылышы. Дөньяны танып белүнең, тәҗрибә туплау, ачыш ясауның шаянлык һәм җорлык, юмор теле белән тасвирлануы. Юмор һәм сатира турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

<u>Уку һәм анализлау өчен</u>:

**Г.Сабитов**. *“Ярсулы яз”* хикәясе. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылуы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен, табигатьне бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау. Телнең сурәтлелеге. ***– 2 сәгать***

<u>Дәрестән тыш уку өчен</u>:

**Н.Дәүли**. “*Язмышка юл”* (бүлекләрне укытучы һәм укучылар сайлап ала)

<u>Уку һәм анализлау өчен</u>:

**А.Расих**. Язучының кыскача тәрҗемәи хәле белән таныштыру. *“Хәвефле сынау”* повесте. Әсәрдә маҗаралылык, реаль чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлекләре. Маҗаралы жанр турында гомуми мәгълүмат бирү. ***– 2 сәгать***

<u>Укып фикер алышу өчен</u>:

**Н.Исәнбәт**. Язучының тәрҗемәи хәле. *“Хуҗа Насретдин”* (кыскартып алына). Үзәк геройда халык авыз иҗатыннан килә торган сыйфатларның (җорлык, тапкырлык, акыл көче ярдәмендә дошманнарын җиңү) туплап бирелеше. Хуҗа Насретдин – халыкның зирәклеген һәм үлемсезлеген раслаучы образ. Комедия турында төшенчә. ***– 4 сәгать***

## Ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр

Г.Тукай. “Шүрәле” (I бүлек), “Пар ат”.

М.Җәлил. “Җырларым”.

Ф.Кәрим. “Кыр казы”.

Г.Кутуй. “Сагыну”.

Ш.Галиев. “Тамаша”.

***Региональ компонент:*** Б.Сөләйманов “Китүләре бигрәк авыр икән” [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б. 48].

# VI СЫЙНЫФ
# (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 50 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 12 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 6 сәгать**

Җырлар, такмаклар турында кыскача мәгълүмат бирү.

Уку һәм анализлау өчен:

*"Гөлҗамал", Көзге ачы җилләрдә".*

Җыр турында төшенчә. Халыкның рухи тормышында җырның роле. Аның көй белән бергә яшәве. Көйләрдә моңның әһәмияте. Борынгы һәм хәзерге җырлар. Магнитофон язмасында җырлар тыңлау. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

*"Ай, былбылым", "Сабан туе", "Шома бас".* Озын һәм кыска җырлар, такмаклар турында төшенчә. Аларда кеше халәтенең төрле яклары чагылу. Укучыларга җырлар язып килергә тәкъдим итү. ***– 1 сәгать***

***Региональ компонент:*** *"Мин бер серле"* (Себер гимны. Хәсән һәм Хөсәен Арангуловлар музыкасы, З.Арангулова башкаруында) [Б.Сөләйманов. Мин Себер татарымын. – Екатеринбург, 1998. – Б. 40]. Аларның тематикасы, характеры.

Дәрестән тыш уку өчен:

Халык җырлары. *"Бер алманы бишкә бүләек", "Әпипә", "Иске карурман", "Ашказар", "Азамат", "Сандугач"* (укытучы һәм укучылар сайлавы буенча).

Уку һәм анализлау өчен:

Г.Тукай. *"Әллүки".* Шагыйрьнең халык көенә, моңына тирән мәхәббәте. *"Өзелгән өмет".* "Тәфтиләү көенә җырлана торган бу җырда лирик геройның моңсу хисләре гәүдәләнеше.

Авторы мәгълүм әсәрләрнең халык көенә җырлануы. ***– 2 сәгать***

Дәрестән тыш уку һәм ятлау өчен:

**Г.Тукай**. *"Туган тел".*

***Региональ компонент:*** **Б.Сөләйманов**. *"Мин төп Себер татарымын чыгышым белән"* [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б. 84].

Уку һәм анализлау өчен:

**Г.Камал.** *"Беренче театр".* Әсәрдә чагылган конфликтның иҗтимагый әһәмияте. Образларның үзенчәлекле сыйфатлары. Искелек гәүдәләнеше буларак Хәмзә образы.

Г.Камал иҗаты турында кыскача белешмә. Конфликт турында төшенчә. Комедия турындагы белемнәрне киңәйтү. ***– 3 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**С.Рәмиев**. *"Уку", "Таң вакыты", "Авыл", "Мин".* Шигырьләрдә мәгърифәткә, белемгә өндәү, рухи уянырга чакыру, шәхес азатлыгын, куәтен данлау. Туган якка мәхәббәт. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле белән таныштыру. ***– 2 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

***Региональ компонент:*** **Г.Абайдуллина**. *“Яратам мәктәбемне”, “Туган тел турында мөнәҗәтләр”* [Мин – Себер татарымын! – Казан, 2006. – Б. 114, 119]. **Г.Абдрахманова**. *“Уян, татар”* [Г.Абдрахманова. Себер ягым. – Төмән, 2003. – Б. 55]. **Ш.Гаделша**. *“Яңа уй”* [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б.79].

Уку һәм анализлау өчен:

**Ә.Фәйзи**. *“Тукай”*. Романны дәрестә һәм өйдә уку. Тукай язмышы, бу язмышның төрле борылышларга бай булуы. Бу борылышларның халык язмышына бәйлелеген күрсәткән ситуация һәм вакыйгалар. Тукайның халык баласы булуы.

Ә.Фәйзинең тәрҗемәи хәле турында кыскача белешмә бирү. ***– 5 сәгать***

**Х.Туфан**. *“Гөлләр инде яфрак яралар”, “Моабитны күрдем төшемдә”, “Иртәләрем, кичләрем”, “Каеннар сары иде”, “Илдә ниләр бар икән?, “Чәчәкләр китерегез Тукайга”*. Шагыйрь әсәрләрендәге хисләр драматизмы, фәлсәфи тирәнлек, сәнгатьчә нәфислек.

Строфа турында төшенчә. Х.Туфан шигырьләренең кайбер үзенчәлекләре.

Шагыйрьнең тормыш юлы белән таныштыру, иҗатына кыскача характеристика. ***– 3 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Х.Туфан**. *“Киек казлар”, “Кайсыгызның кулы җылы?”, “Аралагыз мине”, “Алмаз”*. Хисләрне табигать фонында, кошлар, җәнлекләр язмышы белән бәйләп яки күчерелмә рәвештә аңлату. *“Алмаз”* шигырендә туган телгә мәхәббәт, аның мәңге яшәргә тиешлеге идеясенең чагылышы. Күчерелмә мәгънә турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**Г.Ибраһимов.** *“Кызыл чәчәкләр”*. Сыйнфый көрәшнең кешеләр язмышына тәэсире: бергә үскән малайларның алга таба көрәш эчендә төрле сукмактан китүе, бер-берсенә дошман булып әверелүе. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**М.Гафури**. “*Үзем һәм халкым”, “Мин кайда?”, “Кызыл байрак”* (укытучы һәм укучылар сайлавы буенча).

***Региональ компонент:*** **Я.Зәнкиев**. *“Ана йөрәге”* [Я.Зәнкиев. Кайчыколак. – Төмән, 1994. – Б. 46].

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Гобәй**. *“Маякчы кызы”*. Гражданнар сугышы картиналарының тасвирлануы, бу көрәштән балаларның да читтә кала алмавы. Илсөяр, Бикмүш карт образлары. Әсәрдәге маҗаралылык, бала өчен серлелек элементларының роле. ***– 3 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**И.Юзеев**. Иҗаты белән кыскача гына таныштыру. *“Бакчачы турында баллада”, “Йолдыз кашка турында баллада”*. Баллада турында башлангыч мәгълүматлар. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**И.Гази**. Тәрҗемәи хәле. *“Кызыл томаннар артында”, “Мәүлия нигә көлде?”, “Өч Мәхмүт”*. И.Газинең хикәя иҗат итүдәге осталыгы, сурәтләрнең

тыгызлыгы, лирик, юмористик төсмерләргә байлыгы, гыйбрәтле хәлләрнең яктыртылуы, характерлар аныклыгы. ***– 4 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**Ч.Айтматов**. *“Беренче мөгаллим”*. Мәгърифәтне зурлау мотивларының көчле чагылышы. Дүшән һәм Алтынай образлары. Әсәрдә тугандаш кыргыз халкының гореф-гадәтләре чагылышы. Язучының тормышы, иҗаты, ата-анасы хакында кыскача мәгълүмат бирү. ***– 4 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Р.Миңнуллин.** “*Энекәш кирәк миңа!”, “Әни, мин көчек күрдем”*. Шигырьләрдә шаянлык, нечкә юмор аркылы олы фикерләр әйтү, шәфкатьлелек тәрбияләү. “Кунак егетләр”. Татарча көрәшнең милли, шул ук вакытта башка халыклар өчен дә кызыклы һәм үз булырлык якларын күрсәтү ярдәмендә халыкның матур гореф-гадәтләрен зурлау. *“Батырлык эшләр идем”.* Бала күңеленең нечкәлекләрен мөлаем юмор ярдәмендә чагылдыру. *“Шундый минем туган ягым”, “Кайтыйк ла үзебезгә!”.* Туган илгә, туган якка мәхәббәтне бала исеменнән оста әйтеп бирү. ***– 2 сәгать***

**Л.Ихсанова.** Язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. *“Наил һәм Фаил”.* Үзәк геройның шуклыгы, хаталары, холкы. Фаилнең иптәшләре. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен**:**

**Т.Миңнуллин.** *“Авыл эте Акбай”* пьесасы.

Уку һәм анализлау өчен:

**М.Мәһдиев.** Тәрҗемәи хәле. *“Без – кырык беренче ел балалары”.* Бөек Ватан сугышы авырлыкларының әсәрдә чагылышы. Яшүсмерләр образы. Персонаж һәм вакыйгаларны нечкә юмор белән сурәтләү. “Мин” образы, аның бирелү үзенчәлеге. ***– 4 сәгать***

***Региональ компонент:*** **Б.Сөләйманов** *“Бүләк”* [Б.Сөләйманов. Мин Себер татарымын. – Екатеринбург, 1998. – Б.218].

Укып фикер алышу өчен:

**Ф.Яруллин.** Язучының тормыш юлы һәм иҗаты. *“Иң гүзәл кеше икәнсез”.* Шигырьдә укытучыга соклану хисенең зурлыгы, шул соклану һәм зурлауны күрсәтү өчен китерелгән чагыштырулар. *“Әйбәт тә минем әби”, “Гайни”, “Ялкау ялы”.* Шигырьләрдә бала рухын чагылдыру үзенчәлекләре. *“Ак төнбоек”.* Кешегә яхшылык эшләүнең күркәм гадәт икәнен, әмма аны һәрчак искә төшереп торуның кире тәэсир ясавын оста күрсәтү. ***– 3 сәгать***

### Ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр

Туган ил турында халык җырлары (укытучы сайлавы буенча).
Г.Тукай. “Туган авыл”.
Х.Туфан. “Гөлләр инде яфрак яралар”, “”Алмаз”.
Г.Ибраһимов. “Кызыл чәчәкләр” (“Башлангыч” дигән бүлек).
Р.Миңнуллин. “Әни, мин көчек күрдем”.

***Региональ компонент:*** **Б.Сөләйманов**. *“Мин төп Себер татарымын чыгышым белән”*

# VII СЫЙНЫФ
# (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 47 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 17 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 4 сәгать**

Уку һәм анализлау өчен:

Мәкальләр һәм әйтемнәр. (Н.Исәнбәт бастырган 3 томлыктан, ***Региональ компонент:*** Л.Хәбибуллина "Туган як әдәбияты. 1 кисәк" 45-47 битләрдән файдаланырга). Тугандаш халыклар мәкальләреннән үрнәкләр. Мәкаль һәм әйтемнәрдә халык зирәклегенең, күзәтүчәнлек, гомумиләштерү сәләтенең, фәлсәфи карашлар, әхлак принципларының чагылышы. Аларның җыйнаклыгы, фикер тыгызлыгы, шигърилеге, телбизәк чаралары. Укучыга яңа мәкаль-әйтемнәр язып килергә тәкъдим итү. Мәкаль һәм әйтем турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

*"Сөембикә бәете"*. Сөембикә образында гүзәллек белән легендарлык, бөеклек белән фаҗиганың бергә үрелүе. Бәетнең сәнгатьчә эшләнеше.

Бәет турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

*"Сак-Сок"* бәете.

Уку һәм анализлау өчен:

**К.Насыйри**. Язучының тәрҗемәи хәле белән таныштыру. *"Әбугалисина"* (өзекләр). Әсәрдә акыл көче, гыйлем куәтен раслау, аларның тылсымлы нәтиҗәләрен күрсәтү. Гыйлемне явызлыкка түгел, шәфкатьлелеккә хезмәт иттерү идеясы. Әбугалисина һәм Әбелхарис образлары. ***– 2 сәгать***

**Г.Тукай**. *"Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш"*. Әсәрнең дини рухтагы борынгы "Кисекбаш" поэмасы формасында язылуы. Вакыйгаларның реаль җирлеккә күчерелүе, мифологик образларның шул заманның конкрет шәхес образлары белән аралашып килүе, үзенчәлекле әкияти сюжет ярдәмендә чын картиналар тасвирлау. Кисекбаш образы, аны сыйфатлауда кулланылган гиперболик алымнар. Җанландыруның сатирик максатка хезмәт итүе. Гипербола төшенчәсе. ***– 3 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Исхакый**. Язучының тәрҗемәи хәле белән таныштыру. *"Кәҗүл читек"*. Баланың рухи дөньясын тормышчан ситуациядә һәм төгәл детальләр ярдәмендә ачып бирү. ***– 2 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**Дәрдемәнд**. Шагыйрь турында белешмә. *"Кораб", "Рәсем", "Урысча күп сүзең...", "Куанды ил,,,", "Җәй үтте...", "Видагъ"*. XX гасыр башындагы иҗтимагый фикернең шагыйрь иҗатында чагылышы, авторның аңа үзенчәлекле мөнәсәбәте. Милләт язмышын ил корабы, давыл, дулкын, упкын образларында сурәтләү. Шигырьләрдәге моңсулык, каршылыклы кичерешләр чагылышы. Шагыйрьнең ватанпәрвәрлеге. Туган илгә, туган телгә кайнар мәхәббәте. Шигырь-парчаларының сәнгатьчә камиллеге, нәфислеге. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**К.Тинчурин**. Язучы турында белешмә. *“Җилкәнсезләр”* (өзекләр). Комедиянең конфликт үзенчәлеге. Сатирик типлар. Батырхан образы. Көлү алымнары. ***– 5 сәгать***

**М.Әмир**. Язучы турында кыскача белешмә. “Агыйдел” (өзекләр). Студент яшьләрнең авылда аң-белемне күтәрү, күмәк хуҗалык төзү өчен көрәшләре, бу юлдагы кашылыкларны җиңеп үтүләре. Гаяз, Ильяс, Артыкбикә образлары. Әсәрнең лиризмы. Повесть турында төшенчә. ***– 5 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**С.Хәким**. Иҗаты турында белешмә. *“Юксыну”, “Әнкәй”*. Кешедәге табигый халәтнең – интим-моңсу, гуманистик хисләрнең чагылышы. Анага эчкерсез мәхәббәт хисләре. *“Тегермән стенасындагы язулар”*. Шагыйрьнең детальләрдә авыл язмышын, халыкның авыр тормышын күрсәтә белүе. *“Һәйкәл урынында уйланулар”*. Җәлилчеләрнең җыелма образын сынландыру омтылышы. ***– 3 сәгать***

**Ф.Хөсни**. *“Йөзек кашы”*. Әсәрдә лирик якты хисләрнең тасвирлануы, мәхәббәтнең үкенечле соңы. Айдар холкының үзенчәлекләре. Повестьның истәлеккә корылган булуы.

Типиклык төшенчәсе. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Ә.Фәйзи**. “*Әүхәдинең хатыны Майшәкәр белән саубуллашуы”, “Бал корты”, “Габдулла Тукайга”* (сайлап алына).

***Региональ компонент:*** **Б.Сөләйманов** *“Абу баба”* [Б.Сөләйманов. Мин Себер татарымын. – Екатеринбург, 1998. – Б.121].

Уку һәм анализлау өчен:

**Ф.Кәрим**. Шагыйрь һәм аның иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирү. *“Ант”, “...Сөйләр сүзләр бик күп алар”, “Ватаным өчен”*. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясенә хас булган хисләр кайнарлыгын, шул ук вакытта аларның гади, самими яктыртылышын күңелгә үтемле, тәэсирле сурәтләр ярдәмендә бирү. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Ф.Кәрим**. *“Кыңгыраулы яшел гармун”*. Фазыл образында гади солдатның кешелек сыйфатлары, ватанны ярату чагылышы. Поэмада оптимистик рух.

Поэма турында төшенчә. ***– 1 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Р.Мөхәммәдиев**. *“Муенсалы күгәрчен*”.

Уку һәм анализлау өчен:

**Ә.Еники**. *“Әйтелмәгән васыять”*. Халыкның рухи байлыгына, гореф-гадәтләре, теле, сәнгатенә әхлак нормаларына сак мөнәсәбәт, өлкәннәргә хөрмәт, киң күңеллелек мәсьәләләренең куелышы һәм сәнгатьчә хәл ителеше. Акъәби образы. Аның уй-фикерләре. Пейзаж картинасы. Аның бөтен әсәр рухын, моңын, аһәңен билгеләве. Проблема төшенчәсе. ***– 4 сәгать***

**Н.Арсланов**. *“Атлантида”, “Яз”, “Тәлгәш-тәлгәш миләш”, “Халкыма”*. Шигырьләрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсе һәм фәлсәфи тирәнлеге, форма ягыннан камиллеге. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Ахунов**. Язучының тәрҗемәи хәле белән таныштыру. “*Артышлы тау буенда”*. Повестьта авыл малаеның нефтьчеләр сафыеа килү юлы сурәтләнү. Хәсән холкына хас сыйфатлар; аның мавыгучанлыгы, атка, соңыннан техникага мәхәббәте. Ялгышу аша шәхес буларак формалаша башлавы. Повестьның һәр бүлегендә уздырылган фикер, аларның әсәрдәге төп идеяны үстерүләре. ***– 4 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Х.Сарьян**. *“Бер ананың биш улы”* (өзекләр). Әсәрдә кешенең тормышка мөнәсәбәтен, җаваплылык хисен тасвирлау үзенчәлекләре. Шәхси язмышның нинди булуында халык язмышының роле. Балаларның анага мөнәсәбәтен күрсәтүдә уңышлар. Хикәяләүче образы.

Тема турында төшенчә. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Рәдиф Гаташ**. Шигырьләр (укытучы һәм укучылар сайлавы буенча).

**Ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр**

Дәрдемәнд. “Кораб”, “Атам-анам йорты өчен...”.

Ә.Фәйзи. “Габдулла Тукайга”.

Ф.Кәрим. “,,,Сөйләр сүзләр бик күп алар”, “Кыңгыраулы яшел гармун” (өзек).

М.Әмир. “Агыйдел” повестеннан “Агыйдел рәсемдәге төсле матур...” дип башланган өзек.

Р.Гаташ шигыре (укытучы сайлавы буенча).

***Региональ компонент:*** Ш.Гаделша “Черкине сагынам” [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б. 84].

## VIII СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 46 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 16 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 6 сәгать**

Уку һәм анализлау өчен:

*“Идегәй”*. Дастан героеның тарихи җирлеге. Ватан һәм милли азатлык мәсьәләләренең хәл ителеше. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше, тел байлыгы. Дастан турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Ф.Кәрими**. *“Салих бабайның өйләнүе”* (телен гадиләштереп һәм кыскартып алына). Хикәядә шул чордагы гореф-гадәтләрнең, кешеләр арасындагы күркәм мөнәсәбәтләрнең төгәл чагылдырылуы. Салих карт холкындагы уңай сыйфатлар, кайбер ярамаган шөгыльләре.

Мәгърифәтчелек әдәбияты һәм мәгърифәтче язучылар турында кыскача белешмә. ***– 2 сәгать***

Уку һәм анализлау өчен:

**М.Фәйзи**. Драматург турында белешмә. *“Галиябану”*. Рольләргә бүлеп уку. Олы, саф мәхәббәтнең иҗтимагый тигезсезлек белән бәрелешүе. Бу конфликтның хәл ителешендә кешеләр холкының роле. Галиябану, Хәлил, Исмәгыйль образлары. Әсәр тукымасында реалистик һәм романтик алымнар. Сәнгатьле детальләрнең роле. Татар сәнгатендә музыкаль драма туу. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Ш.Камал**. Тормыш юлы турында кыскача белешмә. *“Акчарлаклар”* (бер бүлеге). Әсәрдә сезонлы эшчеләр тормышының яктыртылышы. Гариф, Газизә, Шәрәфи карт образлары. Үзара мөнәсәбәтләрдәге җылылык, эчкерсезлек, самимилек. ***– 3 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Ш.Бабич**. *“Халкым өчен”*. Укытучы һәм укучылар сайлавы буенча тагын 2-3 шигыре.

Уку һәм анализлау өчен:

**Һ.Такташ**. Шагыйрь иҗаты турында тулырак мәгълүмат бирү. *“Алсу”*: яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләре чагылышы; *“Киләчәккә хатлар”*: утызынчы еллар башындагы иҗтимагый тормышның, социаль-психологик каршылыкларның киң күренешен сурәтләү, киләчәккә ныклы ышаныч белдерү. Поэмада хат формасы. Идея турында төшенчә. ***– 3 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Һ.Такташ**. *“Мәхәббәт тәүбәсе”*.

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Бәширов**. *“Туган ягым – яшел бишек”* (өзекләр). Халыкның ерак тарихтан килә торган яшәү рәвеше, рухи байлыгы, әхлак кагыйдәләре. Гореф-гадәтләрне чагылдыру. Әсәрнең автобиографик хасияте. Язучы турында кыскача белешмә. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Р.Фәйзуллин**. *“Якты моң”, “И, кардәшем”, “Бер хаҗәтсез кайчак...”, “Бишбармак”, Гөмбәзләре – кояшмыни!”, “Үлем белән үлемсезлек”* (укытучы сайлавы буенча).

Уку һәм анализлау өчен:

**М.Җәлил**. *“Тик булса иде ирек”, “Соңгы җыр”, “Серле йомгак”*. М.Җәлилнең гражданлык һәм поэтик батырлыгы турында тулырак белешмә бирү. Шигырьләренең язылу шартлары. Лирик геройларның ireккә, көрәшкә омтылышы. Яу кырында сугыша алмау үкенече, моңсулык. Лирик герой һәм шагыйрь хисләренең бердәмлеге төшенчәсе. *“Сандугач һәм чишмә”*. Поэтик предмет һәм җан ияләрен кешечә хис итәргә сәләтле итеп сурәтләү. Кош һәм чишмә образлары ярдәмендә Туган ил азатлыгы өчен фидакарь көрәшнең изгелеген раслау. ***– 4 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Г.Әпсәләмов**. Язучының биографиясе. *“Алтын йолдыз”* (өзекләр). Романда яшьләрнең романтик образлары. Холык-омтылышларның сугыш кырында сыналуы. Әсәрдә романтик пафос. Роман турында төшенчә. ***– 4 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Р.Төхфәтуллин**. *“Йолдызым”*.

Уку һәм анализлау өчен:

**М.Юныс**. Язучы турында кыскача белешмә. *“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”*. Повестьның тормыш материалыннан чыгып икегә бүленүе, бу өлешләрдә хикәяләү үзенчәлекләре. Образлар системасы. Повестьта уздырылган фәлсәфи фикерләр, хикәяләүдә табигыйлек. ***– 3 сәгать***

**Г.Афзал**. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми характеристика. *“Дөнья матур, дөнья киң”* һ.б. шигырьләрендә (укытучы сайлавы буенча) Туган ил, туган җир, халкыбыз турындагы шигъри сурәтләр. *“Мыштыбый”*. Юмор аша кеше батырлыгының чагылыш байлыгын күрсәтү.

*“Тәнкыйть сүзе», “Ялкау кызлар”, “ӨФ-өф итеп”*. Көлү объектлары һәм предметлары. Аларның халыкчан җирлекләре һәм халыкчан чаралар кулланылу. Сатира турында төшенчә. ***– 2 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**Н.Фәттах**. Язучы иҗаты белән таныштырую *“Итил суы ака торур”* (өзекләр). Болгар дәүләте тормышын, кабиләләр тартышын, гореф-гадәтләр, йолаларын, сәүдә, мәдәният, дин мөнәсәбәтләрен, геройларның хисләрен тасвирлау. Сюжетка киеренкелек һәм җанлылык бирүдә Тотыш холкының роле. Тарихи роман турында төшенчә. ***– 5 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**Р.Батулла**. *“Сөенбикә”* романы.

Уку һәм анализлау өчен:

**Т.Миңнуллин**. Драматург турында белешмә. *“Бәхетле кияү”*. Авыл кешеләре арасындагы эчкерсез, саф мөнәсәбәт һәм мөгамәләрнең кызыклы ситуациядә ачылуы һәм сурәтләнүе. Мөлаем, яратып көлү өчен кулланылган чаралар. ***– 5 сәгать***

Укып фикер алышу өчен:

**А.Гыйләҗев**. *“Язгы кәрваннар”*. Сугыш чоры яшьләренә килгән тормыш һәм хезмәт авырлыкларының чагылышы. Күңел төшенкелегенә бирелмәү, яшьлек хисләренең юл яруы. Эчке кичерешләрнең төгәл чагылдырылуы. Язучы турында белешмә. ***– 3 сәгать***

Дәрестән тыш уку өчен:

**А.Расих**. *“Урланган хәзинә”.*

Уку һәм анализлау өчен:

**С.Сөләйманова**. “*Туган җирем, эчкән суым”, “Кеше барыбер кош нәселеннән...”, “Кеше”, “Сулар ага, күлләр күккә бага...”, “Этюд”, “Тагын узды кыңгыраулы язлар...”*. Бу шигырьләрдәге хисләр байлыгы, күңел тирбәнешләренең табигыйлеге, поэтик бизәкләргә муллык. Сүз белән сурәт ясау осталыгы. ***– 4 сәгать***

***Региональ компонент: Б.Сөләйманов*** *“Әйтмәгез Себерем хакында”, “Кәренәме Себер Казаннан?”, “Казанга”* [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б.50-61].

Дәрестән тыш уку өчен:

**Ш.Галиев**. *“Камырша”, “Утсыз төтен булмый”, “Үзең нинди”, “Тимерче Гомәр һәм гомер”*.

**Р.Харис**. *“Ант суы”, “Борылышта”* (сайлау буенча).

**Ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр**

“Идегәй” (“И Идел йорт, Идел йорт...” дип башланган өзек).

Ш.Бабич. “Халкым өчен”.

Һ.Такташ “Алсу”.

М.Җәлил. “Кичер, илем!”.

Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Ш.Маннапов шигырьләре (укытучы сайлавы буенча).

***Региональ компонент:*** Ш.Гаделша *“Себер татары”* [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б.85].

## IX СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 50 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 6 сәгать**
**Кабатлау – 4 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 8 сәгать**

**Кереш – *1 сәгать***

Тарихи-әдәби процесс һәм аның үзенчәлекләре.Матур әдәбиятның кеше тормышында тоткан мөһим урыны.

Татар әдәбиятының халык һәм милләт язмышында уйнаган роле. Аның үсеш баскычлары: меңьеллык әдәбиятыбыз тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе. Бу бүленештә әдәбиятның үз эчке закончалыклары һәм үсеш тенденцияләре, аларның үзәгендә кеше шәхесенә мөнәсәбәтнең ятуы.

Кешенең һәм татар халкының борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр сузылган тормышын һәм яшәү рәвешен сәнгатьле чагылдыручы буларак татар әдәбияты.

Әдәбият теориясе. Матур әдәбиятның милли үзенчәлеге турында төшенчә бирү.

**Төрки-татар әдәбиятының чыганаклары – *4 сәгать***

Татар әдәбиятының халык авыз иҗаты һәм мифология белән бәйләнеше. Фольклордан килә торган аваз-мотивлар һәм сәнгатьлелек ысул-чаралары, алымнары.

Рун язулы истәлекләр. *“Орхон-Енисей язмалары”нда* алга таба әдәбиятта үстерелеш тапкан фикер-мотивларның чагылышы.

Уйгур язулы истәлекләр. **Мәхмүд Кашгарыйның** “*Дивану лөгат әт-төрк”* китабы – борынгы төркиләрнең мәдәниятен, шул җөмләдән фольклор һәм әдәбиятын өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак. Борынгы дидактик әдәбият үрнәге буларак, **Й.Баласагунлының** *“Котадгу белек”* поэмасы. Андагы төп фикер, поэманың сәнгатьчә эшләнеше. Бу әсәрләрнең төрки-татар язма әдәбиятына тәэсире. **Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани** иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү. Шәрык әдәбиятының тәэсире.

Коръән, аның кыскача эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше. Коръән сюҗетларының әхлакый һәм рухи эчтәлеге, аларның әдәбиятка тәэсире, алга таба татар әдәбиятында сәнгатьле дәвам иттерелүе һәм үстерелүе.

Ислам дине һәм төрки-татар мәдәнияте. Әдәбиятның иҗтимагый тормыш белән бәйләнеше. Язучының җәмгыять тормышында биләгән үзенчәлекле аерым бер урыны.

Әдәбият теориясе. Матур әдәбиятның иҗтимагый вазифасы.

**Болгар чоры әдәбияты –** ***4 сәгать***

Кереш. Идел – Кама буендагы Болгар дәүләте. Анда мәдәниятнең чәчәк ату үзенчәлекләре. Әдәбият һәм сәнгатьнең югары сыйфатын дәлилләгән фактлар.

**Кол Гали**. *"Кыйссаи Йосыф"*. Шәхес һәм шагыйрь буларак Кол Гали турында мәгълүматлар. Дастанның язылу вакыты һәм урыны, бүгенгәчә саклану һәм өйрәнелү дәрәҗәсе.

Дастан-поэманың төп сюжет сызыгы буенча охшаш әсәрләргә нисбәте. Фирдәүси һәм Кол Гали.

"Кыйссаи Йосыф" әсәрендә автор әйтергә теләгән төп фикерләр. Бу фикерләрне уздыруда Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәте сызыгының роле. Сюжетта кешеләрне ярату (гуманизм), гаделлек карашларының чагылышы. Ислам дине алга сөргән гомумкешелек идеалларын җирдәге тормыш вакыйгаларында җанландыру. Әсәрнең нигезендә яткан, мөселман дине мәҗүсилектән өстен һәм бердәнбер дөрес дин дип, күп Аллага табынуның хаталыгын раслаган концепцияне сәнгатьле итеп бирү өчен Йосыф һәм Зөләйха образларының каршы куелып тасвирлануы. Йосыфның рухи ныклыгы, иманына тугрылык саклавы, мәрхәмәтле булуы, акылны хистән өстен куюы, туганлык-кардәшлек тойгы-хисләрен алга сөрүе. Мәхәббәткә тугрылык идеалы буларак Зөләйха образы. Хыянәт, саранлык, тотнаксызлык, хөсетлек, үчлек кебек кешегә ят булырга тиешле сыйфатларны кире каккан күренеш-ситуацияләрнең сюжет сызыгына оста кертелүе. Язмыш кысаларында кешенең үз гамәлләренә үзе җаваплы һәм ирекле булуын раслау, шуның белән кешене олылау. Аның шәхес буларак рухи дөньясын бай итеп сурәтләү.

"Кыйссаи Йосыф" поэмасының сәнгатьчә эшләнеше. Композицион төзелеше. Шартлылык һәм фантастиканың, романтика һәм реалистик җанлылыкның, символиканың үзара тыгыз аралашып килүе, аларның укучыга эстетик тәэсире. Поэтик детальләргә игътибар, аларның халыкчанлыгы һәм сәгатьлелеге. Әсәрнең традицияләргә тугрылыгы һәм новаторлыгы.

"Кыйссаи Йосыф" әсәренең татар әдәбиятында ясаган тәэсире, алга таба үстерелгән традицияләре.

Әдәбият теориясе. Урта гасырлар әдәбиятында дастан жанры. Иҗатта традицияләр һәм яңалык (новаторлык).

**Алтын Урда чоры әдәбияты –** ***4 сәгать***

XIII йөз урталарыннан алып XV йөз башына кадәр дәвердә болгар-татар мәдәнияте, әдәбияты һәм сәнгатьнең торышы турында кыскача мәгълүмат

бирү.Бу чор әдәбиятында иҗтимагый тормышның, сәясм һәм икътисади хәлләрнең чагылышы. Төп мотивлар һәм геройлар.

**Котб, Харәзми, Хисам Кятиб, Мәхмүд Болгари, Рабгузи, Әхмәд Үргәнчи** һ.б. язучылар әсәрләре, аларда чагылган суфичылык мотивлары турында кыскача мәгълүматлар. Суфичылыкның кеше шәхесен аңлауда уңай һәм кайбер бәхәсле яклары. Бу чор әдәбиятында дөньяви мәсьәләләрнең куелышы һәм сәнгатьле хәл ителеше. Жанрлар үсеше, әсәрләрнең поэтик төзелешендә, тел-сурәтләү чараларында һ.б. яңалыклар.

**Сәйф Сараи.** Шагыйрьнең тормышы турында мәгълүматлар. Иҗат эшчәнлеге. Сәгъдинең *“Гөлстан”* әсәрен *“Гөлстан бит-төрки”* исеме белән ирекле тәрҗемә итүе. Сәгъдидән килә торган фикерләрне тәрҗемәченең үзенекеләре белән аралаштыруы. Сәйф Сараиның тәрҗемәче буларак уңышлары.

Сараиның оригиналь әсәрләре, аларның үзенчәлекләре. Шагыйрьнең фәлсәфи уйланулары, аның әсәрләрендәге төп фикерләр: яшәү-үлем, тормышка мөнәсәбәт, яшәүнең төп мәгънәсе, хезмәт һәм иҗатның роле, табигатьнең үлемсезлегеһәм роле һ.б.

Шагыйрь иҗатында мәхәббәт, яшьлек һәм картлык, галимлек һәм наданлык, тугрылык һ.б. мәңгелек темаларның хәл ителүе.

*“Сөһәйл вә Гөлдерсен”* дастаны. Идея-эстетик эчтәлеге, сәнгатьлелек ягыннан үзенчәлекләре. Дастанда сурәтләнгән табигать күренешләренең роле. Чагыштыру, метафоралар, аларның оригинальлеге. Дөньяны материалистик аңлауны чагылдырган детальләр, аларның ышандыру көче. Сәйф Сараи иҗатының татар әдәбияты өчен әһәмияте.

Әдәбият теориясе. Дидактик әдәбият турында төшенчә. Поэтик тәрҗемә, аның милли әдәбиятны үстерүдәге роле. Әдәби багланышлар. Жанр төре һәм жанр формасы буларак газәл, касыйдә. Шигырьләрдә рифма үлчәүләре турында мәгълүматлар.

**Казан ханлыгы чоры әдәбияты – *3 сәгать***

Кереш. Казан ханлыгында әдәбиятның үсеше, аңарда иҗтимагый һәм сәяси хәлләрнең чагылу дәрәҗәсе.

Сүз һәм графика сәнгатьләренең үзенчәлекле чагылышы буларак кабер ташлары (эпитафия). Легенда һәм риваятьләр. Аларда җәмгыять тормышының кайбер яклары гәүдәләнү һәм бу чор кешесенең рухи дөньясы чагылу үзенчәлекләре.

Дастаннар. *“Идегәй”* дастаны турында VIII сыйныфта алган белемнәрне киңәйтү. *“Дастаны Бабахан”* әсәре белән кыскача таныштыру.

Казан ханлыгы чоры әдәбиятының аерым вәкилләре **Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Өмми Камал** иҗатлары турында кыскача мәгълүмат.

Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чоры әдәбиятларыннан килә торган идея-эстетик мотивларның яңача дәвам иттерелүе.

**Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд**. Тәрҗемәи хәленә кагылышлы кайбер мәгълүматлар.

Мөхәммәдьярның әдәби әсәрләренә гомуми күзәтү. Алардагы уртак яклар (композицион төзелештә, тел-стилендә, халык авыз иҗатыннан файдалануда һ.б.)

“Төхфәи мәрдан” һәм “Нуры содур” поэмалары. Аларда гаделлек фикере, кешене яратуны алга сөрү. Лирик герой кичерешләренең табигыйлеге, гомумкешелек мәнфәгатьләреннән килеп чыгуы. Поэмада кеше тормышы һәм табигать күренешләренең чагылышы. Тел-сурәтләү чаралары.

Татар поэзиясен үстерүгә Мөхәммәдьяр керткән өлеш.

Әдәбият теориясе. Лирик герой турындагы төшенчәне киңәйтү.

**XYII йөздә әдәбият – *3 сәгать***

Бу чорда илдәге иҗтимагый-сәяси шартларның татар әдәбиятында үзенчәлекле чагылышы.

Татар милләтенең хәле: милли дәүләтчелек бетү, татар халкының колониаль коллыкка эләгүе. Моның мәдәнияткә, әдәбиятка тәэсире. Әдәбиятта татар халкының азатлык көрәше чагылу, мондый әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше.

Милләт язмышына бәйле төстә әдәбиятта суфичылык фәлсәфәсенең асылы һәм әсәрләрдә чагылышы. Милли бәйсезлек мотивларының көчле яңгыравы.

Бу чор әдәбиятына кыскача күзәтү (*“Дәфтәре Чыңгызнамә”, “Гайса улы Амәт”* һ.б.*). “Җәмигъ әт-тәварих”* әсәре турында мәгълүмат.

**Мәүлә Колый**. Тәрҗемәи хәле. Иҗаты, анда Казан ханлыгы җимерелгәннән соңгы чордагы татар әдәбиятының төп сыйфатлары чагылу. Суфичылык поэзиясенең югары гәүдәләнеше буларак бу иҗатның үзенчәлекләре, сәнгатьлелек дәрәҗәсе.

М.Колый “Хикмәтләр”е, аларның үзенчәлеге, идея-эстетик байлыгы, сәнгатьчә эшләнеше.

М.Колый поэзиясендә образлар системасы.

Әдәбият теориясе. Шигырь төзелеше турында урта сыйныфларда белгәннәрне искә төшерү һәм тагын да тулырак мәгълүмат бирү.

Поэзиядә стилистик фигураларның урыны һәм роле.

**XVIII йөздә әдәбият – *3 сәгать***

Бу чор татар әдәбиятында халыкның иҗтимагый-икътисади хәле чагылу дәрәҗәсе, әдәбиятның халык тормышына якыная баруы. Азатлык көрәшләрен сыйфатлаган әсәрләр. Сүз сәнгатенең үзенчәлекле гәүдәләнеше буларак Батырша хатлары. Пугачев хәрәкәтенең халык авыз иҗатында һәм язма әдәбиятта чагылуы.

**Габдессәлам, Габделмәннан Мөслим углы, Әхмәдбик, Таҗетдин Ялчыгол** һ.б. язучыларның иҗатларына гомуми күзәтү.

Әдәбиятта суфичылык: дидактик рухның көчәюе; дөньяви мотив-авазларның урын алуы. Боларның чагылышы буларак әдәбиятта илаһи бәет, дастан, сәяхәтнамә һәм риваять, мәдхия һәм мәрсия төрләренең активлашуы. Алардагы поэтик табышлар.

**Габдерәхим Утыз Имәни**. Иҗатына гомуми күзәтү. Тәрҗемәи хәле. Фәнни хезмәтлзәре. Шигырьләре, аларда гыйлемгә һәм мәгърифәткә хөрмәтле караш чагылу, кешене олылау, фикер хөрлеген яклау. Бу шигырьләрдәге лирик герой образының төп сыйфатлары.

Утыз Имәни – заманының алдынгы фикер иясе. Иҗатында әдәбиятның яңа сыйфат үзгәрешләрен, яңа баскычка күтәрелү үзенчәлекләрен чагылдыруы. Язучы һәм галимнең татар әдәбиятына һәм фәлсәфәсенә тәэсире.

Әдәбият теориясе. Урта гасырлар татар әдәбиятында жанр төрлелеге. Мәдхия һәм мәрсия.

***Региональ компонент:*** Шагыйрь **Әмдәми** иҗаты турында мәгълумат, шагыйрьнең “Нәсихатнамә” әсәрендә сифичылык фикерләре. Әсәрдә кеше өчен кирәкле, тәрбияләнергә тиешле сыйфатлар һәм, киресенчә, кешене яман юлга җибәрә торган гадәтләр турында фикер бирелеше. [Методик ярдәмлек: Ф.С.Сәйфулина “Региональ әдәбият”]

**Йомгак – *1 сәгать***

Урта гасырларда татар әдәбиятының үсеш юллары. Андагы төп мотив һәм тенденцияләр. Урта гасыр гуманизмының үзенчәлекләре. Кешене, аның җирдәге урынын һәм яшәү мәгънәсен аңлауда әдәбиятта үсеш баскычлары. Кеше образын сәнгатьле сурәтләүдә язучылар ирешкән уңышлар. Кеше белән җәмгыять бәйләнешен төшенә- үзләштерә бару.

Әдәбиятның сәнгатьлелеккә ирешүдәге казанышлары, тел-стильдә үсеш-үзгәрешләр, художестволы ачышлар. Борынгы телнең үзенчәлекләре, бүгенге телдән аермалы яклары, моның сәбәпләре, борынгы телдәнхалыкчан әдәби телгә күчеш баскычлары, бу юлда көч куйган күренекле шәхесләр.

Әдәбият теориясе. Тарихи-әдәби процесста әдәби бәйләнешләрнең роле. Әдәби иҗатта күчемлелек.

**XIX йөзнең беренче яртысында әдәбият – *3 сәгать***

XIX гасырдагы татар әдәбиятына кыскача бәяләмә-кереш. Татар әдәбияты һәм милләт тарихы. Җәмгыять тормышына, мәгърифәт үсешенә тәэсир иткән факторлар (Казанда университет һәм типографияләр ачылу һ.б.) Татарларның Россия һәм Европа эшләренә күбрәк катнашуы. 1812 елгы Ватан сугышында активлыклары. Декабристлар хәрәкәтендә татарлар. Милли тормышка торган саен ныграк тәэсир иткән европалашуның сүз сәнгатендә чагылуы. Бу чор әдәбиятында ике баскыч.

**Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәсетдин Зәки** иҗатларына гомуми күзәтү. Бу иҗатларда чагылган суфичылык карашларының үзенчәлекләре. Яхшылык кылу яки гөнаһка бату фәлсәфәләре, шәхесне бәяләүдә аларның әһәмияте. Җәмгыятьне тигез кешеләр оешмасы итеп күрү фикеренең сәнгатьле гәүдәләнешендә яңалыклар. Аерым алымнарны (антитеза һ.б.) куллануда һәм кайбер әдәби образларның (мәхәббәт, үлем, җылан һ.б.) гәүдәләнешендә үзгәрешләр. Татар поэзиясенә һәм сәнгатьле фикерләү рәвешенә бу шагыйрьләр керткән яңалыклар.

**Габделҗәббар Кандалый – *3 сәгать***

Язучының тормыш юлы. Кандалыйның шәхес буларак үзенчәлекләре, сыйфатлары.

Беренче әдәби әсәрләреннән *“Рисәләи-л-иршәд” (“Тугры юлга күндерүче китап”)* һәм *“Кыйссаи Ибраһим Әдһәм”* поэмалары. Боларда үгет-нәсыйхәтчелек, дини дидактиканың дөньяви рух белән өртелеп бирелүе.Шагыйрь иҗатында эпиклыкның башлангычлары. Суфичылык рухы.

Кандалыйның беренче шигырьләрендә уздырылган фикерләрдә хөрлекне яклау авазлары. Искелеккә, фанатизмга каршы булу.

Г.Кандалыйның алга таба иҗатында дөньяви мәхәббәтнең төп темага әверелүе. Бу теманы эшкәртүдә шагыйрьнең әдәби традицияләргә тугрылыгы һәм новаторлыгы. Хатын-кызларга багышланган поэмалары һәм шигъри хатлары: *“Шәфгый”, “Сахибҗәмал”, “Фәрхи”* һ.б. Хатын-кыз гүзәллеген тасвирлауда, гашыйк булган кешенең хисләрен сөйләүдә, саф сөюне зур бәхет дипраслауда шагыйрьнең сәнгатьле табышлары. Бу идея-эстетик табышларның иҗтимагый аң үсеше белән бәйләнеше. Гашыйкны гәүдәләндергән лирик герой образы ярдәмендә һәркемнең шәхси бәхеткә, мәхәббәткә һәм интим тормышка хакы барлыгын раслау.

Җәмгыятьнең төзелешен, бу төзелештә ярлы катламның авыр хезмәт белән тулы тормышын сурәтләүдә Кандалый реализмының уңышлары. Әлегә бу реализмның башлангыч адымнар гына булуы. Кандалыйда крестьян (“мужик”) образы. Кандалый мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләре, анда демократик омтылышларның чагылышы.

Г.Кандалыйның татар шигъриятенә, шигырь техникасын баетуга керкән зур өлеше. Иҗатына К.Насыйри, Г.Тукай кебек язучылар биргән бәяләр. Кандалый иҗатының туплану һәм өйрәнелү дәрәҗәсе.

Әдәбият теориясе. Шигырь үлчәмнәре.

**XIX йөзнең икенче яртысында әдәбият**
**(Яңа әдәбиятка күчеш чоры)**

Кереш. XIX гасырның икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә татарлар арасында иҗтимагый хәрәкәтнең җанлануы, моңар аерым гыйльми җәгыятьләрнең, башка халыкларның алдынгы карашлы галимнәренең йогынтысы. И.Гаспралы турында мәгълүмат бирү. Көнчыгыштан килә торган алдынгы карашлар һәм фәлсәфи тәгълиматлар тәэсире.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылышы. Реализның ныгый башлавы. Мәгърифәтчелек реализмы формалашу. Аның төп билгеләре һәм сыйфат үзенчәлекләре. Әдәбиятта чагылган гомумкешелек кыйммәтләренең реаль эчтәлек ала баруы.

XIX йөзнең икенче яртысында татар әдәбиятына гомуми бәяләмә-күзәтү. Идеаль башлангыч урынына реаль башлангыч килү.

Мәгърифәтчеләрдән **Шиһабетдин Мәрҗәни, Хөсәен Фәезхановларның** эшчәнлеге һәм иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү. ***– 1 сәгать***

**Каюм Насыйри.** Аның әсәрләре турында урта сыйныфларда белгәннәрне искә төшерү. Иҗат эшчәнлегенең күптармаклы булуын мисаллар белән раслау.

Әдәби әсәрләренә күзәтү. Аларда Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятларыннан һәм татар әдәбиятыннан килә торган мотивларның аралашып дәвам иттерелүе.

**“Әбугалисина кыйссасы”**нда мәгърифәтне, яхшылыкны алга сөрү, гади халыкны һәм гаделлекне яклаучыны зурлау. Мәгърифәт һәм гыйлемнең хаклык яклы да, явызлыкка илтүче мин-минлек яклы да булырга мөмкин икәнен күрсәтеп, беренчесен алга чыгару. “Кыйсса”дагы фантастик әкиятләр стиле.

*“Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият”* җыентыгы. Андагы гуманлы фикерләр. Урта гасырлар әдәбияты традицияләрен дәвам итү. Иҗтимагый мәсьәләләрнең сәнгатьле чишелешендә үзенчәлекләр.

К.Насыйри иҗатының халыкчанлыгы. Әдәби әсәрләрендә халык авыз иҗптына киң урын бирелү.

Әдәбият теориясе. Әдәбиятның халыкчанлыгы төшенчәсен киңәйтеп аңлату. ***– 3 сәгать***

Мөстәкыйль уку өчен. **К.Насыйри**. *“Кырык вәзир кыйссасы”*.

Татар прозасының реализм нигезләрендә җитлегү чорына керүе. Прозада жанрларның камилләшә баруы, яңа жанрлар һәм жанр төрләре барлыкка килү (роман, повесть, сатирик хикәя һ.б.). Төп темалар һәм проблемалар, аларның мәгърифәтчелек рухында хәл ителеше. Уңай һәм тәнкыйди юнәлешләрнең ачык төс алуы. Татар әдәбиятының “күп гасырлар Шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына Гареб тәэсире астына” (Ф.Әмирхан) керә башлавы һәм моның прозада чагылышы. Язучыларның милләт язмышы турында уйлануларында яңалыклар. ***– 1 сәгать***

Укытучы һәм укучылар сайлавы буенча түбәндәге монографик темаларның **(Муса Акъегет, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Закир Һади)** берсен яки икесен өйрәнү. ***– 4 сәгать***

**Муса Акъегет**. *“Хисаметдин мелла”* романы – мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятының беренче әсәрләреннән. Үзәк геройлар – шәхес иреге өчен көрәшүчеләр, аларның асыл сыйфатлары. Романның стиль үзенчәлекләре.

**Риза Фәхретдинов**. “*Әсма, яки Гамәл вә җәза”*. Яхшылык һәм явызлык, әдәплелек һәм әдәпсезлек, галимлек һәм наданлык бәрелеше. Романда гомумкешелек кыйммәтләрен раслау. Әсәрнең әдәби-стиль үзенчәлекләре.

**Фатих Кәрими**. “*Салих бабайның өйләнүе”, “Бер шәкерт белән бер студент”, “Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы”, “Мирза кызы Фатыйма”* хикәяләре. Мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләрен гуманлы идеаллар ноктасыннан торып яклау һәм хәл итү. Геройларның дөреслек хакына барган көрәштә тәвәккәллеген, нык холыклы булуын хуплау. Хикәяләрдә халыкчан тел һәм стиль.

**Закир Һади**. *“Җиһанша хәзрәт”.* Шәхес һәм мохит проблемасында кешенең рухи азатлыгы мәсьәләсен реалистик хәл итү. Әдәби образның катлаулыгына омтылу. Повестьта татар җәмгыятенең өлгергән мәсьәләләре һәм үзенчәлекле яклары чагылу.

Әдәбият теориясе. Мәгърифәтчелек реализмы.

М ө с т ә к ы й л ь  у к у  ө ч е н. **Шакир Мөхәммәдев.** *“Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай”.* **Ф.Кәрими** . *“Истанбул мәктүпләре”.*

***Региональ компонент:*** *Мәүлекәй Юмачиков иҗаты*. Шагыйрьнең “Мәкәрҗә ярминкәсе” әсәрендә дөньяга карашлары, гади халыкка мөнәсәбәте чагылышы. [Методик ярдәмлек: Ф.С. Сәйфулина “Региональ әдәбият”; ” Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б.7-15].

**Заһир Бигиев *– 4 сәгать***

Әдипнең тормыш юлы. Киң белемле, алдынгы карашлы, дөнья әдәбиятын яхшы белгән, аерата төрек һәм француз әдәбиятлары белән кызыксынган зыялы рухани булып җитлегүе.

*“Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә”* (“Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә”) романында саф мәхәббәт белән байлык арасындагы каршылык тудырган хәлләрнең тормышчан итеп тасвирлануы. Татар прозасында детективның реаль нигезләргә утыртылуы. Кеше менәзен (характерын) тормышчан җирлектә ачуда уңышлы алымнар. Зөләйханы фаҗигагә алып килгән сәбәпләрнең берсен күрсәтеп, “бала ата-ана сүзеннән чыкмаса яхшы” дигән фикер уздырылу. Байлыкка омтылышның кеше холкын бозуын, һәлакәткә китерүен сурәтләү. Хикәяләүнең объективлаша төшүе.

“*Гөнаһе кәбаир*” романы турында кыскача мәлүмат. Заһир Бигиев романнарының поэтик эшләнешендә алга китеш буларак сюжет һәм композиция төзеклегенә омтылу.

“*Мавәраэннәһердә сәяхәт”* әсәре турындамәгълүмат бирү.

Заһир Бигиев турында Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан әйткәннәр.

Әдәбият теориясе. Роман жанры турында өстәмә мәгълүмат бирү. Сюжет һәм композиция.

Татар поэзиясенең бу чоры – яңа сыйфат үзгәрешләренә әзерлек дәвере. Яңаруның татар халкы милләт буларак формалашу, милли үзаңы көчәю белән бәйләнештә баруы. Иске формаларда яңа эчтәлек уздырылу. Лирикада кеше хисләрен чагылдыруның ачыклана төшүе. Шигъри хикмәтләрдә акыл үткенлегенең, сәнгатьлелекнең артуы. ***– 1 сәгать***

**Мифтахетдин Акмулла** – татар, казакъ, башкорт әдәбиятларының уртак вәкиле. Акмулланың хат алымы белән язылган шигырьләре *(“Замана галимнәренә”, “Нургали хәзрәт”* һ.б.), алардагы төп фикерләр, поэтик үзенчәлекләр. *“Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе”*. Аның романтик рухы, җанлы сөйләмгә якын булуы, халык иҗаты алым-детальләреннән мул файдаланып язылуы. Акмулла – чичән шагыйрь. Аның хикмәтләренең төп сыйфатлары: кыскалык, тапкырлык, образлылык. Акмулла турында Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов. ***– 2 сәгать***

**Яков Емельянов**. Иҗаты турында белешмә. Бу иҗатта дини мотивлар. Шигырьләрендә гражданлык рухының көчәя баруы. Җәмгыятьнең байлар һәм ярлыларга бүленүеннән ризасызлык, гади кеше хәлен реалистик буяулар белән тасвирлау. Гадел, юмарт, юаш, яхшы кешеләрне мактап *(“Балам”)*, шагыйрьнең саран, яман, усал, тәкәббер адәмнәрне тәнкыйть итүе *(“Саран бай”).* Лирик геройның рухи халәтен тасвирлауда яңалыклар (“*Кайгы”*). Шигырьләренең

халыкчанлыгы, тел-сурәтләү чараларының гади образлылыгы, ритмика ягыннан байый һәм төрләнә баруы.

Әдәбият теориясе. Шигырьдә ритм һәм рифма турындагы төшенчәләрне укучылар хәтерендә яңарту һәм көчәйтү. ***– 2 сәгать***

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н. **Әхмәт Уразаев-Кормаши**ның *“Кыйссаи Таһир илә Зөһрә”* әсәре.

Татар драматургиясенең беренче адымнары. **Г.Ильяси, Ф.Халиди** әсәрләре. Жанр формалашу. Драматургиядә Көнчыгыш әдәбиятлары һәм Урта гасыр татар әдәбиятыннан килә торган хыялый-романтик рухны дәвам иттерү (**Минһаҗетдин Әлказаный.** *“Ихтыярлы кыз ихтыярсыз улмыш”*. **Ф.Халиди.** *“Залим ачлык, испанияле Сәет Яхъя”).*

Беренче сәхнә әсәрләрендә мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләре, саф әдәп-әхлак кагыйдәләрен яклау, иске тормыш һәм гореф-гадәтләрне тәнкыйтьләү.

Төрекчә һәм русчадан тәрҗемәләр: “Комедия Чистайда”, “Зәваллы чужык”, “Ревизор” һ.б.

Әдәбият теориясе. Драма һәм комедияжанрлары турындагы белемнәрне тулыландыру. ***– 2 сәгать***

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н. **Г.Исхакый.** *“Өч хатын белән тормыш”.*

**IX сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак.** Матур әдәбиятһәм иҗтимагый-тарихи үсеш процессы. Урта гасырлар, XVIII һәм XIX йөзләрдәгеәдәбиятлардатөп баганалар булган иҗатчылар, күренекле әдәби әсәрләр. Аларда кеше шәхесенә карашның үсә, тирәнәя баруы.Әдәбиятта иҗтимагый мотивларның чагылыш дәрәҗәләре. Сәнгатьлелекнең үсеш баскычлары. Әдәбиятның гади халык тормышына якыная баруы. ***– 1 сәгать***

## X СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

**Әсәрләрне өйрәнү – 50 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 10 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 8 сәгать**

### XX гасырда татар әдбияты

**Кереш**. XX йөз татар әдәбиятында илдәге һәм дөньядагы сәяси-иҗтимагый хәлләр, бу гасырның социаль тетрәнүләре һәм революцияләр чагылышы. Әдәбиятның яңа үрләргә күтәрелүе, бу үсешнең тигез булмавы. 1905 – 1907 еллардан башлап 20 нче елларга кадәр дәвам иткән, 80 нче елларның икенче яртысыннан яңадан башланган күтәрелешнең 30 – 80 нче елларда хакимлек иткән ялган һәм ялгыш тенденция һәм принциплар киртәсендә узган чорлар белән аралашып килүе. Халыкчан әдәби телнең формалашуы һәм үсүе, бу юлдагы аерым кимчелекләр. Язуда ике тапкыр графика алмаштыруның матур әдбият үсешенә тискәре йогынтысы; аерым алганда, традицияләрнең өзелүе.

Шәхес культы һәм татар язучылары. Бөек Ватан сугышы һәм татар язучылары. Сәясиләштерелгән тоталитар система һәм татар әдәбияты. (2 сәгать)

### XX йөз башындагы татар әдәбиятына күзәтү (2 сәгать)

1905 – 1907 еллар инкыйлабы тудырган шартларда милли әдәбиятның чәчәк атуы. Язучы һәм заман. Язучы һәм милләт язмышы.

Татар әдәбиятының жанрлар һәм стильләр ягыннан баюы. Әдәби юнәлешләр. Реализмның төрле тармак-төсләре. Пролетар әдәбият юнәлеше барлыкка килү. Романтизм агымы. Символизм, акмеизм һәм модернизм өлкәсендәге тәҗрибәләр.

Әдәбият теориясе. Иҗат методы турындагы төшенчәне киңәйтү.

### Гаяз Исхакый (5 сәгать)

Тормыш һәм иҗат юлы. Патша хөкүмәтенә каршы көрәше. Бу көрәштә төп омтылышлары, эшче-крестьян мәнфәгатьләрен кайгырту, аларны иҗтимагый изелүдән коткару максаты. Әдипнең милләт язмышы өчен борчылуы., татар милләтенең дини һәм колониаль изелүенә каршы чыгышлары, милли азатлык көрәшендә катнаша башлавы. Г.Исхакыйның көрәш юлы, төрмәләрдә утыруы, сөргендә булуы, Төркиягә качып китүе, илгә яңадан кайтып, революцион көрәшне дәвам иттерүе.

Г.Исхакый әсәрләрендә яңа әдәбиятның нигезләре салыну. *“Ике йөз елдан соң инкыйраз”* повесте. Аның татар әдәбияты һәм гомумән милләтнең үзаңы өчен әһәмияте.

*“Теләнче кыз”* романының өч кисәгендә төрле иҗат үзенчәлекләре чагылышы. Сәгадәт һәм Габдулла образларында шул заман идеяләренең гәүдәләнеше, аларның башта мәгърифәтчелек рухында, соңыннан тәнкыйди реализм мәсләгендә бирелеше. Кешене һәрчак сагалап торган бозыклык белән изгелек, мәрхәмәтлелек, сафлык сыйфатларының үзара көрәш-бәрелешен ышандырырлык вакыйгаларда күрсәтү.

Язучының *“Тормышмы бу?”, “Мулла бабай”* кебек проза әсәрләре, *“Алдым – бирдем”, “Мөгаллим”, “Тартышу”, “Кыямәт”, “Зөләйха”* һ.б. драма һәм комедияләре турында мәгълүмат бирү. Әсәрләрнең үзеген тәшкил иткән конфликт – иске белән яңа тартышы. Милли характерларның, милли гадәт-йолаларның, үзенчәлекләрнең гәүдәләнеше.

Г.Исхакый иҗатының татар әдәбияты өчен әһәмияте.

Әдәбият теориясе. “Конфликт” төшенчәсен тулырак аңлату. Иҗтимагый конфликт. Конфликтның башка төрләре.

М ө с т ә к ы й л ь  у к у  ө ч е н. **Г.Исхакый**. *“Сөннәтче бабай”, “Ул әле өйләнмәгән иде”.*

### Фатих Әмирхан. “Хәят” (2 сәгать)

Бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләэеләре чагылу. Рус дөньясы беләнаралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү

тәртипләренә карашында каршылыклар туу, моның ул шартларда мәҗбүрият булуы. Дини йолаларны үтәүнең күңелне сафландыруы, шул ук вакытта дини йола-гадәтләрне таратып аңлауның шәхес ирееген киртәләүдәге роле. Язучының кешедәге күңел тирбәнешләрен бирүдәге табышлары.

Әдәбият теориясе. Психологик анализ турында төшенчә.

### Галимҗан Ибраһимов. “Яшь йөрәкләр” (3 сәгать)

Романда төп сызык – яңарышка, рухи азатлыкка омтылыш. Җәләш, Сабир һәм Зыя образлары. Кеше җанының матурлыкка сусавын, тынгысыз эзләнүләрен раслаган теләк-омтылышлар. Матурлыкның бер чагылышы буларак музыка. Мәхәббәттә бәхетсезлеккә, шәхеснең фаҗигасына китергән сәбәпләр. Әсәрнең романтик пафосы, анда сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчан җирлеге. Характерлар сурәтендә психологик бизәкләрнең муллыгы.

### Шәриф Камал. “Акчарлаклар” (2 сәгать)

Әсәр турында 8 нче сыйныфта белгәннәрне искә төшерү. Әсәрдә гади хезмәт кешеләре, аларның рухи матурлыгы чагылу, эчке кичерешләр байлыгы. Бәхет ни ул? Акчаны мулрак табу – бәхетнең үземе? Бәхет – кешеләрнең саф хисләре, күңелне чистарта торган эш-гамәлләре, бер-берләренә гадел мөнәсәбәтләре түгелме? Мондый сорауларга җавап эзләүгә этәрүдә әсәрнең исеме; аерым сәнгатьчә детальләре, вакыйгаларның бирелеш рәвеше уйнаган роль. Кешеләр язмышында җәмгыять төзелешендәге каршылыклар чагылу.

Әдәбият теориясе. Образ турында тулырак мәгълүмат бирү. Символик образлар.

**Йомгак.** XX йөз башында татар прозасы ирешкән уңышларны гомумиләштерү. Күренекле язучылар, аларның әсәрләре. Аларда татар җәмгыятенең тормышы, кешенең, төрле социаль катламнарның бу тормыштагы урыны һәм кыйммәте чагылу дәрәҗәсе. Әдәбиятка гади кешеләр, хезмәт иясе вәкилләре образлары килеп керү, аларның тормышчан сурәтләнеше. Гуманизмның яңа сыйфатлар алуы. (1сәгать)

**XX йөз башы татар поэзиясе** (күзәтү рәвешендә кереш). Аның яңа баскычка күтәрелүе. Күренекле шагыйрьләр. Гражданлык лирикасы көчәю. Сатира өлкәсендә уңышлар. Жанр төрләре баю, сәнгатьчелек җәһәтеннән казанышлар. (1 сәгать)

### Габдулла Тукай (5 сәгать)

Тормыш баскычлары. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында моңарчы алган белемнәрне искә төшерү һәм гомумиләштерү, яңа фактлар белән таныштыру.

Тукай иҗатында халык авыз иҗаты принциплары һәм традицияләренең көчәюе, җанлы сөйләм теленә якынаю. Риториканың кимүе, сурәтлелек арту.

Тукай шигъриятендә иҗтимагый рухның көчәюе. Социаль тигезлекне гомумкешелек идеалы итеп аңлау, аны төрле яклап раслау һәм яклау,

конкретлаштыру. Милли моңнарга игътибар арту. Шагыйрь һәм чор. Дөньяны һәм яшәүнең мәгънәсен халыкчан позицияләрдән торып аңлату һәм тасвирлау.

Тукай лирикасы, үзенчәлекләре. Лирик геройның шагыйрь шәхесенә хас билгеләре һәм халыкчан герой белән уртак иткән сыйфатлары. Шагыйрьнең эстетик идеалы.

Шагыйрь иҗатында табигать, җир, ил, халык образлары.

Милли поэзиягә Тукай керткән яңалыклар, табышлар. Башка халыклар әдәбиятына Тукай иҗатының йогынтысы.

Тукай – тәнкыйтьче, аның халык авыз иҗаты һәм милләт тарихы турындагы хезмәтләре.

Әдәбият теориясе. Иҗат методы буларак реализм.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н . **Г.Тукай**. *“Китмибез!”, “Даһигә”, “Сәйфия”, “Хөрмәтле Хөсәен ядкаре”* шигырьләре; *“Халык әдәбияты”, “Тәнкыйть – кирәкле шәйдер” исемле мәкаләләре.*

## Дәрдемәнд (3 сәгать)

*“Шагыйрьгә”, “Каләмгә хитаб”, “Бүзләрем маналмадым”, “Без”, “Яз чәчәге”, “Гөрләгән сулар башында...”, “Бертуганың чит тибәдер...”, “Тел – илнең колагы”, “Атам-анам йорты өчен...”, “Илдә бер дуст булмаса гәр...”.*

Дәрдемәнд шигырьләрендә лирик герой. Шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм Туган ил, туган халык, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләренең оста сурәтләнеше. Язмыш фәлсәфәсе. Лирик геройның халык күтәрелешенә, инкыйлаби үзгәрешләргә мөнәсәбәте; революцияләрдә шәхес ирege буылачак дип сиземләве. Шигырьләренең сәнгатьчә үзенчәлеге. Хикмәт традицияләренең яңа югарылыкта дәвам иттерелүе.

Әдәбият теориясе. Татар шигыре төзелеше, үзенчәлекләре, гомуми билгеләре. Поэзия төрләре.

## Сәгыйт Рәмиев (4 сәгать)

Тормыш һәм иҗат юлы. Яшьлек елларындагы рухи эзләнүләре. Иҗат эшчәнлегенең башлануы.

“Таң йолдызы”, “Тавыш” газеталарында эшчәнлеге, бу еллардагы иҗаты. Иске тормышны кире кагу. *“Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!” һәм “Низамлы мәдрәсә”* пьесалары, аларда ухдырылган фикерләр: яңа, якты тормышка омтылу, шуңа хезмәт итү, иске, катып калган, милләтне артка сөйри торган тәртипләргә һәм гореф-гадәтләргә каршы булу, көрәшү. Бу әсәрләрдә мәгърифәтчелек традицияләре.

*“Таң вакыты”* шигыре – татар милләтенең уянуына, алга омтылышына ышаныч гимны.

С.Рәмиев иҗатының төп үзенчәлекләре. Романтизмны ачык чагылдыруы Татар шигыренә керткән яңалыклары. Көлкене сурәтләгән образларга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре, мондый образларның үзенчәлекләре.

Әдәбият теориясе. Иҗат методы буларак романтизм.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н . **С.Рәмиев**. *“Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!”*

## Мәҗит Гафури (3 сәгать)

*“Шатлык шигыре”, “Көннәребез”, “Электрик фонаренә хитаб”, “Түгелгән яшь”, “Татар хатыны”, “Вөҗдан теләге”, “Юктырсың ла, алла!..”, “Ул кем?”, “Хөррият иртәсе”, “Бер төндә”, “Татар җегетенә”, “Эшче”, “Алтын тәре, бәрхет палас”, “Ертылган сәхифәләр”* шигырьләре, мәсәлләре.

Шагыйрьнең иҗтимагый аң үсеше. Мәгърифәтчелектән – милли азатлыкка, милли азатлыктан – иҗтимагый азатлык фикерләренә килүе. М.Гафури иҗатында шәхес иреге проблемасының акрынлап социаль ирек мәсьәләсе белән алмаштырылуы. Гафури поэзиясенең “чорның күзе һәм колагы” булып әверелүе. Вакыт-вакыт гомумкешелек кыйммәтләренең сыйнфый мәнфәгатьләр артында күләгәдә калуы. Татулык һәм мәрхәмәт хисләренең үч алу, җәза бирүгә омтылыш хисләре белән аралашып килүе. Болар арасындагы диалектик бәйләнешне күрү мөмкинлеге.

Совет чорында язган әсәрләрендә кеше бәхетен төрле тарафларда эзләве. Сыйнфый көрәшне тарайтып аңлау, вату, җимерү, үч алу мотивлары белән мавыгу, аларны нигезләү.

Гафури поэзиясендә лирик герой образы. Рухи азатлык идеяләренә ышанычның чагылуы.

Гафури иҗатының художество үзенчәлекләре. Прозасы турында кыскача мәгълүмат бирү.

**XX йөз башы татар драматургиясе** (гомуми күзәтү). Жанрның оешып (формалашып) җитүе, төрләргә һәм жанр формаларына баюы. Татар профессиональ театры туу, төрле труппалар оешу. Бу хәлләрнең милли драматургия үсешенә тәэсире. (1 сәгать)

## Галиәсгар Камал (4 сәгать)

Тормыш һәм иҗат юлы. Мәгърифәт өлкәсендә күпьяклы эшчәнлеге.

Г.Камалның беренче пьесалары. Бала тәрбияләү, гаилә төзелеше, мәгърифәтле-зыялы булу турында үгет-нәсыйхәт, мәхәббәт проблемалары.

Драматургның сатирик комедияләре. Аларда куелган төп мәсьәләләр, тудырылган типлар. Татар җәмгыятенең кимчелекләреннән көлү.

*“Банкрот”* комедиясе. Сюжеты һәм композициясе, образлар системасы. Акчага омтылышның кешене түбәнлеккә, оятсызлыкка төшерү ихтималы. Кешеләрнең бер-берсенә карата ерткычлыгы, хәрәмләшү, алдашуның җирлеге. Комедиянең татар драматургиясе һәм театры өчен әһәмияте, бүгенге көннәргә аваздашлыгы.

Драматургның совет чорындагы иҗат эшчәнлеге турында кыскача мәгълүмат бирү. Декламацияләре, алардагы төп мотивлар. Эстрада әсәрләре, аларда заман сулышының чагылышы.

Г.Камалның татар драматургиясенә һәм театр сәнгатенә керткән өлеше.

Әдәбият теориясе. Сатира турында тулырак төшенчә бирү. Сатирик конфликт үзенчәлекләре.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н. **Г.Камал**. *“Безнең шәһәрнең серләре”.*

**XX гасыр башы татар әдәбиятына** күзәтү рухында **йомгак ясау.**

Бу чордагы балалар әдәбияты, публицистика, әдәби тәнкыйть турында белешмәләр бирү. (2 сәгать)

**Совет хакимияте башланганда татар әдәбияты.**

1917 елда революцияләр һәм татар язучылары, аларның инкыйлабка килү юллары. Революция идеяләренең татар әдәбиятында чагылуы. Беренче чор әсәрләрдә, бигрәк тә шигырьләрдә, инкыйлаб идеяләрен (иҗтимагый тигезлек, ирек, сугышны туктату һәм тынычлык өчен, җирне крестьяннарга бирү өчен көрәш) гомумкешелек идеаллары рухында кабул итү һәм сурәтләү, сыйнфый азатлык көрәшен идеаллаштыру, аны гомумкешелек кыйммәтләренең берсе һәм иң мөһиме төсендә кабул итү һәм сурәтләргә омтылу.

Революцияләр һәм гражданнар чоры әдәбиятына гомуми күзәтү. Көрәштә җиңү тантанасын күрсәтү өчен поэзиядә абстракт һәм космик образ-символларның активлашуы. Драматургия һәм прозада иҗтимагый конфликтның төп урынны алуы. **Сәгыйт Сүнчәләйнең** *“Ихтилал шигырьләре”*, **М.Гафуриның** *“Кызыл байрак”* исемле шигырьләр җыентыклары, аларда инкыйлаби көрәш мотивларының чагылуы. **Ф.Бурнашның** *“Таһир-Зөһрә”* трагедиясе, *“Яшь йөрәкләр”* комедиясе. Бу әсәрләрдә социаль тигезсезлекне кире кагу үзенчәлекләре. (2 сәгать)

**20 нче еллар әдәбияты (3 сәгать)**

Әдәби процесска гомуми характеристика. Яңа газета-журналлар, әдәби төркемнәр һәм агымнар (“Октябрь күмәге”, футуризм, имажинизм). Яңа тормышның поэтик бизәкләрен һәм сурәтләү телен эзләү.

Әдәбияттагы төп темалар. Революция һәм шәхес, кеше бәхете темасы. **М.Гафури, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт** шигырь-поэмалары. Яңа җәмгыять өчен көрәшне һәм батырлыкны романтик бизәкләрдә сурәтләү (**Кави Нәҗми**. *“Шобага”, “Яр буендагы учаклар”*).

Революцион аскетлык темасы (**Ш.Усманов**. *“Ил кызы”, “Краском мәхәббәте”* хикәяләре; **Ф.Бурнаш**. *“Хөсәен мирза”* драмасы һ.б.). Шәхес теләк-омтылышларын сыйнфый көрәшкә буйсындырып аңлау һәм сурәтләү, гомумкешелек кыйммәтләрен һәм кеше шәхесен артка чигерү.

20 нче елларда сатира, аның объектлары. Искелек белән көрәш үзенчәлекләренең әдәбиятта чагылуы.

**Галимҗан Ибрһимов (5 сәгать)**

Тормыш, көрәш һәм иҗат юлы.

Ибраһимовның эстетик карашлары формалашу. Аларда пролетар эстетиканың торган саен күбрәк урын ала баруы.

Әдипнең совет чорында язган әсәрләрендә сыйнфый тигезсезлекне һәм инкыйлаби көрәшне сурәтләү. Иҗтимагый азатлык көрәшен изгеләштерү, аны кешелекнең иң бөек омтылышы итеп күрсәтергә омтылу. *“Безнең көннәр”* романы. *“Яңа кешеләр”* пьесасы. *“Кызыл чәчәкләр”* хикәясе. *“Тирән*

*тамырлар”* романы. Боларда төп тема һәм образлар. Әсәрләрдә үтерү, үч алу фәлсәфәсенең яктыртылышы, сыйнфый тигезсезлекнең аерым кешене тәрбияләүдә, үзгәртүдәге роле чагылу.

*“Казакъ кызы”*. Әсәрнең язылу һәм басылу тарихы. Роман турында татар, казакъ, төрекмән язучылары һәм тәнкыйтьчеләре. Әсәрдәге вакыйгаларның “моңарчы татар әдәбиятында булмаган яңа бер хәят, яңа бер шигърият эченә алып” (Гали Рәхим) керүе.

Романның сюжет төзелеше. Казакъ далаларындагы беренчелек өчен барган партия-ыруглар көрәше сызыгы белән Карлыгач-Арысланбай мәхәббәте сызыгының үзара оста бәйләнеше. Яшьләрнең шәхси бәхет өчен көрәшләренең дәүләт өчен көрәштән өстен куелуы. Партия көрәшләренең халык язмышына җимергеч тәэсире, түбән катлауларга гына түгел, патша хакимиятенә оппозициядә булган милли көчләргә дә зарар китерүе. Биремҗан карт образында милләтнең акылы һәм буйсынмас рухы, иркенлеккә һәм иреккә омтылуы чагылу дәрәҗәсе.

Саран сурәтләрдә, үткен детальләрдә казакъ халкының бай рухы, матур гореф-гадәтләре, аерым кимчелекле яклары тасвирлану. Кеше рухының байлыгы белән иҗтимагый тигезсезлекнең үзара килешә алмавы мотивлары. Әсәрдәге тел-стиль үзенчәлекләре, хикәяләүдә эпиклык.

Г.Ибраһимовның совет чорындагы күпьяклы иҗаты. Әсәрләрендә, публицистикасында, тәнкыйтендә һәм гыйльми хезмәтләрендә эшче сыйныф идеологисе үткәрелү. Бу идеологияне берьяклы, күпертеп аңлау һәм үткәрергә омтылу.

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте өчен бу иҗатның әһәмияте.

Әдәбият теориясе. Әдәбиятның интернациональ мәгънәсе. Стиль турында төшенчә. Эпиклык.

Мөстәкыйль уку өчен. **Г.Ибраһимов**. *“Тирән тамырлар”*.

## Һади Такташ (3 сәгать)

Шигырьләр: *“Газраиллар”, “Күктән сөрелгәннәр”, “Антым”, “Урман кызы”, “Эшлиләр”, “Мәңгелек әкият”, “Сагыну”, “Такташ үлде”, “Урман”, “Карт артист”, “Давылдан соң”, “Син дә үл инде”, “Әйдә, энем”, “Җырланачак җырлар турында”, “Бүгенге матурлык”, “Җырым сиңа булсын”, “Балай... гади җыр гына”, “Үтеп барышлый”, “...Ай кебек озак яшәмәбез”;* поэмалар: *“Мәхәббәт тәүбәсе”, “Киләчәккә хатлар”; “Югалган матурлык”* пьесасы.

Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле, иҗаты, шәхесе.

Беренче чор иҗатында гомумкешелек кыйммәтләре чагылу. Мифологик образларга игътибар. Иҗтимагый тигезсезлек, сугыш афәтләрен, кешелек җәфалары өчен җан әрнүне үзенчәлекле, абстракт дини-мифологик һәм космик образларда чагылдыру.

*“Такташ үлде”, “Син дә үл инде”* – манифест рухындагы шигырьләр, аларда искелеккә каршылыкны чагылдыру үзенчәлекләре. Көрәшче аскетлыгы, аны үзенчәлекле төстә яклау.

Һ.Такташ иҗатына яңа, реалистик алым-сурәтләр килеп керү һәм активлашу. Тормышчан образларда, бер яктан, гомумкешелек кыйммәтләре чагылу, икенче яктан, илне үзенә буйсындырган “социалистик” идеология. *“Әйдә, энем”, “...Инде бу кырларда”* шигырьләре. Яшәүнең мәгънәсен, иң әүвәл, сыйнфый азатлык көрәшендә күрү, шәхес азатлыгы фикерен сыйнфый көрәш идеяләренә буйсындыру. *“Үтеп барышлый”, “Ак чәчәкләр”*. Яшәүнең мәгънәсен һәм матурлыгын табигать һәм шәхес берлегендә табу.

Мәхәббәт, ата-ана һәм балалар мөнәсәбәтләрен иң изге, бөек хисләр төсендә җырлау. *“Мәхәббәт тәүбәсе”* поэмасы, *“Югалган матурлык”* драмасы.

*“Киләчәккә хатлар”* поэмасы. Форма яңалыгы, үзенчәлекләре. Шагыйрь, Мохтар карт, эшче образлары. Аларда чорның катлаулы атмосферасында шәхес язмышы, коммунистик идеология тудырган каршылыклар чагылу. Коллектив һәм шәхес, күмәк хезмәт һәм шәхси җаваплылык мөнәсәбәте мәсьәләләре, авторның аларны рәсми идеология таләпләренә туры китереп хәл итәргә омтылуы. Шәхси милекчелекһәм күмәкләштерү сәясәте бәрелеше тудырган ситуациядә крестьян язмышы, аның перспективасы. Поэма исеменең метафорик яңгыраш алуы.

Һ.Такташ иҗатында пролетариат дәверенең үзенчәлекләре, уңай яклары һәм кимчелекләре чагылу.

Шагыйрьнең поэзиягә алып килгән яңалыгы. Яңа образлар, фикерләр, сурәтләү чаралары. Бу иҗатның татар әдәбияты өчен әһәмияте.

Әдәбият теориясе. Шигырь төзелеше турындагы мәгълүматларны киңәйтү, бербөтен төшенчә тудыру.

### Фатих Әмирхан. “Шәфигулла агай” (2 сәгать)

Әсәрнең язылу һәм саклану тарихы. Вульгар идеологизациянең шәхескә тискәре тәэсирен ачып салу. Шәфигулла образы, ярдәмче персонажлар образлары. Яңа җәмгыятьтә торган саен күбрәк урын ала барган примитив тәртипләр, аларның милли гадәт-йолалар белән көлкеле дә, кызганыч та тартыш-бәхәсе, аларны берничә яссылыкта чагылдыру. Повестьның төзелеше, үзенчәлекләре, арттыру алымнары.

Әсәрнең совет тәртипләренә һәм вульгар социологизмга беренче үткен сатира булуы.

Әдәбият теориясе. Гипербола. Шарж.

### Кәрим Тинчурин (4 сәгать)

Тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драматургиясе, төп әсәрләре. Асылда комедияләр остасы булып, иске җәмгыятькә һәм яңа җәмгыятьтәге аерым кимчелекләргә көлке һәм сатира угын юнәлтүе.

*“Американ”* комедиясе. Әсәрдә көлке эченә көлке яшерелеп бирелүе, конфликтның бу җәһәттән үзенчәлеге. Сатирик көлүнең төп объекты итеп иске җәмгыятьнең ташландык катламы алыну. Сатирик персонажларның үзләренә генә хас сыйфатларын күрсәтүдә буяулар төрлелеге. Милләтне артка сөйрәүче иске гореф-гадәтләрне, аерым сыйнфый катлауларны

чагылдырган образлар, аларның үз-үзләрен фаш итүгә нигезләнгән сурәтләү үзенчәлекләре. Наданлык, мин-минлек, байлыкка һәм шөһрәткә омтылу, кеше җилкәсендә яшәргә маташу, хөсетлек кебек сыйфатларны милли тарлык һәм милли нигилизм кебек күренешләр белән бәйләп-аралаштырып күрсәтү. Көлкеле хәлләр һәм вакыйгалар, аларның оста эшләнгән булуы. Төп һәм ярдәмче образлар, аларның сыйфатлары. Әсәрнең төзелеше, тел-стиль чараларының байлыгы, татар теленең каламбур мөмкинлекләреннән тулы һәм белеп файдалану. Көлке тудыруның башка алымнарына мисаллар. Ул алымнарның көлкеле үзәк сюжетка оста бәйләнгән булуы.

К.Тинчурин иҗатының әһәмияте.

Әдәбият теориясе. Комедия жанры турында берботен төшенчә тудыру.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н . К.Тинчурин. *“Сакла, шартламасын!”* комедиясе.

**Йомгаклау дәресе** (1 сәгать).

## XI СЫЙНЫФ
## (68 сәгать)

**Әсәрләр өйрәнү – 50 сәгать**
**Сөйләм үстерү – 10 сәгать**
**Дәрестән тыш уку – 8 сәгать**

### Чит илләрдә татар әдәбияты. Күзәтү (1 сәгать)

Чит илләрдә татар әдәбияты. Андагы төп темалар һәм проблемалар, бигрәк тә Туган илне сагыну темасының актуаль булуы. **Йосыф Акчура, Хәсән Хәмидулла, Гәүһәр Туганай, Хөсәен Габдуш, Әхнәф Тангатар, Сания Гыйффәт** һ.б. иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү.

### Гаяз *Исхакый* ( 3 сәгать)

Язучының 1917 клгы инкыйлабларга мөнәсәбәте, эмиграциядәге тормышы һәм иҗаты. Хикәяләре. *“Дулкын эчендә”, “Ике ут арасында”, “Жан Баевич”* пьесалары. Аларның идея-эстетик үзенчәлекләре. Сыйнфый көрәштә шәхеснең рухи һәм физик яктан газапланууларын һәм кыерсытылуын күрсәтү. Руслашуга артык бирелүнең милләтне аяныч та, көлке дә хәлләргә төшерүен тасвирлау.

*“Локман хәким”* әкияте, *“Олуг Мөхәммәт”* тарихи драмасы, алардагы төп фикерләр, тарихи-фәлсәфи эчтәлекнең мөһимлеге, татар әдәбияты өчен яңалыгы.

*“Көз”* повесте. Нәфисә һәм Гөлсем образларының капма-каршы куеп сурәтләнүендә эчке мәгънә. Хәлил образы. Кеше, үз язмышына хуҗа була алсын өчен, актив булырга, ныклы иманлы булырга тиеш, дигән фикер чагылдырылу. Милли гадәт-йолаларның йомшаруы, яки югалуы кешедәге рухи ныклыкка тәэсир итүен, кешене рухи таркалуга китерүен раслау. Башка милләт вәкиленә чит-ят мохитнең аны һәлакәткә дә китерүе мөмкинлеген ышандырырлык төстә сурәтләү. Повестьта сәнгатьчә детальләрнең роле, символик образлар.

Г.Исхакый иҗатының татар әдәбияты һәм сәнгате тарихындагы урыны.

**30 нчы елларда совет әдәбияты (2 сәгать)**

Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең әдәби процесста чагылышы.

Татар әдәбиятында Октябрь инкыйлабы һәм гражданнар сугышы чорларын чагылдыру (**Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, К.Нәҗми, Т.Гыйззәт, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Тинчурин** әсәрләре). Көрәшче-герой образында һәм ситуация-конфликтларда тормышчан һәм схемачыл билгеләрнең үрелеп килүе.

Яңа кеше образын эзләү, аны, иң беренче, сыйнфый көрәш ноктасыннан, партиялелек позициясеннән торып күзаллау һәм тасвирлау (**Ш.Камал, М.Әмир** һ.б. әсәрләре).

Яңа әхлак нормаларын аңлауда үзенчәлекләр. Еш кына үткәндәге әхлак кагыйдәләрен санламау, шик астына алу, хәтта кире кагу белән мавыгу. Күмәк хезмәткә мөнәсәбәт тәрбияләргә тырышу, хезмәт кешесен югары күтәрергә омтылу (**Г.Кутуй.** *“Тапшырылмаган хатлар”,* **Р.Ишморат.** *“Гөлзадә”* һ.б.)

Иҗтимагый идеалны шигърияткә әверелдерү юлларында эзләнүләр (**Ш.Маннур, М.Җәлил, Ф.Кәрим** һ.б. әсәрләре).

М.Галәүнең *“болганчык еллар”* һәм *“Мөһаҗирләр”* романында татар халкы тормышы һәм тарихындагы аерым караңгы, фаҗигале чорларның гәүдәләнеше. Әсәрләрнең этнографик бизәкләргә муллыгы.

30 нчы елларда иҗади эзләнүләрнең катлаулы, язучылар язмышының фаҗигале булуы. Шәхес культы чорындагы репрессияләр һәм язучылар.

Әдәбият теориясе. Социалистик реализм турында бүгенге карашлар. Аның, метод буларак, татар әдәбияты үсешен тоткарлавы, рухи тупикка сөйрәве.

**Нәкый Исәнбәт (3 сәгать)**

Тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү. Гыйльми эшчәнлегенә күзәтү ясау.

*“Идегәй”* трагедиясе. Трагедиянең кыскача эчтәлеген ачу, идея-эстетик анализ бирү. әсәрнең халык дастанына һәм гомумән халык авыз иҗатына мөнәсәбәте. Татар халкының азатлыкка омтылу рухын чагылдыручы буларак Идегәй образы. Ил өчен көрәш темасы. Трагедиянең сюжет үстерелеше, композицион төзелеше; дастаннан килә торган алымнар, тел-сурәтләү чаралары. Әсәрнең жанр ягыннан үзенчәлекләре.

Әдәбият теориясе. Трагедия жанры. Трагик конфликт.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н. **Н.Исәнбәт.** *“Зифа”* комедиясе.

**40 – 50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы (3 сәгать)**

Бөек Ватан сугышы һәм татар язучылары.

Ил һәм җәмгыятьнең рухи тормышына сугыш керткән үзгәрешләр. Дошманны җиңүгә омтылыш пафосының әдәбиятта аерым жанрлар үсешенә тәэсире. Нәсернең активлашуы. **Т.Гыйззәт, М.Әмир, Н.Исәнбәт** пьесалары**, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, И.Гази, А.Шамов** һ.б. хикәя-повестьлары.

Әсәрләрдә мугыш һәм кеше проблемасы. Сугыш чынбарлыгы һәм аны сурәтләү үзенчәлекләре. Патриотизм һәм дошманга нәфрәтнең чагылышы. Монда берьяклылык барлыкка килү. Әдәбиятның сугышчы хисләрен сурәтләүдә схемачыллыкны җиңә баруы, хисләр һәм сурәтләү төсләренең баюы.

**Г.Әпсәләмов** повестҗ һәм романнары (*"Алтын йолдыз", "Газинур", "Мәңгелек кеше")*. Аларда романтик сурәтләр һәм образлар. Сугыш фаҗигасенең дә, шәхес кичерешләренең дә тулы ачылып бетмәве. Сугыш һәм совет солдаты турында да, илбасарлар хакында да берьяклырак мәгълүмат бирелү, психологик тирәнлек җитмәү. Г.Әпсәләмов прозасында сюжетның төзек, җанлы һәм тыгыз булуы, әсәрләрне уку өчен кызыклы һәм тәэсирле итүе.

Партия Үзәк Комитеты 1944 елның августында кабул иткән карар. Аның татар әдәбиятына, сәнгать һәм мәдәниятенә, гомумән фәлсәфи-тарихи фикеренә ясаган тискәре тәэсире, аерым алганда, үткән тарихка караган әсәрләр язуда берьяклылыкка китерүе.

Әдәбият теориясе. Роман төрләре.

М ө с т ә к ы й л ь у к у ө ч е н. **Хисам Камал.** *"Һәркемнең гомере бер генә"* романы.

**Муса Җәлил (3 сәгать)**

Шигырьләр: *"Хуш, акыллым", "Окоптан хат", "Кыз үлеме", "Кичер, илем!", "Кошчык", "Шагыйрь", "Дару", "Бүреләр", "Төрмәдә төш", "Юллар", "Күлмәк", "Дуска", "Тау елгасы", "Сөю", "Кар кызы", "Бер үгет", "Имән", "Батырлык турында".*

М.Җәлилнең тормыш һәм сугышчан юлы. Сугышка кадәрге иҗатына кыскача күзәтү. 20 – 30 нчы еллар шигъриятендә батырлык темасы. *"Алтынчәч"* драматик поэмасы. Яшьлек һәм мәхәббәтне пафос белән сурәтләү, хезмәтнең поэтик гәүдәләнеше. *"Хат ташучы"* поэмасы.

Шагыйрьнең сугыш чоры иҗатында батырлык темасының реаль эчтәлек белән сугарылуы. Кеше хисләренең патриотизм пафосы белән тыгыз үрелеп тасвирлануы. *"Моабит дәфтәрләре"* циклы. Кешенең Ватанны саклау сугышында җаваплылыгы тойгысы, аның төрле поэтик вариацияләре. Дошманга нәфрәтнең чагылышы. Сагыну, ярату, якыннарга хөрмәт һ.б. кешелек тойгыларының шигырьләрдә лаеклы урын алуы, аларның тәэсир көчен арттыруы. Поэтик алымнар һәм бизәкләр, аларның яңалыгы һәм сәнгатьлелек көче.

"Моабит дәфтәрләре"ндә юмор үзенчәлекләре.

Әдәбиятта һәм сәнгатьтә М.Җәлил образы.

Әдәбият теориясе. Лирик шигырь. Поэзиядә гражданлык мотивлары. Поэма, баллада жанры турындагы белемнәрне тулыландыру.

## Татар әдәбияты яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында
## (4 сәгать)

**Кереш.** Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда илдә булган хәлләр һәм сәяси-иҗтимагый үзгәрешләр. Тоталитар системаны җимерүгә беренче омтылышлар. Торгынлык еллары. Ил халыкларының үзгәртеп кору чорына килеп керүе, СССРның таркалуы, яңа икътисади һәм иҗтимагый нигезләргә күчүнең башлануы. Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәш.

Бу дәвердә татар әдәбияты: илдәге, татарстан Республикасындагы хәлләр һәм үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылу дәрәҗәсе.

**50-70 нче еллар әдәбияты (күзәтү).** Төп иҗат көчләре. **Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, М.Әмир, И.Гази, Г.Әпсәләмов, К.Нәҗми, Ә.Еники, С.Баттал, Ш.Маннур, С.Хәким** һ.б.ларның әсәрләре турында кыскача мәгълүмат бирү. Аларда жанр төрлелеге, сәнгатьлелек ягыннан һәм тематикада яңалыклар.

Бу еллар әдәбиятының гомуми кимчелекләре: тормышчан дөреслек җитеп бетмәү, ил һәм халык тормышындагы вакыйга-хәлләрне бизәп-шомартып күрсәтү; геройлар характерын схемачылыкка сөйри торган төстә тасвирлау; тематикадагы яңалыкны сәнгать ягыннан яңалыктан өстен кую һ.б..

**И.Гази.** *“Онытылмас еллар”* трилогиясе. Аерым типик характерлар иҗат итүдә әсәрнең әдәби процесстагы урыны: революцияне кабул итү һәм бәяләүдә кайбер кимчелекләре.

**М.Әмир.** “Ялантау кешеләре”, “Саф күңел”. Дилогиянең язучы иҗатындагы роле, урыны, әдәбият тарихы өчен әһәмияте; сугыш чоры һәм сугыштан соңгы еллардагы халык тормышын берьяклырак тасвирлау.

**Г.Бәшировның** *“Намус”* романы. Хезмәт кешесенең рухи байлыгын ачуда, тел-сурәтләү чаралары өлкәсендә уңышлар. Әсәрнең тормыш дөреслегенә тугрылыгы ягыннан кайбер җитешсезлекләре.

### Әмирхан Еники (2 сәгать)

Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән таныштыру. Язучының сугыш елларында иҗат иткән хикәяләре. Алардагы психологик бизәкләр, гади кешенең эчке кичерешләрен дөрес һәм тәэсирле итеп сурәтләү, детальләр төгәллеге.

*“Әйтелмәгән васыять* хикәясе. Акъәби боразы, аның халык намусын һәм рухи дөньясындагы сафлыкны гәүдәләндерүе. Ананың балаларына мөнәсәбәте, күңел җылылыгы, сизгерлеге, яңа йола-тәртипләрне аңларга омтылуы, үз күңелендә электән урнашкан, канына сеңгән гадәтләрнең замана тудырган яңалыклар белән каршылыкка керүе.

Хикәянең сәнгатьчә эшләнеше, композициясендә үзенчәлекләр. Халыкның гореф-гадәте, туганлык җепләренең изгелеге, кеше күңеленә игътибарның җитмәве кебек сыйфатларның калку итеп куелуы. Болардан чыга торган төп фикер. Кылган образы. Хикәядә Миңлебай карт әйткән соңгы сүзләрнең эчке мәгънәсе. Учак образы.

*“Матурлык”* хикәясе. Ана һәм бала мәхәббәтенең үзенчәлекле чагылдырылуы. Хикәянең сәнгатьчә эшләнеше.

**Хәсән Туфан (2 сәгать)**

Шагыйрьнең тормыш юлы, шәхес буларак үзенчәлекле сыйфатлары.Иҗатының башлангыч чоры. *“Урал эскизлары”, “Бибиевләр”* поэмалары. Алардагы төп фикер, сәнгатьчә эшләнешләрендә үзенчәлекләр.

Х.Туфанның тоткынлык чорындагы иҗаты. Кеше кичерешләренең төрлелеген, байлыгын чагылдыруы (*“Иртәләр җитте исә”, “Чәчәк сибелә җирдә”* һ.б.).

Авторның татар шигыре строфикасына керткән яңалыгы (*“Гөлләр инде яфрак яралар”).*

Туфан шигъриятенең фәлсәфи тирәнлеге *(“Сөйли торган материя”, “Сүз кушасы килә талларга”* һ.б.) Табигать белән кеше бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен сурәтләү.

60 – 70 нче елларда Х.Туфан иҗаты. “Туфан – үзе бер чор” (С.Хәким). Бу чор иҗатының төп сыйфатлары. Лирик геройның рухи баюы *(“Гомер эзләре буйлап”, “Кармәт истәлекләре”). “Еракларга алып киттеләр”* поэмасы. Шагыйрь иҗатында әхлак сафлыгы, мәхәббәткә тугрылык, ныклы гаилә төзү проблемаларының сәнгатьчә хәл ителеше.

**Әдәбиятка яңа иҗат көчләре килү**

**Нурихан Фәттах.** *“Сызгыра торган уклар”* романы. Язучының иҗатына кыскача күзәтү ясау. *“Сызгыра торган уклар”*ның тарихи роман буларак үзенчәлекләре. Ерак тарихка бүгенге проблемалар югарылыгыннан караш. Төп образлары, сюжет үстерелеше, характерларның ачылу дәрәҗәсе. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендә үзенчәлекле сыйфатлар, борынгы төрки тел үрнәкләренең әсәрдә бүгенге әдәби телгә оста үрелгән булуы. (2 сәгать)

Әдәбият теориясе. Тарихилык принцибы турында.

**Аяз Гыйләҗев.** Иҗатына кыскача күзәтү. *“Әтәч менгән читәнгә”* повестен анализлау.Әсәрдә уздырылган төп фикерне ачыклау. Образларга бәя бирү, художество үзенчәлекләрен тәгаенләү. Повестьның соңгы еллар әдәбияты өчен яңалыгы. (2 сәгать)

**Илдар Юзеев** иҗаты турында гомуми мәгълүмат бирү. Шагыйрь ёщм драматург буларак иьат эшчщнлеге. Поэма, баллада, шигъри трагедияләр авторы. Аларда заман һәм кешенең үзара мөнәсәбәте, кешене кеше иткән чыганакларны эзләү һәм сәнгатьчә күрсәтергә омтылу.

*“Өчәү чыктык ерак юлга...”* Поэмадагы тормышчан проблемалар. Фазылҗан, Нур һәм “мин” образлары. Аларның үз тормыш сукмакларын эзләүләре. Рухи дөньяларына игътибар. Кәккүк образына йөкләнгән мәгънә. Поэманың үзәгенә куелган юл образы. Яшьлек хатирәләрен шигъри юлларда бирү үзенчәлекләре. Җанлы һәм җансыз табигать образларының (көймә. урман, чабыш атлары) хатирәләрне тергезүдәге роле. Поэмада шигъри сурәтлелек байлыгы. (2 сәгать)

**Туфан Миңнуллин.** Драматургның тәрҗемәи хәле. Драма поэтикасына, формасына яңалыклар алып килүе, символика, шартлылыкка иркен мөрәҗәгать итә башлавы (*"Ай булмаса, йолдыз бар", "Моңлы бер җыр", "Әлдермештән Әлмәндәр"*). Тарихка һәм тарихи шәхесләр образына мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләре (*"Канкай углы Бәхтияр", "Без китәбез, сез каласыз", "Ат карагы").*

*"Әлдермештән Әлмәндәр"* комедиясе. Әлмәндәр карт образының тормышчан фәлсәфи нигезе: ил картының тормышка мәхәббәте һәм яшәү дәрте, халык акылын һәм тәҗрибәсен чагылдыруы. Комедиядә яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең оста хәл ителүе. Шартлылыкка киң мөрәҗәгать итүнең сәнгатьчәаклануы.

Татар театр сәнгатен үстерүдә Т.Миңнуллин драматургиясенең роле.

Әдәбият теориясе. Пролог. Эпилог, Интермедия, Аллегория. (3 сәгать)

**Хәзерге татар әдәбияты**

**Кереш.** Җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылуы. Әсәрләрдә милли бәйсезлек һәм мөстәкыйльлеккә омтылу авазлары, милләтебез тарихына игътибарның артуы. Тарихи һәм табигатьне саклау темаларының активлашуы. Бүгенге әдәбиятта шәхес концепциясенең үзенчәлекләре. (1сәгать)

**Поэзия (7 сәгать)**

**Н.Арсланов, Г.Афзал** һ.б. әсәрләре, аларның үзенчәлекле яклары.

Шигъриятькә яңа иҗат көчләре килү: **Р.Әхмәтҗанов, Р.Мингалим, Р.Гаташ, Г.Рәхим, Зөлфәт, З.Мансуров, К.Сибгатуллин, Ш.Маннапов, Г.Моратов, Р.Зәйдуллин, Б.Сөләйманов, Ш.Гаделша** һ.б. Яңа тема һәм идеяләр. Аерым жанрларның активлашуы: поэма, оратория, дастан, баллада, реквием һ.б., боларда аерым жанр чикләренкиңәйтергә һәмтөрләндерергә омтылышлар. Шигъри сүзнең эчке куәтен, җегәрен арттыруда уңышлар. Поэзиядә халык авыз иҗатындагы, бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатендәге символикадан, шартлы алымнардан файдаланырга омтылышның артуы һәм җанлануы. (2 сәгать)

**Равил Фәйзуллин** иҗатын кыскача күзәтү. Психологик киеренкелеккә омтылышы, чичәнлек традицияләрен уңышлы үстерүе. *"Гадиләргә гимн", "Көрәшчеләр"* поэмаларының идея-эстетик үзенчәлекләре. Аларда кешенең бүгенге җәмгыятьтәге урынын күзаллауның чагылышы. (2 сәгать)

**Ренат Харис** поэзиясе турында мәгълүмат бирү. Шигъриятендә заманчылык рухы, фикер тирәнлегенә омтылыш, шагыйрьнең сәнгатьчә үтемле мөмкинлекләр эзләве. Оригиналь формаларга, метафорикага кыю мөрәҗәгать итүе (*"Ат иярләү", "Ант суы", "Җәлилчеләр"* поэмалары, *"Кеше"* ораториясе) (1 сәгать)

***Региональ компонент:*** **Ш.Гаделша** [Мин – Себер татарымын. – Казан, 2006. – Б.85]; Б.Сөләйманов ***:*** **Б.Сөләйманов** [Б.Сөләйманов. Мин Себер татарымын. – Екатеринбург, 1998. – Б.121]. (укытучы сайлавы буенча)

**Проза (7 сәгать)**

Проза жанрында җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасын яңача хәл иткән әсәрләр язылу (**Г.Ахунов**. "Идел кызы", **М.Хәсәнов**. *"Язгы аҗаган",* **А.Гыйләҗев**. *"Балта кем кулында*?", "Йәгез, бер дога!"). Әсәрләрдә тоталитар системаның шәхесне изүе, физик һәм мораль яктан мәсхәрәләве, таптавы чагылу.

**Р.Батулла, Ә.Гаффар, М.Маликова, Ф.Садриев, Ф.Яруллин, Т.Әйди** һ.б. әсәрләре. Аларда тормыш дөреслегенә якынаю процессы чагылу. (3 сәгать)

**Мөсәгыйть Хәбибуллин** әсәрләре турында гомуми мәгълүмат бирү. *"Кубрат хан"* романы. Гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар, аларны ил мәнфәгатьләре яктылыгында карау, илнең иминлеген, милләт язмышын алга чыгарып тасвирлау. Сюжет җанлылыгы, образлары. Тарихи фактларга, мәгънәләргә, сүз-тәгъбирләргә игътибар, аларның бүгенге укучыга тәэсир көче. (2 сәгать)

***Региональ компонент:*** **Якуб Зәнкиев** иҗатына күзәтү. *"Иртеш таңнары"* романы. (2 сәгать)

**Б.Сөләйманов** *"Нәби яки көтелмәгән очрашу*" [Б.Сөләйманов. Мин Себер татарымын. – Екатеринбург, 1998. – Б.150-176].

Әдәбият теориясе. Сәнгатьчә дөреслек категориясе.

**Драматургия (5 сәгать)**

**Т.Миңнуллин, А.Гыйләҗев. Ю.Әминев, Ә.Баянов, И.Юзеев** һ.б. пьесаларында әхлак проблемаларына игътибарның артуы. Татар халкының рухи сәламәтлеге мәсьәләләре чагылу.

**Яшь драматурглар З.Хәким, М.Гыйләҗев, Д.Каюмов, Р.Гыйззәтуллин** пьесаларына кыскача күзәтү-мәгълүмат бирү. (1 сәгать)

**Р.Батулланың** драма әсәрләренә кыскача күзәтү**.** *"Өчәү юлга чыктык"* драмасы. *"Кичер мине, әнкәй!"* мелодрамасы. Алардагы заманчалыкның чагылышы.

*"Сират күпере"* тарихи драмасына анализ. Тукай образын гәүдәләндерүдә яңалыклар, сәнгатьчә ачышлар. Образлар системасы. (2 сәгать)

**Ризван Хәмид** иҗаты турында гомуми мәгълүмат бирү. *"Синең урыныңа кайттым", "Кайтыр идем", "Китәм инде"* пьесаларында фәнни-техник революция шартларының шәхесне рухи бөлгенлеккә төшерүен күрсәтү. Кеше күңеленең катылыгына, миһербансызлыкка нәфрәт чагылу (*"Олы юлның тузаны"*).

*"Җиде баҗа"* драмасы: төп фикере, сәнгатьчә үзенчәлекләре, яңа алымнар куллануда табышлар. Күгәй, Дая, Дулат, Искәндәр образлары. Болар ярдәмендә кешенең асыл сыйфатларын олылау. Драманың эчтәлегендә бүгенге авыл проблемаларының, авыл гадәт-йолаларының актуальлеген чагылдыру. (2 сәгать)

## Балалар әдәбияты (3 сәгать)

Бүгенге татар балалар әдәбиятының төп иҗат көчләре. **Л.Ихсанова, Ж.Тәрҗеманов, Х.Халиков, Р.Хафизова, Ж.Дәрзаман, Р.Бәшәр, З.Хөснияр** һ.б. әсәрләре. Төп тема һәм проблемалар. Сурәтләү объектының гаилә хәлләренә, бала яки яшүсмернең эчке дөньясына авыша баруы.

**Шәүкәт Галиев** иҗатына күзәтү. Шигырьләрендә баланың психологиясе, тынгысыз холкы чагылу. Бу чагылуның үзенчәлекләре, тапкырлыкка, җорлыкка, көтелмәгәнлеккә киң урын бирелү.

**Роберт Миңнуллинның** балалар поэзиясенә анализ ясау. Тема һәм образлар төрлелеге. Туган якка, табигатькә, ата-анага чиксез мәхәббәтне нечкә юмор һәм мөлаем җылылык белән тасвирлау.

Балалар әдәбиятында проза жанрының, бигрәк тә тарихи прозаның яңа әсәрләр белән баюы. Сурәтләүдә мажаралылыкка киң урын бирелү. Әкият төренең җанлануы.

## Йомгак (1 сәгать)

Совет чорында татар әдәбияты узган юл: табышлар һәм югалтулар. Әдәбиятның сәнгатьчә дөреслеккә ирешү юлында ныгый баруы. Әдәби процессның юлдашы буларак әдәби тәнкыйть. Соңгы еллар тәнкыйтендә актив эшләүче **М.Хәсәнов, Р.Мостафин, Ф.Мусин, Т.Галиуллин, А.Әхмәдуллин, Ф.Галимуллин, Ф.Хатипов, Н.Хисамов, Ф.Урманчиев, Х.Миңнегулов, Н.Ханзафаров, Ә.Сәхәпов, М.Вәлиев, С.Маннапов, С.Хафизов, Р.Рахмани, Ф.Бәширов** һ.б.

Халыкның рухи һәм акыл хәзинәсен саклау һәм үстерүдә татар әдәбиятының роле.

## Югары сыйныфларда инша ( сочинение) язу өчен тәкъдим ителгән якынча темалар

1. “Кыйссаи Йосыф” поэмасы – халыкның рухында.
2. Мөхәммәдьяр – гуманист-шагыйрь.
3. “Әйа агач, яшең күпме?” (Г.Кандалый поэзиясе).
4. К.Насыйри һәм татар халык авыз иҗаты.
5. Хәдичәнең гүзәллеге нидә? (З.Бигиев романнары).
6. Акмулла – гаделлек һәм мәгърифәт җырчысы.
7. Күпме какканны күтәрде бу милләт... (Г.Исхакый әсәрләрендә милләт язмышы чагылу).
8. Канатсыз акчарлаклар (“Акчарлаклар повесте).
9. “Син – Кеше!” (XX йөз башы әдәбиятында кеәе образы)
10. Г.Тукай – халыкның үз баласы.
11. Г.Ткай һәм төрки халыклар әдәбияты.
12. “Уеңны уйдырып сал” (Дәрдемәнд иҗаты).
13. Сиражетдин – комсызлык корбаны (“Банкрот” комедиясе).
14. Гали ике ут арасында (“Яшь гомер» драмасы).

15.“Киләчәккә хатлар” бүгенге укучыга нәрсә бирә?
16.Көлке көлә килә... (“Американ”да сатира һәм юмор.)
17.Кеше үз язмышына үзе хуҗа. (Г.Исхакый. “Көз”.)
18.Рәнҗетелгән һәм изелгәннәрне яклап. (“Идегәй” трагедиясе.)
19.Киң даланың ирек сөюче кызы. (Г.Ибраһимов. “Казакъ кызы”.)
20.Без сугышта юлбарыстан көчлебез. (Бөек Ватан сугышы татар әдәбиятында)
21.Зинданнарны ватып чыккан җыр. (“Моабит дәфтәре”)
22.“Намус” романы һәм бүгенге тормыш.
23.“Кайсыгызның кулы җылы...” (Х.Туфан лирикасы.)
24.Хәзинә хуҗалары. (Г.Ахуновның “Хәзинә” романы.)
25.Тарихыбыз түреннән килгән аваз һәм рух. (Н.Фәттах романнары.)
26.Мәгънәсез ярышучылар. (А.Гыйләҗев. “Әтәч менгән читәнгә”.)
27.“Кеше китә - җыры кала”. (М.Мәһдиев прозасы.)
28.Әлмәндәр – ил карты. (“Әлдермештән Әлмәндәр” комедиясе.)
29.Хыял һәм чынбарлык бәрелеше. (Р.Мөхәммәдиевнең “Ак кыялар турында хыял” повестенда образлар системасы.)
30.Шагыйрь сират кичә. (Батулла. “Сират күпере”.)

## Ирекле темалар

1. Җир йөзе шундый киң, күңелле һәм якты. (М.Җәлил)
2. “Халык – зур ул, көчле ул... (Г.Тукай)
3. Дуслар кирәк дөнья көтәргә...
4. Рус җирендә без әсәрле, эзле без... (Г.Тукай)
5. Сабантуй – хезмәт һәм дуслык бәйрәме.
6. Авылым матур уйлый.
7. “Китап укып елый алганнарның
   Күңелендә булмый каралык”. (М.Әгъләмов)
8. Сүзләр чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...
9. Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Тукай образы.
10. Минем яраткан әсәрем (язучым).
11. Хаклвк өчен көрәшчеләр сафында мине урыным.

## 5-11 нче сыйныф укучыларының татар теленнән һәм әдәбиятыннан белемнәрен бәяләү

### Укуны бәяләү

Укучыларның 1 минутта уку тизлеге түбәндәгечә билгеләнә:

| Сыйныфлар | Икенче ярты еллыкта | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Хәреф саны | | Иҗек саны | | Сүз саны | |
| 5 | 355-600 | 415-650 | 155-235 | 160-250 | 65-105 | 70-110 |
| 6 | 415-650 | 445-700 | 160-250 | 170-270 | 70-110 | 75-115 |
| 7 | 445-700 | 455-725 | 170-270 | 180-280 | 75-120 | 80-125 |
| 8-9 | 455-725 | 485-755 | 180-280 | 190-290 | 80-125 | 85-130 |
| 10 | 465-735 | 495-765 | 190-290 | 200-300 | 85-130 | 90-135 |
| 11 | 475-745 | 500-775 | 200-300 | 210-320 | 90-140 | 100-145 |

**Искәрмә:**

- Укуның төп максаты – текстның дөрес укылуына һәм эчтәлеген аңлауга ирешү;
- Укуны тикшереп бәя биргәнче, укучылар, бәяләү нормалары белән таныштырылып, текст белән эшләү күнекмәләре алырга тиеш.



**Укуга куелган таләпләр һәм бәяләү**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| *1.*<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | ***Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:***<br>***- фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;***<br>***- татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең әйтелеш үзенчәлекләре сакланса;***<br>***- җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә дөрес бүленсә;***<br>***- тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса;***<br>***- интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;***<br>***Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә;*** | «5» ле билгесе куела |
| *1.*<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | ***Таләп ителгән күләмдәге сүзләр тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:***<br>***- кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;***<br>***- сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;***<br>***- җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;***<br>***Укытучыларның сорауларына төгәл җавап бирелсә;*** | ***«4» ле билгесе куела*** |
| *1.*<br><br>2.<br><br>3. | ***Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;***<br>***Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;***<br>***Сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса;*** | ***«3» ле билгесе куела*** |
| *1.*<br>*2.*<br><br>*3.*<br>*4.* | ***Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;***<br>***Уку барашанда үтелгән орфорг.-да төгәлсезлекләр күп кабатланса;***<br>***Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;***<br>***Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә җавап алынганда.*** | ***«2» ле билгесе куела*** |

| | | |
|---|---|---|

**Язма эшләрне бәяләү**

***Тел буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатларыннан чыгып, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә төрле язма эшләр – диктантлар, изложение, сочинение яздырыла. Диктантларны бәяләгәндә, орфоргафик һәм пунктуацион хаталар саны, ә изложение һәм сочинениеләрдә орфографик һәм пунктуацион хаталар белән бергә, теманың ачылу дәрәҗәсе, язманың тел байлыгы (С.), грамматик ялгышлары (Г.), логик (Л.), һәм фактик (Ф.) хаталар да исәпкә алына.***

***Хаталар тупас һәм тупас булмаган хаталарга бүленеп йөртелә:***

**Тупас хаталарга** ***алдагы сыйныфларда һәм бу уку елында үтелгән орфоргафик, грамматик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган хаталар керә;***

**Тупас булмаган орфографик хаталар:**

***- укучы үзе төзәткән орфоргафик хаталар (өч хатасын үзе төзәткән укучының эше бер баллга түбән бәяләнә); язылышы татар теле кагыйдәләренә туры килмәгән ялгышлар (Сибгат, төнъяк, Акъегет һ.б.);***

***- мәгънәләре төрлечә кулланылган кушма яки тезмә сүзләрне бутап язу (өй алды – өйалды, ил гизәр – Илгизәр һ.б.);***

***- программа нигезендә өйрәнү күздә тотылмаган яки соңрак үтеләчәк теоретик материалларга караган орфоргафик хаталар;***

***- дәреслектә күрсәтелмәгән очракларга караган сүзне юлдан-юлга күчерүдә ялгышу.***

***Тупас булмаган пунктуацион хаталарга җөмлә эчендәге синтагмаларны яки кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен, функцияләре бердәй булган тыныш билгеләренең берсе урынына икенчесен кую (теркәгечләрдән башка бәйләнгән ике тиңдәш кисәкнең берсе икенчесенә каршы куюны белдергән очрактасызык яки өтер кую; гомумиләштерүче сүзләр янында – ике нокта яки сызык; аныклагычлар янына – сызык, ике нокта, җәяләр яки ике яктан өтер; ымлык яки аваз ияртемнәреннән соң – өтер яки өндәү билгесе; теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә – өтер, нокталы өтер яки сызык; тиңдәш кисәкләр арасында – өтер яки нокталы өтер; иярченле кушма җөмләдә – өтер яки ике нокта; туры сөйләм янында - сызык, өтер яки сызык, күп нокта һәм сызык, ике нокта һәм сызык; тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую; берничә тыныш билгесе бергә очрашкан урыннарда ялгышу; үзара бик тыгыз бәйләнештәге гади җөмләләрне өтер, сызык яки ике нокта белән аерып язу; тезмә кушма җөмләләрнең өлешләрен нокта белән аерып, шул фикерне гади җөмләләр итеп бирү) керә.***

## Диктантлар

***Диктант укучыларның орфографик һәм пунктуацион яктан белемнәрен тикшерү максатыннан яздырыла һәм, башкарылу алымнарына карап, ике төргә бүлеп йөртелә: өйрәтү һәм контроль диктантлар.***

***Өйрәтү диктантларына сүзлек диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, ирекле, сайланма, хәтер, иҗади һәм күрмә диктантлар керә.***

***Контроль диктантлар, гадәттә, тема үтелеп беткәч һәм уку елының беренче, икенче яртысы тәмамлангач яздырыла. Контроль диктант өчен алынган текстка өстәмәләр кертелми, бернинди аңлатма һәм искәртмәләр бирелми. Ләкин укучылар контроль диктантның булачагы, нинди орфограммаларны кабатларга кирәклеге турында алдан кисәтелә.***

***Сыйныфлар буенча контроль диктант күләме түбәндәгечә билгеләнә:***

| *Сыйныфлар* | *Сүзләр саны* | |
|---|---|---|
| | *Уку елы башында* | *Уку елы ахырында* |
| Y | ***100*** | ***110*** |
| YI | ***110*** | ***120*** |
| YII | ***120*** | ***130*** |
| YIII | ***130*** | ***140*** |
| IX | ***140*** | ***150*** |
| X | ***150*** | ***160*** |
| XI | ***160*** | ***170*** |

## Контроль диктантларны бәяләү:

| *№* | *Таләпләр* | *Билге* |
|---|---|---|
| ***1.*** | ***Орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаган эшкә***<br>***Искәрмә. Пөхтә эшләнгән 1 орфоргафик яки 1 пунктуацион хаталы эшкә*** | ***«5»ле билгесе куела.***<br>***«5»ле билгесе куела ала*** |
| ***2.*** | ***1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә***<br>***Искәрмә. 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки Бер*** | ***«4»ле билгесе куела***<br>***«4»ле билгесе куела*** |

| | | |
|---|---|---|
| | *төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә* | |
| *3.* | *2 орфографик, 1-3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә*<br>*Искәрмә. 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә* | *«3»ле билгесе куела*<br>*«3»ле билгесе куела* |
| *4.* | *5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә* | *«2»ле билгесе куела* |
| *5.* | *6-7 орфографик, 4-5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә* | *«1»ле билгесе куела* |

## Изложение яздыру һәм бәяләү

***Изложение язу өчен укучыга аңлаешлы телдә язылган хикәяләү характерындагы текст алына.***

***Изложение язганда балаларның бәйләнешле фикер йөртә белү сәләте генә түгел, ана теленең орфографик, грамматик, стилистик һәм пунктуацион үзенчәлекләрен белүләренә, текст эчтәлегеннән чыгып, нәтиҗә ясый белү сәләтенә, сүз байлыгыннан файдалана белү мөмкинлекләренә дә бәя бирелә.***

| *Сыйныфлар* | *Изложение саны* | *Уку елы башында* | | *Уку елы ахырында* | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *Текст күләме* | *Язма күләме* | *Текст күләме* | *Язма күләме* |
| Y | ***8 (2)*** | ***150-170*** | ***100-110*** | ***170-200*** | ***110-120*** |
| YI | ***6 (2)*** | ***200-220*** | ***120-130*** | ***220-250*** | ***130-140*** |
| YII | ***6 (2)*** | ***250-300*** | ***140-160*** | ***300-350*** | ***160-180*** |
| YIII | ***6 (2)*** | ***350-400*** | ***180-200*** | ***400-450*** | ***200-220*** |
| IX | ***4 (2)*** | ***450-475*** | ***220-240*** | ***475-500*** | ***240-250*** |
| X | ***2 (1)*** | ***475-500*** | ***240-250*** | ***500-525*** | ***250-260*** |
| XI | ***2 (1)*** | ***500-525*** | ***250-260*** | ***525-550*** | ***260-275*** |

## Изложениене бәяләү

| *№* | *Текстның бирелеше* | *Грамоталылыгы* | *Билге* |
|---|---|---|---|
| *1.* | *Текст, планга нигезләнеп, эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган, фактик һәм техник хаталар юк.* | *1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар.* | *«5» ле билгесе куела* |
| *2.* | *Текст хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры* | *2 орфографик, 1 пунктуацион (яки 1* | *«4» ле билгесе* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик, 1 техник хата җибәрелгән.* | *грамматик) хата бар.* | *куела* |
| *3.* | *Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган; сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик, 2 техник хата җибәрелгән.* | *3 орфографик, 2 пунктуацион 1грамматик хата бар.* | *«3» ле билгесе куела* |
| *4.* | *Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган; стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар күп.* | *Орфографик хаталарның саны өчтән, пунктуацион хаталарның саны икедән, грамматик хаталарның саны өчтән артык* | *«2» ле билгесе куела* |
| *5.* | *Текстның эзлеклелеге сакланмаган; сүзләр һәм җөмләләрбәйләнешендә җибәрелгән хаталар текстның эчтәлеген аңлауны кыенлаштыра, техник хаталар бик күп.* | *Төгәлсезлекләр «2»ле нормасыннан артып китсә* | *«1» ле билгесе куела* |

## Сочинение яздыру

***Сочинение укучыларның тормыш күзәтүләреннән алган тәэсирләрен язмада грамоталы һәм эзлекле бирә, әдәби әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән образлы телдә бәйләнешле итеп яза алу мөмкинлеген тикшерү максатыннан яздырыла.***

***Әдәби сочинениеләр нинди дә булса әсәр үтелеп беткәч яздырыла, андый сочинениеләр 5-8 сыйныфларда өйрәтү һәм контроль, 9-11 сыйныфларда контроль сочинение буларак үткәрелә.***

***Әдәби-иҗади сочинениеләр мөстәкыйль укылган яки дәресләрендә үткән әсәргә, андагы образ һәм вакыйгаларга карата укучы фикерен белү максатыннан яздырыла.***

***Өйрәтү характерындагы сочинениеләрне язганда, укучы текст, әсәр турында тәнкыйть материалларныннан, сүзлекләрдән файдалана.***

***Ирекле сочинениеләрдә тәкъдим ителгән теманы үзенчә ача, вакыйга һәм геройларга, геройларның үзара мөнәсәбәтенәбәя бирә, үз фикерен исбатлау өчен, башка чыганаклардан файдалана.***

## Сочинениене бәяләү

| № | *Текстның бирелеше* | *Грамоталылыгы* | *Билге* |
|---|---|---|---|
| *1.* | *Эчтәлек темага туры килә, язмада фактик ялгышлар юк; план буенча эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган.* | *1 орфографик (пунктуацион яки грамматик) ялгыш бар.* | *«5» ле билгесе куела* |
| *2.* | *Язманың эчтәлеге темага нигездә туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, теле бай, образлы; стиль, бердәмлеге сакланган.* | *2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар.* | *«4» ле билгесе куела* |
| *3.* | *Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теле ярлы, синонимнар аз кулланылган, образлы түгел; стиль бердәмлеге сакланмаган.* | *3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар.* | *«3» ле билгесе куела* |
| *4.* | *Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз кулану ялгышлары очрый; стиль бердәмлеге юк.* | *7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар.* | *«2» ле билгесе куела* |
| *5.* | *Төгәлсезлекләр билгесе «2»ле кую нормасыннан артып киткән.* | *Ялгышлары «2»ле билгесе кую нормасыннан артык.* | *«1» ле билгесе куела* |

***Язма эштән соң беренче юлга, кызыл юл турысыннан башлап, ялгышларның саны күрсәтелә: башта орфографик, аннан пунктуацион һәм стилистик хаталар саны ике нокта Аша күрсәтелә. Мәсәлән: 1:2:3. Бу язылыш 1 орфографик, 2 пунктуацион, 3 стиль хатасы барлыкны күрсәтә.***



РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ
“Д.И.Менделеев исемендәге Тубыл дәүләт социаль-педагогия академиясе”

Филология факультеты

Татар теле, әдәбияты һәм укыту методикалары кафедрасы



**К.С. САДЫКОВ**

# ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕННӘН КАГЫЙДӘЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ

Урта мәктәп укытучылары һәм педагогика институтының
татар теле бүлеге студентлары өчен
укыту-методик кулланма

**ТУБЫЛ 2009**

УДК 809.432.1
ББК 81.632.3
С 14

Утверждено на заседании кафедры
татарского языка, литературы и МП
«25» сентября 2009 г.

В данный сборник собраны правила татарского литературного языка по фонетике, орфографии, орфоэпии, словообразованию, лексике, морфологии, синтаксису. Объясняются трудные случаи правописания, даются схемы анализа, вопросы и задания для самостоятельной работы. Рекомендуется в качестве учебно-методического пособия учителям средних общеобразовательных школ, студентам дневной и заочной форм обучения, абитуриентам / составитель К.С.Садыков.- Тобольск: Тобольская государственная педагогическая академия им. Д.И.Менделеева, 2009.

**Составитель:**
**Садыков К.С.**, кандидат педагогических наук, доцент кафедры татарского языка, литературы и МП ТобГСПА им. Д.И.Менделеева.

**Рецензенты:**
**М.А. Сагидуллин** – кандидат филологических наук,
доцент Тюменского государственного университета
**Ф.С. Сайфулина** – доктор филологических наук, доцент

© Садыков Клим Султанович, 2009
© Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева
ТОБОЛЬСК 2009

## КЕРЕШ

***Бу җыентык – тел гыйлеменең фонетика, графика, орфография, морфология, синтаксис бүлекләренә караган төп төшенчәләр һәм кагыйдәләр тупланмасы. Методик кулланма институтның татар бүлегендә укучы студентларга, ана теле укытучыларына татар әдәби теле үзенчәлекләрен искә төшерү һәм белемнәрен системага салу, мәктәптә укыту процессында тел гыйлеменең төрле бүлекләрен өйрәнгәндә куллану максатын искә алып төзелде. Һәрбер бүлеккә анализ үрнәкләре тәкъдим ителә, мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр дә бирелә,***

***Җыентыкны төзегәндә хәзерге татар әдәби теле буенча Р.С.Абдуллина, Т.М.Гайнуллина, Н.С.Гыймадиева, М.З.Зәкиев, К.З.Зиннәтуллина, С.М.Ибраһимов, Н.В.Максимов, Б.М.Мифтахов, Ф.С.Сафиуллина, Г.М.Сөнгатов, Д.Г.Тумашева, Ф.Ф.Фатыйхова, М.З.Хәмидуллина, Г.М.Шәйхиева, Р.В.Юсупов хезмәтләреннән файдаландык.***

## ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ ҺӘМ АНЫҢ ӨЛЕШЛӘРЕ

***Тел гыйлеме – тел турындагы фән, ягъни лингвистика. Ул телнең төрле якларын өйрәнә торган аерым бүлекләрдән тора:***

- ***фонетика – телнең авазлар составын, аларның кулланыш үзенчәлекләрен өйрәнә;***
- ***графика – авазларның язуда бирелешен, орфография – дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнәләр;***
- ***пунктуация – тыныш билгеләрен кую нигезләрен өйрәнә.***

***Болардан тыш тел гыйлеменең лексика, сүзьясалышы, грамматика бүлекләре бар.***

***Лексика - телдәге сүзләр җыелмасы, лексикология сүзлек байлыгын өйрәнә. Лексикологиянең тармаклары булган семасиология – сүзләрнең мәгънәсен, этимология – сүзләрнең килеп чыгышын, фразеология – телдә бер төшенчә белдерү өчен яраклашып катып калган тотрыклы төзелмәләрне, лексикография – телдәге сүзләрне җыю, сүзлекләр төзү, сүзлекләрнең төрләрен өйрәнәләр.***

***Сүзьясалышы бүлеге сүзнең төзелешен һәм ясалу ысулларын өйрәнә.***

***Грамматика – тел гыйлеменең сүзләр, сүзтезмә һәм җөмләләрнең төзелеше турындагы тармагы. Аның бүлекләре булган морфология сүз төркемнәрен, ә синтаксис сөйләм төзелешен өйрәнәләр.***

## ФОНЕТИКА

***Авазларны төрле яклап өйрәнә торган фән фонетика дип атала. (Аваз – сөйләмнең бүленми торган иң кечкенә кисәге, хәреф – авазның язудагы шартлы билгесе).***

***Авазлар ике төргә бүленә: сузык һәм тартык.***

***Сузык авазны әйткәндә үпкәдән килә торган һава бернинди тоткарлыкка очрамый, ул бары тик тавыштан гына тора. Хәзерге татар әдәби телендә 12 сузык бар: шуның тугызы татарныкы (а - ә, о - ө, у - ү, ы – е, и) һәм 3 алынма сузык (<u>о</u>, <u>ы</u>, <u>э</u>).***

***Калын сузыклар: [а], [о], [у], [ы]; рус теленнән кергән сүзләрдә [<u>о</u>], [<u>ы</u>], [<u>э</u>] – киң әйтелешле сузыклар кулланыла.***

***Нечкә сузыклар: [ә], [ө], [ү], [е], [и], [э].***

***Иренләшкән сузыклар: [у], [ү], [о], [ө].***

***Иренләшмәгән сузыклар: [ы], [е], [а], [ә], [и].***

**Сузык авазлар таблицасы**

| *Күтәрелеш* | *Алгы рәт* | *Арткы рәт* |
|---|---|---|
| *Югары* | *[ и ] [ ү ]* | *[ <u>ы</u> ] [ у ]* |
| *Урта* | *[ е ] [ <u>е</u> ] [ ө ]* | *[ о ] [ ы ] [ <u>о</u> ]* |
| *Түбән* | *[ ә ]* | *[ а ]* |

***Сузык аваз – иҗек ясаучы берәмлек. Татар телендә сүз кисәкләре юлдан юлга сүзнең иҗеккә бүленгән урыныннан күчерелә: тө-зе-леш, бак-ча-чы-лар. Шуңа күрә сүзнең иҗек тәшкил итмәгән кисәген юл азагында калдырырга да, икенче юлга күчерергә дә ярамый: октя-брь түгел. Ялгыз бер хәреф юл азагында калдырылмый, икенче юлга да күчерелми: у-куы яки уку-ы түгел.***

***Тартык авазларны әйткәндә, үпкәдән чыккан һава агымы нинди дә булса торкарлыкка очрый. Хәзерге татар әдәби телендә 28 тартык аваз бар.***

***Авазларны әйткәндә тавышның катнашу дәрәҗәсенә карап, тартыклар яңгырау, саңгырау һәм сонантларга бүленәләр. Саңгырау тартыклар бары тик шаудан гына торалар. Яңгырау тартыкларны әйткәндә шау да, азрак тавыш та катнаша. Сонор тартыклар әйтелешендә шау азрак, тавыш күбрәк була.***

***Тартыкларның күбесе яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта парлашалар.***

***Яңгырау тартыклар: б в г гъ д ж з җ л м н ң й р w***
***Саңгырау тартыклар: п ф к къ т ш с ч х ц щ һ [,]***

***Искәрмә: [w] авазы язуда иҗек башында в хәрефе белән, иҗек ахырында у һәм ү хәрефләре белән белдерелә: [wакъыт] – вакыт, [таw] – тау, [күрүw] – күрү.***
***[,] – бугаз тартыгы – һәмзә. Иҗек ахырында язуда белдерү өчен э хәрефен язалар: маэмай; нечкә иҗектән соң иҗек башында килсә, ь хәрефе белән белдерелә: мәсьәлә; калын иҗектән соң килсә, ъ хәрефе белән белдерелә: Коръән. [къ] һәм [гъ] – язуда к һәм г хәрефләре белән күрсәтелә.***

**Тартыкларны төркемләү таблицасы**

| *Ясалу урыны* | *Яңгырау* | *Саңгырау* | *Сонор* |
|---|---|---|---|
| *Ирен-ирен* | *б* | *п* | *м, w* |
| *Ирен-теш* | *в* | *ф* | |
| *Тел алды* | *д, ж, з, җ* | *т, ш, с, ч, ц, щ* | *л, н, р* |
| *Тел уртасы* | | | *й* |
| *Тел арты* | *г* | *к* | |
| *Кече тел (увуляр)* | ғ (гъ) | қ (къ), *х* | *ң* |
| *Йоткылык (фарингаль)* | | *Һ* | |
| *Бугаз (ларингаль)* | | *[,] – һәмзә* | |

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Хәзерге татар әдәби телендә ничә сузык аваз бар, алар нинди авазлар?***
2. ***Сузыклар нинди төркемнәргә бүленәләр? Һәр төркемгә кергән сузыкларны әйтеп чыгыгыз.***
3. ***Хәзерге татар әдәби телендә ничә тартык аваз бар, алар нинди авазлар?***

4. ***Тавыш һәм шау катнашу ягыннан тартык авазлар нинди төркемнәргә бүленәләр? Бу төркемнәргә кайсы тартыклар керә?***
5. ***Ясалу урынына карап, тартыклар нинди төркемнәргә бүленәләр һәм аларга кайсы тартык авазлар керә?***

**Аваз үзгәрешләре**

***Сингармонизм – сузык авазларның сүз эчендә бер-берсенә охшашлануы (сузыклар ассимиляциясе).***

1. ***Рәт гармониясе. Сузык авазлар сүздә калынлыкта яки нечкәлектә ярашалар: бардылар, килделәр.***
   ***Сузыклар ярашуының бу төренә буйсынмыйлар:***
   ***а) алынма сүзләр: китап, фабрика;***
   ***б) ике тамырдан торган кушма сүзләр: төнбоек, берьюлы;***
   ***в) миңа, сиңа, зәңгәрсу кебек сүзләр.***

***Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрдә кушымчалар сүзнең соңгы иҗегендәге сузыкка карап ялгана: калын булса – калын кушымча: телевизорда, нечкә булса – нечкә кушымча: төрекчә, станциядә.***

***Искәрмә: рус алынмалары гадәттә калын кушымчалар ала: осетрны, медикаментлар, режиссерга.***

***Алынма сүзләрнең –ль, -ия, -ие гә беткәннәренә нечкә кушымчалар ялгана. Сүз ахырында ь төшеп кала: моделе, артеле, учреждение-не, революция-се. -ль, -ость кә беткәннәренә дә нечкә кушымчалар ялгана: ведомосте, гастрольгә;***

***Власть, секретарь, календарь кебек сүзләр тартым белән төрләнгәндә, тартымның I һәм II зат күплек кушымчаларында беренче иҗек – нечкә, икенчесе – калын була: власть – властена, календарь – календаребыз, повесть – повестенда.***

2. ***Ирен гармониясе. Ирենләшкән сузыклар [о] һәм [ө] авазлары үзләреннән соң килгән [ы] [е] авазларын иренләштерәләр: бөтен [бөтөн], колын [колон].***

***Татар телендәге сүзләрдә о, ө хәрефләре 1 нче иҗектә генә языла, башка иҗекләрдә иренләшү процессы булса да, язылмый, ы, е хәрефләре килә. Ә кушма сүзләрне ике сүз итеп карарга кирәк: бербөтен (бер+бөтен), өчпочмак (өч+почмак).***

***Ассимиляция – тартыкларның бер-берсенә охшашлануы.***

***1. Уңай (прогрессив) ассимиляция.***

***а) яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта ярашу. Бу очракта яңгырау тартыкка беткән сүзләргә - яңгырау тартыктан башланган, саңгырауга беткән сүзләргә саңгыраудан башланган кушымчалар ялгана: сүздә, кырда, йөрәктә, бардыр; б) борын ассимиляциясе булганда борын авазына беткән сүзләргә борын авазыннан башланган кушымчалар ялгана: таңнар, урамнан, төнне.***

***2. Кире (регрессив) ассимиляция (арттан килгән аваз алдагы авазны охшашландыра) әйтелештә генә күзәтелә, язуда чагылыш тапмый. Бу – ирен ассимиляциясе: унбиш (умбиш), көнбагыш (көмбагыш).***

***Аваз чиратлашу күренеше. 1. Сүз ахырында саңгырау п, к, къ тартыклары сүзгә сузыктан башланган һәм -рак, -рәк кушымчалары ялганганда, яңгырау парлары белән чиратлашалар: п-б, к-г, къ-гъ. Мәсәлән, тарак – тарагы, түп – төбе, күрәк – күрәге, сирәк – сирәгрәк.***
***2. Сүз ахырында яңгырау тартыклар саңгырау парлары белән чиратлашалар: завод (завот), коллектив (коллектиф), клуб (клуп). Мондый сүзләрне дөрес язу өчен сүз ахырына сузык аваз кушымчалары куеп карарга кирәк: клубы, флагы, составы, теплоходы. Бу сүзләргә юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә саңгырау аваздан башланган кушымчалар ялгана: клубка, заводтан, коллективта.***

***Дифтонг – бер иҗектә янәшә килгән ике сузык кушылмасы. Татар телендә ау-әү (яу-яү) дифтонглары бар. Дифтонгларга беткән сүзләргә сузык аваз кушымчалары ялганганда, у, ү хәрефләре в хәрефе белән алмашына: тау – тавы, түләү – түләве, бау – бавы.***

***Истә тотыгыз:***

- ***Татар телендә ц, щ, ё хәрефләре кергән сүзләр бөтенләй юк. Алар – алынмалар: ёлка, щетка, цирк, самолёт, клеёнка;***
- ***ң хәрефе белән сүз башланмый;***
- ***е, ю, я хәрефләре икешәр авазга билге булып йөри-ләр: е – [йы], [йэ] ерак, елан, ерым; ю – [йу], [йү] юл, юкә; я – [йа], [йә] яка, яшел.***

***Я, ю хәрефләре сүз азагында калын да, нечкә дә булып киләләр. Мәсәлән, дәрья, әдәбият, дөнья сүзләрендә ул калын авазны белдерә һәм калын кушымча ала: дәрьялар, әдәбияты, дөньясы. Галия, армия, мәдәният сүзләрендә нечкә әйтелә һәм нечкә кушымчалар ала: Галиянең, армиягә, мәдәниятне.***

***Сүз башындагы ю, я хәрефләренең нечкәлеген белдерү өчен, бу хәрефләрдән соң килгән тартык артыннан нечкә сузык аваз хәрефе булмаса, нечкәлек билгесе куела: яшь, ямьле, юньле, япь-яшь.***

***Кушма сүзнең икенчесе я, ю, е хәрефенә башланса, алар арасына аеру билгеләре ь, ъ куела. Беренче тамыр нечкә булса, нечкәлек билгесе, калын булса, калынлык билгесе куела. Мисаллар: төньяк, берьюлы, елъязма, алъяпкыч.***

### Сүзләргә фонетик анализ ясау тәртибе

1. ***Сүзне иҗекләргә бүлеп, басымын күрсәтергә.***
2. ***Сүздә авазлар һәм хәрефләр санын билгеләргә.***
3. ***Авазларны һәм хәрефләрне рәттән санап чыгарга.***
4. ***Сузык авазларга характеристика бирергә. Сүз сингармонизм законына буйсынамы?***
5. ***Тартык авазларга характеристика.***
6. ***Сүзнең әйтелеше белән язылышы туры киләме? Килмәсә, сәбәбен аңлатырга.***

***Бирем: ишек, табигать, бишьеллык, Әкълимә сүзләренә фонетик анализ ясагыз.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. *Аваз үзгәрешләре нилектән килеп чыга?*
2. *Татар телендә еш күзәтелә торган нинди аваз үзгәрешләрен беләсез?*
3. *Нинди фонетик күренеш сингармонизм законы дип атала?*
4. *Сингармонизмның төрләрен әйтегез. Мисаллар китерегез.*
5. *Нәрсә ул тартыклар ассимиляциясе? Аның нинди төрләре бар?*
6. *Тартыклар ассимиляциясенә мисаллар китерегез.*
7. *Аваз чиратлашуы кайсы авазларга кагыла? Мисаллар китерегез.*
8. *Редукция күренешен мисаллар белән аңлатыгыз.*

## Графика һәм орфография

### Графика

***Графика турында гомуми төшенчә.** Язуда кулланыла торган хәрефләрнең билгеле бер тәртиптә урнаштырылып бирелүе алфавит дип йөртелә. (Бу сүз грек алфавитындагы беренче ике хәреф исеменнән – “альфа” һәм “бета”, татар телендә - әлифба, шулай ук гарәп алфавитының беренче ике хәреф исеменнән: “әлиф”, “би”дән алынган.) Хәрефләрнең формасын һәм аларның телдәге авазларга туры килүен тел гыйлеменең графика дигән бүлеге өйрәнә (graphike – грекча “рәсем төшерү”). Алфавиттагы хәрефләрне кулланып, сүзләрне дөрес язу орфография кагыйдәләре белән билгеләнә.*

*Алфавит һәм орфография әдәби телгә нигезләнеп төзелә. Әдәби телдә булмаган диалект һәм сөйләш үзенчәлекләре орфографиядә чагылыш тапмыйлар. Татар графикасы аваз-хәреф язуыннан гыйбарәт. Телдәге авазлар шартлы график билгеләр – хәрефләр белән билгеләнә. Хәзерге татар алфавиты 39 хәрефтән тора. Басма һәм кулъязма хәрефләрнең баш һәм юл хәрефе формалары бар:*
*Аа, Бб, Вв, Гг, Дд, Ее, Ёё, Жж, Зз, Ии, Йй, Кк, Лл, Мм, Нн, Оо, Пп, Рр, Сс, Тт, Уу, Фф, Хх, Цц, Чч, Шш, Щщ, Ъъ, Ыы, Ьь, Ээ, Юю, Яя, Әә, Өө, Үү, Җҗ, Ңң, Һһ.*

*Алфавиттагы хәрефләрнең татар телендәге фонемаларга туры килеше. Татар теленең къ, гъ, w һәм һәмзә [ , ] авазларыннан башка барлык фонемалары өчен дә язуда аерым хәрефләр бар. Ләкин кайбер хәрефләр татар теленең үз фонемаларын гына түгел, рус теленнән яки аның аша бүтән телләрдән кергән фонемаларны да белдерәләр. Бу очракта бер хәреф ике төрле фонема билгесе булып йөри.*

*Сузык фонемалар.*

*Калын сузыклар – а, о, у, ы, ый, нечкәләре - ә, ө, ү, э-е, и хәрефләре белән бирелә. Калын сузыкларны белдергән хәрефләр – сүзләрнең калын иҗекләрендә, нечкә сузыкларны белдергәннәре нечкә иҗекләрдә языла: карга, бакча, чаңгы, урман, ботак, Барый; күлмәк, көмеш, үрдәк, элемтә, икмәк.*

*А хәрефе а фонемасын белдерә: кар, чана, урам; а хәрефе шулай ук күп иҗекле сүзләрнең беренче иҗекләрендә - а фонемасы о-лаштырып әйтелгән очракларда да языла: багана, баганалар, бакчаларда.*

***Йа, йу дифтонглары я, ю хәрефләре белән бирелә: якты, юл, юрган, якын.***

***О, ө хәрефләре татар теленең тар о, ө фонемаларын белдерә һәм бер тамырлы сүзләрнең беренче иҗегендә языла; калган иҗекләрдә иренләштерелгән ыо, еө авазлары ы, е хәрефләре белән бирелә: борынгы, солы, бөрлегән, бөтергеч. О, ө хәрефләре кушма сүзләрнең икенче тамырындагы беренче иҗектә дә саклана: аккош, озынборын.***

***Ы, е хәрефләре татар теленең тар әйтелешле ы, е фонемаларын белдерә: ыргак, кыр, ышкы; келәм, кеше, без. Сүз башында е фонемасы э хәрефе белән бирелә: эт, эл, эссе.***

***Е хәрефе сүз һәм иҗек башында йы – йе әйтелешләрен белдерә: ел, елан, егет, каен, җәен, поезд.***

***Ә, у, ү, и хәрефләре ә, у, ү, и фонемаларын белдерәләр һәм сүзнең шул авазлар әйтелгән һәр урынында языла: әңгәмә, буран, бүлмә, киртә.***

***Сүз һәм иҗек ахырында у, ү хәрефләре w фонемасын белдерә: тау, бау, яуда, дәү.***

***Ый – и фонемасының калын парына – ый дифтонгына билге булып йөри: ярый, сый, сайрый.***

***А, о, у, ы, ый хәрефләренең к, г хәрефләре янында ә, ө, ү, е, и авазлары өчен язылу очрагы да бар. Бу очракта а, о, у, ы, ый хәрефләре шартлы рәвештә к, г хәрефләренең к, г түгел, бәлки къ, гъ фонемалары булып укылуын белдерә: каләм, табигый, Гали.***

***Әгәр дә андый иҗек тартык авазга бетсә, ул тартыктан соң нечкәлек билгесе куела: табигать, Сәгыйть, шагыйрь.***

***Әгәр къ, гъ авазлары иҗек ахырында булып, аннан соң берәр тартык аваз килсә яки сүз шунда тәмамланса, к, г хәрефләренең къ, гъ булып укылуын белдерү өчен ъ билгесе языла: нәкъ, дикъкать, дәгъва.***

***Рус теленнән яки аның аша башка телләрдән кергән сүзләрдә о, ы, э-е хәрефләре үзенә башка төрле фонемаларны – киң әйтелешле о, ы, э-е сузыкларын күрсәтәләр: вагон, завод, поэма, тезис, посылка, эра, промышленность.***

***Алфавиттагы я, ю хәрефләре и авазы төсмере белән әйтелүче нечкә (палаталь) тартыклардан соң – а, у фонемаларын, сүз һәм иҗек башларында исә йа, йу авазларын белдерә һәм беренче очракта рус теленнән яки аның аша башка телдән кергән сүзләрдә генә, ә икенче очракта татар сүзләрендә генә кулланыла: отряд, революция, бюро, юбилей, июль; яз, югары. Я, ю хәрефләре татар сүзләрендә шулай ук йә, йү әйтелешен дә белдерә: юкә, яшь, җәю, җәя.***

### Тартык фонемалар

***Татар телендә тартык авазларның калынлыгы-нечкәлеге сузыкларның нинди булуына бәйле. Шунлыктан тартык авазларның калын һәм нечкә вариантларына икесенә бер генә хәреф алына: болын, тора, сора; бүлмә, төрә, сөрә.***

***Къ һәм к фонемалары – к хәрефе белән, гъ, г исә г хәрефе белән берләштереп бирелә: канат (къанат һәм канат), карта (къарта һәм карта), агым, сәгать, күбәләк, Гәрәй.***

***Тартык фонемаларның яңгырау һәм саңгырау парлары татар алфавитында аерым хәрефләр белән бирелә: б – п, в – ф, г – к, д – т, ж – ш, җ – ч, з – с, һ – х.***

***Үзенчәлекле тартык – һәмзә э, ь, ъ хәрефләре белән күрсәтелә: тәэсир, тәэмин, маэмай, мәсьүл, мәсьәлә, коръән.***

***В хәрефе татар сүзләрендә (сүз һәм иҗек башларында) w авазы өчен языла: вакыт, ватан, дәвер, савыт. Рус теленнән кергән сүзләрдә һәм фамилия ясагыч -ова, -ева кушымчаларында в хәрефе ирен-теш тартыгын белдерә: вагон, завод, Сәлимова.***

***Ц, щ хәрефләре рус теленнән яки аның аша башка телләрдән кергән сүзләрдә генә языла: цирк, циркуль, щётка, борщ, щи.***

## ОРФОГРАФИЯ

***Орфография турында гомуми төшенчә. Орфография (грекча “orthos” - дөрес һәм “grapho” – язам сүзләреннән) – гомуми кабул ителгән, бердәм нормаларга салынган (унификацияләнгән) һәм һәркемгә мәҗбүри саналган практик язу системасы. Орфография сүзләрнең һәм кушымчаларның дөрес язылышын, сүзләрнең аерым яки кушылып язылуларын, баш хәрефләрнең кулланылышын һәм сүз кисәкләрен юлдан юлга күчерүне билгели, аларны кагыйдәләштереп бирә. Орфография кагыйдәләренә шулай ук мәгънә аеру язылышлары (дифференциацияләнгән язылыш) да керә.***

***Татар орфографиясенең төп принцибы. Орфография төзүдә берничә принцип бар: фонетик, морфологик, тарихи-традицион һәм график принциплар. Теориядә дә, практикада да иң яхшы, иң уңай дип танылганы – фонетик принцип. Чөнки сүздә нинди аваз әйтелсә, шуларның үз график билгеләрен куеп язу ансат та, фонетик яктан төгәл дә. Хәзерге татар язуы, башлыча, шул принципка нигезләнгән. Татар әдәби телендә сүзләр ничек, нинди авазлар белән әйтелсә, шулай языла – бу безнең орфография өчен төп кагыйдә. Татар язуында бу кагыйдәнең тотрыклы үткәрелүе телебез өчен хас сингармонизм законын – калын сүзләрнең калын сузыклар, нечкәләрнең – нечкә сузыклар белән генә әйтелүен (мәсәлән, йортларның – чәчәкләрнең) анык чагылдыруда гына түгел, күп очракта авазларның төрле-төрле комбинатор үзгәрүләрен, чиратлашуларын тулысынча бирүдә дә күренә. Мәсәлән, тамыр яки нигез азагындагы къ, к, п авазлары сүзгә сузык яки сонор аваздан башланган кушымча ялгану белән, гъ, г, б авазларына әйләнә, һәм моны орфография дә кире какмый: ак – агы, аграк, ефәк – ефәге, китап – китабы. Күплек кушымчасы -лар, -ләр борын авазларыннан соң -нар, -нәр формасын ала һәм шулай языла да: урманнар, болыннар, таңнар, үләннәр. Нинди аваздан соң килүләренә карап, юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләренең кушымчалары берничә төрле вариантта йөри: атка, эшкә, бакчага, үләнгә һ.б.***

***Морфологик принцип. Сүз төрләнү белән, авазлары күп төрле чиратлашулар, комбинатор үзгәрешләр кичерә торган телләр (мәсәлән рус теле) өчен фонетик принцип төп нигез була алмый. Шуңа күрә андый телләр өчен беренче чиратта морфологик принцип характерлы. Морфологик принцип сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язуны, сүз үзгәрү белән, алардагы аваз үзгәрешләрен күрсәтеп тормауны максат итеп куя. Кайсы телдә генә булмасын, орфография бер генә принцип белән чикләнеп кала алмый. Татар язуында да кайбер очракларда морфологик принцип кирәк булып чыга. Мәсәлән, з, н, л авазларына беткән сүзләрдә бу тартыклар, күрше авазга ияреп, с, м, ң, н булып ишетелсә дә, яки ике сүз чигендә янәшә сузыкларның берсе йотылса да, яисә сузыклар арасына туры килеп, саңгырау тартык яңгырауга әйләнсә дә, сүзнең (тамырның, нигезнең яки андагы кушымчаның) мәгънә ачыклыгы югалмасын өчен, бу үзгәрешләр язуда күрсәтелми: мәсәлән, әнкәй, утынлык, унбер, буранлы сүзләре әңкәй, утынның, умбер, буранны формасында түгел, ә язылганча бирелә. Чакыру, исеме, сеңелесе кебек сүзләрне, җанлы сөйләмдәгечә чакру, исме, сеңлесе рәвешендә ы-е авазларын төшереп калдырып түгел, бәлки тулысынча (сүзнең тамырын үзгәртмичә - чакыру, исеме, сеңел) язу да морфологик принципка карый.***

***Тарихи-традицион принцип. Бу – сүзләрне, хәзерге телдә ничек әйтелүенә карамастан, борынгы чорда ничек язылган, шулай язу дигән сүз. Бу принцип язу кагыйдәләре берничә йөз еллар буенча шул килеш сакланган телләрдә генә була, чөнки сүзләрнең әйтелеше гасырлар дәвамында үзгәрә, ә язу кагыйдәләре элеккечә сакланып килә. Тарихи-традицион принцип инглиз һәм француз, гарәп орфографияләре өчен хас. Мәсәлән, [төзөлөш] – төзелеш, [комлок] – комлык.***

***График принцип. Бу – алынма сүзләрне шул тел орфографиясендәгечә язу дигән сүз. Мәсәлән, татар телендә рус теленнән алынган сүзләр рус теле орфографиясендәгечә языла: морфология, марксизм, революция, лексикология.***

***Дифференциаль принцип – омонимик очракларны бер-берсеннән аеру өчен кирәк: өч почмак (три угла), өчпочмак (треугольник), ак сакал (белая борода), аксакал (уважаемый старец).***

***Орфография белән орфоэпия тыгыз бәйләнештә тора. Орфоэпия – авазларны дөрес әйтү кагыйдәләре. Ул фонемаларның һәм аларның вариантларының нинди фонетик шартларда ничек әйтелүен билгели. Аңа шулай ук аерым сүзләрдәге, сүзтезмәләрдәге (яки сүз араларындагы) һәм хәтта кайбер грамматик формалардагы авазларның язудагыга туры килми торган әйтелеш очракларын күрсәтү дә керә.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Нәрсә ул орфография? Орфографик кагыйдәләрне аңлатыгыз.***
2. ***Нәрсә ул орфоэпия? Татар һәм рус телләрендә бер үк хәрефләр белән белдерелеп тә, әйтелешләрендә аерма булган авазларны әйтегез.***
3. ***Сезнең нинди орфоэпик хаталар ишеткәнегез бар?***

# ЛЕКСИКА

***Лексика – сүзләр җыелмасы, телнең сүзлек составы. Сүз күп яклы һәм катлаулы тел берәмлеге. Һәр сүзгә төп һәм күчерелмә мәгънәләре, килеп чыгышы, кулланыш үзенчәлеге, төзелеше һәм башка яклардан характеристика биреп була. Лексикология – тел белеменең лексиканы тикшерә торган бер тармагы.***

***Синонимнар дип бердәй яки якын мәгънәле сүзләргә әйтәләр: матур – гүзәл, сылу, чибәр; батыр – кыю; башлы – зирәк, белемле, акыллы.***

***Антонимнар – капма-каршы мәгънәле сүзләр: кечкенә - зур; аста - өстә; биек – тәбәнәк.***

***Омонимнар – бер төрле яңгырашлы, ләкин бернинди дә мәгънә уртаклыгы булмаган сүзләр: йөз – сан, кешенең бите, суда йөзү; тиен – җәнлек, акча берәмлеге. Омонимнарны түбәндәге төркемнәргә бүлергә мөмкин:***

***а) омофоннар – язылышы төрле, әмма әйтелешләре бер төрле сүзләр: карт аю – картаю; Айтуган – ай туган.***

***б) омографлар – язылышлары бер, әйтелешләрендә аерма бар: карта (къарта) – карта, ярм`а – `ярма.***

***в) омоформалар – билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр: өй (исем) - өй (боерык фигыль), йөз (сан) – йөз (боерык фигыль).***

***г) паронимнар – охшаш яңгырашлы сүзләр: тугры (верный) – туры (прямой), гыйбарәт (түбәндәгедән гыйбарәт, состоит в следующем) – гыйбрәт (гыйбрәт алу, получить урок).***

***Фразеологизмнар – кимендә ике сүздән торган, күчерелмә мәгънәгә ия булган образлы сүзтезмәләр: колагына да элми; саламга ябышу; көймәсе комга утырган, сыбызгы сызу.***

***Метафора – бер атаманың икенче атамага охшашлыгы нигезендә күчеше: кеше борыны – көймә борыны; усал кеше – усал җил; ефәк күлмәк – ефәк чәч.***

***Метонимия – бер күренеш, әйбер яки кешене башка күренеш, әйбер, кешегә хас сыйфат, билге белән атау нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә: Зал елый, үкси иде (Һ.Такташ); аның кулы – кул кую.***

***Синекдоха – сүз мәгънәсе бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчә: ...әллә ничә авызлы булган бер семья... (Г.Тукай); Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде (Г.Тукай).***

## Татар теленең сүзлек составы

***Алынмалар – төрле телләрдән кереп, актив кулланылышта йөргән сүзләр: армия, бригада, штаб, китап, галим, әдип.***

***Интернациональ сүзләр – күп халыклар өчен уртак сүзләр: конгресс, паспорт, программа, дипломат.***

***Тарихи сүзләр – җәмгыятьнең үсеш тарихында предметлар, күренешләр юкка чыгу сәбәпле кулланыштан төшеп калган сүзләр. Алар күбрәк тарихи вакыйгаларны сурәтләгәндә кулланыла: урядник, алпавыт, тархан, жандарм.***

***Архаизмнар – нинди дә булса төшенчәнең, күренешнең искергән атамалары: ут – үлән, ат – исем, букча – сумка, эслүб – стиль.***

***Неологизмнар – телдә барлыкка килә торган яңа сүзләр: информатика, компьютер.***

***Профессионализмнар – билгеле бер һөнәр ияләренең эшчәнлегенә караган сүзләр: педагог, тапкырлау.***

***Пуризм – телнең чисталыгы өчен көрәш.***

***Калька – теге яки бу сүзне кисәкләп – морфемалап бер телдән икенче телгә тәрҗемә итеп, бербөтен сүз барлыкка китерү: многолетний – күпьеллык, показатель – күрсәткеч, великодушие – олыҗанлылык.***

***Лексикология составына ономастика, топонимика тармаклары да керә. Ономастика ялгызлык исемнәрне – исемнәр, фамилияләр, кушаматларның тарихын, топонимика ялгызлык характердагы географик атамаларны өйрәнә. Топономастика – бу ике тармакны берләштерүче фән. Ул үз эченә зоонимика (хайван атамалары), космонимика (күк җисемнәре исемнәре), гидронимика (сулыкларның атамалары) кебек тармакларны берләштерә.***

***Лексикологиянең телдәге сүзләрне җыю, сүзлекләрнең төрләрен өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы лексикография дип атала.***

***Сүзлекләр күп төрле: филологик сүзлекләр, телара сүзлекләр, аңлатмалы сүзлекләр, диалектологик сүзлекләр. фразеологик сүзлекләр, терминологик сүзлекләр, орфографик сүзлекләр, энциклопедик сүзлекләр һ.б.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Татар теленең сүзлек составында төп урынны нинди сүзләр алып тора?***
2. ***Нәрсә ул алынма сүз? Мисаллар китерегез.***
3. ***Нәрсә ул лексикография?***
4. ***Сүзлекләрнең төрләрен әйтегез.***
5. ***Аңлатмалы сүзлекнең төзелешен аңлатыгыз.***

## *СҮЗЬЯСАЛЫШЫ. СҮЗ ТӨЗЕЛЕШЕ*

***Тел белеменең сүзьясалышы бүлегендә сүзнең төзелеше һәм ясалу ысуллары өйрәнелә.***

***Сүз мәгънәле кисәкләрдән – морфемалардан тора. Сүзнең төп мәгънәсен үз эченә алган морфема тамыр дип атала. Сүзнең бер-бер артлы тамырга ялганып килеп, аңа нинди дә булса мәгънә өсти торган кисәкләре кушымчалар дип атала. Кушымчаларның өч төре бар: сүз ясагыч, форма ясагыч, төрләндергеч кушымчалар.***

***Сүз ясагыч кушымчалар сүзгә яңа мәгънә өсти һәм яңа сүз ясый. Мәсәлән: авыл – авылдаш, бас – баскыч, бүл – бүлмә.***

***Форма ясагыч кушымчалар сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртмичә, бер сүз төркеменең төрле төркемчәләрен билгеләр яки сүзләргә модаль төсмерләр өстиләр, сүзнең формасын үзгәртәләр. Алар килеш, тартым, зат-сан, заман, юнәлеш, дәрәҗә, юклык һәм затланышсыз фигыль кушымчалары. Боларның бер төрен бәйләгечләр (төрләндергечләр) дип атыйлар. Бәйләгечләргә исемнәрдә килеш һәм тартым кушымчалары, фигыльләрдә зат-сан кушымчалары керәләр. Форма ясагычларның икенче төрен модальлекләр яки төр кушымчалары дип йөртәләр.***

***Сүзнең төрләндергеч кушымчаларын аерып алганнан соң калган өлеше нигез дип атала. Нигез ике төрле була: 1. Морфемаларга таркатып булмый торган тамыр нигез: кыр, бала, эт. 2. Тамыр һәм сүз ясагыч кушымчадан торган ясалма нигез: баскыч, эшче, авылдаш.***

**Сүз төзелешен тикшерү тәртибе**

1. ***Сүзне җөмләдән алып, мәгънәле кисәкләргә таркатырга, ничә мәгънәле кисәктән торуын әйтергә.***
2. ***Сүзнең тамырын табарга, 2-3 тамырдаш сүз уйлап әйтергә.***
3. ***Кушымчаларның кайсы төркемгә керүләрен күрсәтергә.***
4. ***Нигезен билгеләргә.***

***Мисал: Авылдаш – авыл-даш, ике өлештән тора: авыл – тамыр, -даш – сүз ясагыч кушымча, тамырдаш сүзләр: авыллар, авылым, авылкаем, сүзнең нигезе – авылдаш.***

***Бирем: бакчачылык, файдаланмагансыз, үзенчәлекле сүзләрен төзелешләре ягыннан тикшерегез***

***Сүз ясалышы ысуллары***

***Сүз ясалышы ысуллары дип телнең үз чаралары ярдәмендә яңа сүзләр ясау юлларын, алымнарын атыйлар. Алар түбәндәгеләр:***

***Ясалма сүзләр – тамыр яки ясалма нигезгә сүз ясагыч кушымча ялганып ясалалар: бас-кыч, күз-лек, күз-лек-ле, тиз-лек.***

***Кушма сүзләр ике сүзнең кушылып бер мәгънә белдерүеннән барлыкка килгән сүзләр: төнбоек, алъяпкыч, көнбагыш, кулъязма.***

***Парлы сүзләр бер-берсенә я мәгънәдәш, я капма-каршы мәгънәле, я авазdaш сүзләрне теркәү, я бер үк сүзне кабатлау юлы белән ясалалар һәм сызыкча аша языла лар: исем-ат, ата-ана, лаштыр-лоштыр, тиз-тиз.***

***Тезмә сүзләр ике яки берничә сүздән торалар һәм бер мәгънә белдерәләр, бер сорауга җавап бирәләр, аерым язылалар: мүк җиләге, үги ана яфрагы, миләш чыпчыгы, Түбән өлкәсе.***

***Кыскартылма сүзләр - сүзләрнең я беренче авазлары, я беренче сүзнең бер өлеше, ә икенче сүз тулысынча, я һәр сүзнең берәр иҗеге алынып ясалган сүзләр: БМО, драмтүгәрәк, колхоз.***

***Сүзнең мәгънәсе киңәю нәтиҗәсендә дә яңа сүзләр ясала, бер сүз икенче сүз төркеменә күчә: йомгак – йон йомгагы, сүзне йомгаклау; сугыш – война, сугыш – дерись.***

***Авазлар үзгәрү нәтиҗәсендә дә сүз яңа мәгънә ала: тугъры – туры, сыпыру – себерү.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Сүз нинди морфемалардан тора?***
2. ***Нәрсә ул тамыр нигез, ясалма нигез, кушма нигез? Мисаллар китерегез.***
3. ***Сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү тәртибен мисаллар белән аңлатыгыз.***
4. ***Татар телендә сүзләр нинди юллар белән ясала? Мисаллар китерегез.***
5. ***Татар телендә тамыр үзгәрәме? Рус, гарәп-фарсы сүзләре белән чагыштырып сөйләгез.***

## МОРФОЛОГИЯ (СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ)

***Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелә торган сүзләр СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ дип аталалар. Сүз төркемнәрен өйрәнә торган фән морфология була. Татар телендә 13 сүз төркеме бар:***

***Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр.***

***Бәйләгеч сүз төркемнәре: теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, бәйлек һәм бәйлек сүзләр.***

***Модаль сүз төркемнәре: модаль сүзләр, кисәкчә, ымлык.***

***(Сүз төркемнәренең бүленеше “Татар грамматикасы. II том. Морфология”. – Казан, 2002 китабыннан алынды)***

## ИСЕМ

***Исем – предмет, күренеш һәм затларны белдерә һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә. Ул уртаклык һәм ялгызлык исемнәргә бүленә, конкрет һәм абстракт предметларны, төшенчәләрне белдерә ала. (Өстәл, бала – уртаклык исемнәр, Гали, Апуш, Җиңү бәйрәме – ялгызлык исемнәр; урман, сөт, такта – конкрет, уй, философия – абстракт исемнәр) Исемнәр килеш, тартым, сан белән төрләнә, иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ала.***

***Исемнәрнең күплек саны –лар, -ләр кушымчалары ярдәмендә ясала: кырлар, бакчалар, мәктәпләр. Борын авазларга беткән исемнәргә күплектә -нар, -нәр кушымчасы ялгана: урамнар, таңнар, төннәр.***

***Татар телендә 6 килеш бар:***

| *Килешләр* | *Сораулары* | *Кушымчалары* |
|---|---|---|
| ***Баш килеш*** | ***Кем? Нәрсә?*** | _ |
| ***Иялек килеше*** | ***Кемнең? Нәрсәнең?*** | ***-ның, -нең*** |
| ***Юнәлеш килеше*** | ***Кемгә? Нәрсәгә? Кая?*** | ***-га, -гә, -ка, -кә*** |
| ***Төшем килеше*** | ***Кемне? Нәрсәне?*** | ***-ны, -не*** |
| ***Чыгыш килеше*** | ***Кемнән? Нәрсәдән? Кайдан?*** | ***-дан, -дән, -тан, -тән, -нан, -нән*** |
| ***Урын-вакыт килеше*** | ***Кемдә? Нәрсәдә? Кайда?*** | ***-да, -дә, -та, тә*** |

***Татар телендә, рус теленнән аермалы буларак, исемнәр тартым белән (притяжательность) белән төрләнә.***

| *Затлар* | *Мисаллар* | *Берлек сан кушымчалары* | *Күплек сан Кушымчалары* |
|---|---|---|---|
| ***I зат*** | ***әнием, өем, дәфтәрем*** | ***-ым, -ем, -м*** | ***-быз, -без, -ыбыз, -ебез*** |
| ***II зат*** | ***әниең, өең, дәфтәрең*** | ***-ың, -ең, -ң*** | ***-гыз,-гез, -ыгыз, -егез*** |
| ***III зат*** | ***әнисе, өе, дәфтәре*** | ***-ы, -е, -сы, -се*** | ***-(лар)ы, -(ләр)е*** |

***Тартымлы исемнәр килеш белән дә төрләнә:***
***Б.к. әнием, өең, дәфтәре***
***И.к. әниемнең, өеңнең, дәфтәренең***
***Ю.к. әниемә, өеңә, дәфтәренә***
***Т. к. әниемне, өеңне, дәфтәрен***
***Ч. к. әниемнән, өеңнән, дәфтәреннән***
***У.- в. к. әниемдә, өеңдә, дәфтәрендә***

**Исемгә морфологик анализ ясау үрнәге:**

1. ***Тексттан исемне табып, ялгызлыкмы, уртаклыкмы икәнен билгеләргә.***
2. ***Конкрет исемме, абстракт исемме?***
3. ***Санын күрсәтергә.***
4. ***Килешен билгеләргә.***
5. ***Тартым белән төрләнгәнме? Төрләнсә, зат-санын күрсәтергә.***
6. ***Ясалышын һәм төзелешен ачыкларга.***
7. ***Нинди җөмлә кисәге булуын билгеләргә.***

***Бирем: Тубыл – Себернең җәүһәре җөмләсендә исемнәрне табып, тулы морфологик анализ ясагыз.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Исем дип нинди сүз төркеменә әйтәләр?***
2. ***Исемнәргә нинди кушымчалар ялгана?***
3. ***Татар телендә ничә килеш кушымчасы бар? Алар нинди кушымчалар?***

4. *Иркәләү-кечерәйтү кушымчалары рус телендәге нинди кушымчаларга охшаган?*
5. *Предметның кайсы затка каравы татар һәм рус телләрендә ничек белдерелә?*

## СЫЙФАТ

***Сыйфат предметның билгесен белдерә, исемне ачыклап килә һәм нинди? кайсы? кайдагы? Сорауларына җавап бирә. Сыйфат белән ачыкланган исем сыйфатланмыш дип атала. Сыйфатлар төрләнмиләр, җөмләдә аергыч яки хәбәр булып киләләр. Сыйфатланмышсыз кулланылганда сыйфатлар исемләшәләр һәм исем үзенчәлекләрен алалар.***

***Сыйфатлар асыл һәм нисби сыйфатларга бүленәләр. Асыл сыйфатлар, билге күләмен үзгәртеп, дәрәҗә кушымчалары ала алалар. Предмет билгесенең төрле күләмен белдерү сыйфат дәрәҗәләре дип атала.***

1. ***Гади дәрәҗәдәге сыйфатлар предметның билге нормасын белдерәләр һәм махсус кушымчалар алмыйлар: зур, биек, матур, яшел, сары.***
2. ***Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфат ике предметның билгесен чагыштыра һәм –рак, -рәк кушымчалары ярдәмендә ясала: зуррак, биегрәк, матуррак, яшелрәк, сарырак.***
3. ***Артыклык дәрәҗәсе бер предметтагы билгенең башкалардагыдан күпкә артык икәнен белдерә. Берничә юл белән ясала:***

   ***а) көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә : ямь-яшел, түм-түгәрәк, кып-кызыл, сап-сары;***

   ***б) иң, җете, шыр, чем-, үтә, дөм һ.б. кисәкчәләр ярдәмендә: дөм сукыр, үтә килешле, иң биек, чем-кара.***

   ***в) бер үк сыйфатны кабатлау юлы белән: үткеннең үткене, матурның матуры.***

***4. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат әйбердәге билгенең гадәттәгедән бераз ким булуын белдерә. Алар: -гылт, -гелт, -кылт, -келт, -сыл, -сел, -су, -кылтым. –келтем, -ылҗым, -елҗем кушымчалары ярдәмендә ясалалар: кызгылт, яшькелт, сусыл, алсу, әчкелтем, күгелҗем.***

***Төзелешләре буенча сыйфатлар тамыр (күк, зур), ясалма (йолдызлы, кышкы), кушма (искиткеч), тезмә (шыр тиле) һәм парлы (зур-зур, энеле-сеңелле) булалар.***

### Сыйфатларны тикшерү тәртибе

1. ***Сыйфатны табып, асылмы, нисбиме икәнен билгеләргә. Соравы.***
2. ***Сыйфатланмышы бармы? Исемләшкәнме?***
3. ***Дәрәҗәсе.***
4. ***Ясалышы.***
5. ***Җөмләдәге функциясе.***

***Бирем: Кинәт аллы-гөлле нурлар хәрәкәткә килделәр. Менә кып-кызыл нур хәтфә-яшел төскә буялды. Яшел прожектор алсу нур сирпеде. (Г.Сабитов) Тексттан сыйфатларны табып, морфологик анализ ясагыз.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. ***Сыйфат нинди мәгънә белдерә?***

*2. Сыйфатлар нинди кушымчалар кабул итә?*
*3. Татар телендә, сыйфатланмыш килеш белән төрләнгәндә, сыйфат төрләнәме? Рус телендә бу ничек?*
*4. Сыйфатларның нинди дәрәҗәләре бар?*

## САН

***Предметларның санын, микъдарын, исәбен, саналу тәртибен, чамасын белдерә торган сүзләр сан дип аталалар. Сан белән ачыкланган исем саналмыш була. Предметны ачыклап килгән саннар төрләнмиләр, алар җөмләдә аергыч булалар. Математикада саннар саналмышсыз да кулланылалар. Андый саннарны абстракт саннар диләр. Саналмышсыз саннар исемләшә, исемгә хас кушымчалар алып төрләнә, төрле җөмлә кисәге була ала.***

***Мәгънәләре һәм морфологик билгеләре ягыннан саннар 5 төркемгә бүленә:***

1. ***Микъдар саннары предметларның төгәл исәбен белдерә, ничә? күпме? никадәр? сорауларына җавап бирәләр. Вакланма, өлеш саннары да микъдар саннарына керәләр: ун, унсигез, уннан бер, ярты, чирек.***
2. ***Тәртип саннары предметларның саналу яки урнашу тәртибен белдерә, -нчы, -нче кушымчалары белән ясала, ничәнче? соравына җавап бирә, исемләшә дә ала: Унынчыларны җыелышка чакырдылар.***
3. ***Бүлем саны бер төрдәге әйберләрнең тигез өлешләргә бүленүен белдерә, -ар, -әр, -шар, -шәр кушымчалары ярдәмендә ясала, ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә: бишәр, унар, берәр.***
4. ***Чама саны әйбернең санын чама белән белдерү өчен кулланыла, ничәләп? никадәр? сорауларына җавап бирә, ике төрле юл белән ясала:***

    ***а) ун-лап , сигез-ләп, кырык-лап, йөз-ләп (-лап, -ләп кушымчасы белән);***

    ***б) биш-алты, ун-унбиш (кечерәк сан белән зуррак санны парлау юлы белән).***
5. ***Җыю саны бер төрдәге предметларның бергә туплану исәбен белдерә, ничәү? соравына җавап бирә, саналмышсыз кулланыла, барлык саннардан да ясалмый: унау, бишәү, икәү.***

***Төзелеше ягыннан саннар тамыр (бер, ике), кушма (унбер, унтугыз), парлы (биш-алты), тезмә (егерме бер) булалар.***

***Саннар 3 төрле язылалар: 1) гарәп цифрлары белән: 5, 8, 10; гарәп цифрлары белән язылган саннардан соң килгән кушымчалар алардан бераз аерыбрак языла: 11 нче сыйныф. Вакыт чикләрен белдерүче саннар сызык аша языла: Г.Тукай 1886 – 1913 елларда яшәгән. 2) Рим цифралары ярдәмендә: II, XX, XXV; рим цифраларыннан соң сызыкча да, кушымча да язылмый: XXI гасыр (егерме беренче гасыр), Николай II (Николай икенче).***
***3) Парлы саннар сызыкча аша языла (биш-алты), кушма саннар кушылып языла ( унҗиде).***

### Саннарны тикшерү тәртибе

1. *Саннарны табып күрсәтергә.*

2. *Төркемчәсен әйтергә.*
3. *Кайсы сүз төркемен ачыклавын яки мөстәкыйль кулланылуын аңлатырга.*
4. *Төрләнү-төрләнмәвен әйтергә.*
5. *Төзелешен күрсәтергә.*
6. *Җөмләдәге функциясен билгеләргә.*

***Бирем: Тагын ике көннән икенче номерлы приказ әзерләнде. Саннарны табып, морфологик анализ ясагыз.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. *Нинди сүзләр сан төркеменә керә?*
2. *Санның нинди грамматик билгеләре бар?*
3. *Микъдар санының мәгънәсен, грамматик билгеләрен әйтегез.*
4. *Тәртип һәм бүлем саннары турында сөйләгез.*
5. *Нинди саннарны чама саны дип әйтәләр?*
6. *Җыю санына нинди саннар керә?*
7. *Төзелеше ягыннан нинди саннар була? Алар ничек языла?*

## АЛМАШЛЫК

***Исем, сыйфат, сан, рәвеш кебек сүз төркемнәрен алмаштырып килә ала торган сүз төркеме алмашлык дип атала. Мәгънәләре ягыннан алмашлыклар җиде төркемгә бүленәләр:***

1) *Зат алмашлыклары: мин, син, ул, без, сез, алар.*
2) *Күрсәтү алмашлыклары: бу, теге, ул, шул, әнә, менә, андый...*
3) *Сорау алмашлыклары: кем, ни, нәрсә, кайда, кайсы, ничә, нинди, ничек...*
4) *Билгеләү алмашлыклары: һәр, һәркем, һәрбер, барлык, бөтен, һәммә, үз...*
5) *Билгесезлек алмашлыклары: әллә кем, әллә ни, әллә кайда, кемдер, нидер, ничектер...*
6) *Юклык алмашлыклары: һичкем, һичкайчан, һичкайсы, беркайчан, бернинди...*
7) *Тартым алмашлыклары: минеке, синеке, аныкы, безнеке...*

***Исем алмашлыклары килешләр белән төрләнәләр.***

**Алмашлыкларны тикшерү тәртибе**

1. *Алмашлыкны табарга.*
2. *Төркемчәсен әйтергә.*
3. *Төрләнешен ачыкларга.*
4. *Җөмләдәге функциясен билгеләргә.*

***Бирем: Кайда берлек, шунда көч. Алмашлыкларга морфологик анализ ясагыз.***

***Белемегезне тикшерегез:***

1. *Алмашлык нәрсә ул?*
2. *Алмашлыкның нинди төркемчәләре бар?*

3. ***Билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыкларының ясалышын һәм язылышын аңлатыгыз.***
4. ***Кайсы алмашлыклар килеш белән төрләнә?***
5. ***Алмашлыклар нинди җөмлә кисәкләре булып киләләр?***

## ФИГЫЛЬ

***Фигыль – зат яки предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме. Ул заман, зат-сан, барлык-юклык, юнәлеш һәм дәрәҗә белән төрләнә, җөмләдә күбрәк хәбәр булып килә.***

***Барлык төре эш-хәлнең үтәлүен, юклык – үтәлмәвен белдерә: барам – бармыйм, әйт - әйтмә.***

***Фигыльләр ике төркемгә бүленә: затланышлы һәм затланышсыз фигыльләргә. Затланышлы фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр, затланышсызар төрләнмиләр.***

***Затланышлы фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше***

| | ***Хикәя фигыль*** | ***Боерык фигыль*** | ***Теләк Фигыль*** | ***Шарт Фигыль*** |
|---|---|---|---|---|
| ***Берлек I зат*** | ***барам*** | _ | ***барыйм*** | ***Барсам*** |
| ***II зат*** | ***барасың*** | ***бар*** | _ | ***Барсаң*** |
| ***III зат*** | ***бара*** | ***барсын*** | _ | ***Барса*** |
| ***Күплек I зат*** | ***барабыз*** | _ | ***барыйк*** | ***Барсак*** |
| ***II зат*** | ***барасыз*** | ***барыгыз*** | _ | ***Барсагыз*** |
| ***III зат*** | ***баралар*** | ***барсыннар*** | _ | ***Барсалар*** |

***Хикәя фигыль эш яки хәлнең хәзерге, үткән, киләчәк заманда үтәлү-үтәлмәвен хикәяләп белдерә, барлык-юклык формаларында килә, зат-сан белән төрләнә, җөмләдә хәбәр була.***

***<u>Хикәя фигыльнең заманнары</u>. Хәзерге заман хикәя фигыль -а/-ә, -ый/-и кушымчалары белән ясала (бара, килә, карый, эшли). Үткән заман: категорик (билгеле) ү. з. -ды/-де, -ты/-те кушымчалары белән (барды, килде, кайтты, китте); нәтиҗәле (билгесез) ү.з. -ган/-гән, -кан/-кән кушымчалары белән (барган, килгән, кайткан, киткән) ясала. Киләчәк заман: билгеле киләчәк заман –ачак/әчәк, -ячак/-ячәк кушымчалары (барачак, киләчәк, укыячак, эшләячәк) белән; билгесез киләчәк заман -ыр/-ер, -ар/-әр кушымчалары белән (барыр, килер, туар, эчәр) ясала.***

***Боерык фигыль эш кушуны, боеруны, үтенүне белдерә: кил – килегез, килсен – килсеннәр, килмәгез, килсәнә.***

***Теләк фигыль сөйләүченең нинди дә булса эш башкарырга теләген белдерә: яз<u>ый</u>м, бар<u>ый</u>м, кил<u>и</u>м.***

***Шарт фигыль икенче эш-хәлнең үтәлүенә шарт булган эш-хәл мәгънәсен белдерә: укыса – укымаса, кайтса – кайтмаса.***

***Затланышсыз фигыльләр***

***Сыйфат фигыль (причастие) үзендә сыйфат һәм фигыль билгеләрен берләштерә, җөмләдә исемне ачыклап аергыч булып килә: килә торган кунак, көтүче малай, укыган китап, барасы юл, эшлисе эш.***

***Хәл фигыль (деепричастие) – төп фигыльдән аңлашылган эш яки хәлгә өстәмә эшне белдерә; җөмләдә хәл булып килә: уйнап (әйтте), бара (тора), эшли-эшли (арыдым), укыгач (белә), ишетмәгәч (җавап бирмәде), әйткәнче (уйла).***

***Исем фигыльдә (имя действия) фигыль һәм исем үзенчәлекләре дә бар. Ул -у, -ү кушымчалары ярдәмендә ясала. Эш-хәлне атап әйтә һәм исем кебек сан, килеш, тартым белән төрләнә: хат язу, урманга бару, газета укымау, кайтуларына ун көн узды. Кайбер исем фигыльләр исемгә күчә алалар: көтү – ожидание (ис. фиг.), көтү – стадо (исем).***

***Инфинитив – эш яки хәлне максат яки тиеш булу мәгънәсендә белдерә, -рга / -ргә, -ырга / -ергә, -арга / -әргә, -маска / -мәскә (юклык формасы) кушымчалары белән ясала: карарга, эшләргә, барырга, килергә, йөремәскә.***

***Аерым торганда мәгънә белдермичә, җөмлә эчендә генә кулланылучы фигыльләр ярдәмче фигыльләр дип аталалар: иде, икән, ит (бар иде, юк икән, ярдәм итә).***

***Эшнең үтәүчегә мөнәсәбәтен белдерү – фигыль юнәлеше дип атала.***

| *Юнәлеш* | *Кушымчалар* | *Мәгънәсе* |
|---|---|---|
| ***Төп*** | *–* | ***Үтәүче эшне үзе башкара: Ул йомышны үтәде, юды.*** |
| ***Кайтым*** | ***-н, -ын, -ен*** | ***Эш үтәүченең үзенә кайта: юынды.*** |
| ***Төшем*** | ***-л, -ыл, -ел*** | ***Эш читтән төшә: йомыш үтәлде, юылды.*** |
| ***Уртаклык*** | ***-ш, -ыш, -еш*** | ***Үтәүче эшне бергәләп эшли: сөйләшә, юыша.*** |
| ***Йөкләтү*** | ***-дыр, -дер, -тыр, -тер, -т*** | ***Үтәүче эшне кемнәндер эшләтә, кегәдер йөкли: Йөкне ташытты, керне юдыртты, эшләттерде.*** |

**Фигыльләрне тикшерү тәртибе**

1. ***Тексттан фигыльне табарга.***
2. ***Затланышлымы, затланышсызмы икәнен билгеләргә.***
3. ***Төркемчәсен әйтергә.***
4. ***Барлыктамы, юклыктамы икәнен билгеләргә.***
5. ***Затланышлы булса, зат-санын күрсәтергә.***
6. ***Заманын (булса) билгеләргә.***
7. ***Юнәлешен әйтергә.***
8. ***Җөмләдәге функциясен билгеләргә.***

***Бирем: Иртә торгач та үрдәк тамагын туйдырган да юлга чыккан. Фигыльләрне табып морфологик анализ ясагыз.***

## РӘВЕШ

***Эш яки хәлнең яки билгенең билгесен белдерә торган сүз төркеме рәвеш була. Ул төрләнми, ничек? кая? кайда? кайдан? кайчан? күпме? никадәр? ник? кебек сорауларга җавап бирә. Җөмләдә рәвеш, күбесенчә, фигыльне ачыклый һәм хәл булып килә: тиз эшләү, эчтән уку, соң килү. Рәвеш рәвешне һәм сыйфатны да ачыклый ала. Аларны дәрәҗә рәвешләре дип йөртәләр: шактый зур, гаҗәеп матур, ифрат авыр, бик тиз йөгерү. Мәгънәләре ягыннан рәвешләр 6 төркемчәгә бүленә:***

1. ***Саф рәвешләр: әкрен, кинәт, озак, яланаяк, бушлай.***
2. ***Күләм-чама рәвешләре: бераз, гаять, күп, әз.***
3. ***Охшату-чагыштыру рәвешләре: мамыктай, татарча, минемчә, картларча.***
4. ***Вакыт рәвешләре: кичә, бүген, башта, иртән, тиздән.***
5. ***Урын рәвешләре: ары, бире, түбәндә, якын.***
6. ***Сәбәп-максат рзвешләре: юри, әрәмгә, юкка, шунлыктан.***

**Рәвешкә морфологик анализ ясау тәртибе:**

***1. Рәвешне табып, ачыклаган сүзе белән күрсәтергә.***
***2. Нинди сүз төркемен ачыклаган?***
***3. Төркемчәсен күрсәтергә.***
***4. Төзелеш-ясалышы.***
***5. Җөмләдәге функциясе.***

***Бирем: Каяндыр ташлар арасыннан бәреп чыккан чишмәдән терекөмештәй саф, боздай салкын суны учың белән алып чөмерә-чөмерә эчү үзе ни тора! (Аяз Гыйлаҗев) Рәвешләрне табып, морфологик анализ ясагыз.***

## *АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ*

***Аваз ияртемнәре – төрле тавыш һәм авазларга охшатып ясала торган сүзләр: кеше яки хайван тавышлары, алар чыгарган авазлар, төрле предметлардан чыккан тавышлар һ.б. Мәсәлән: һау-һау, хи-хи, гыр-гыр, кикрикүк, шыгыр-шыгыр. Сөйләмдә тавышка охшатып түгел, ә образны чагылдыру өчен кулланылган образ ияртемнәре дә була: гөлт, җем-җем, кылт. Аваз ияртемнәре күбрәк фигыль белән кулланылалар. Алар фигыльгә турыдан-туры яки кил фигыле һәм ит ярдәмче фигыле ярдәмендә ияләр: гөлт итеп ут күтәрелә, шыгыр-шыгыр килә. Аваз ияртемнәре үзләре генә дә кулланылырга мөмкин:***

***Җил манараның аена утырып***
***Сызгыра: - Ф-у-у-у-у-у-у... (Һ.Такташ)***

***Аваз һәм образ ияртемнәреннән мөстәкыйль мәгънәле сүзләр дә ясала алалар. Аларның күпчелеге фигыльләргә туры килә: шыгыр-шыгыр – шыгырдау, ялт-йолт – ялтырау, кыштырдау, шау-шу.***

## *ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛӘР*

***Хәбәрлек сүзләр җөмләгә кирәклек, тиешлек, мөмкинлек, кире кагу, каршы килү, хуплау, хупламау һ.б. мәгънәләр бирәләр, җөмләдә хәбәр булып киләләр. Хәбәрлек сүзләргә тиеш, кирәк, мөмкин, ярый, ярар, әйе, шулай шул, шул-шул,бар, юк сүзләре керәләр. Кичке шәфәкънең дә үз матурлыгы <u>бар</u> ич! (Ә.Еники)***

## *БӘЙЛӘГЕЧ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ*

### *ТЕРКӘГЕЧ*

***Теркәгеч – җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләләрнең өлешләрен үзара бәйләү өчен кулланыла торган ярдәмлек сүз төркеме. Нинди мөнәсәбәт белдерүенә карап, теркәгечләр тезүче һәм ияртүче теркәгечләргә аерылалар. Тезүче теркәгечләр тигез хокуклы сүз һәм җөмләләрне бәйлиләр һәм үзләре өч төркемгә бүленәләр:***

1. ***Җыючы теркәгечләр: һәм, вә, тагын, янә, ни...ни, да, дә, та тә.***
2. ***Бүлүче теркәгечләр: яки, я, яисә.***
3. ***Каршы куючы теркәгечләр: ләкин, ә, әмма, бәлки, тик, фәкать.***

***Ияртүче теркәгечләр белән бәйләнгән сүзләр һәм җөмләләр үзара буйсынулы бәйләнештә торалар һәм алар арасында ачыклау, сәбәп, максат, нәтиҗә, шарт, кире шарт, чагыштыру мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Бу төркемгә чөнки, ки, гүя, гүяки, гәрчә, әгәр, әгәренки, әгәр дә, ягъни теркәгечләре керәләр.***

### *БӘЙЛЕК*

***Бәйлекләрнең лексик-грамматик мәгънәләре җөмләдәге сүзләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләрен белдерә, мөстәкыйль мәгънәләре юк. Синтаксик яктан бәйлекләр сүзләрне бер-берсенә бәйлиләр. Бәйлек үзе иярткән сүз белән бергә кулланылганда гына бер җөмлә кисәге була ала: <u>Төн буе</u> <u>әти белән</u> атлар саклдым. (Г. Хәсәнов)***

***Үзеннән алда килүче сүзнең нинди килештә килүен таләп итүләренә карап бәйлекләр 3 төркемгә бүленәләр:***

1. ***Баш (һәм иялек) килешне таләп итүче бәйлекләр: белән, өчен, кебек, күк, төсле, шикелле, чаклы, хәтле, кадәр, тикле, турында, аркылы, аша, буе, буенча, буйлап, саен, сәбәпле.***
2. ***Юнәлеш килешен таләп итүче бәйлекләр: кадәр, чаклы, хәтле, күрә, каршы, таба, карганда, карамастан.***
3. ***Чыгыш килешен таләп итүче бәйлекләр: соң, башка, бүтән, бирле, тыш, элек.***

## МОДАЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ

### КИСӘКЧӘ

***Кисәкчә** - сүзләргә, җөмлә кисәкләренә, җөмләләргә төрле мәгънәви, эмоциональ-экспрессив төсмерләр өсти торган модаль сүз төркеме. Мәгънә төсмерләренә карап, кисәкчәләр түбәндәге төркемчәләргә бүленәләр:*

*1. Көчәйткеч кисәкчәләр: а) ап-, кып-, ямь-, түм-, чем- һ.б.*

*б) иң, чалт, чатнама, дөм, нәкъ, шыр.*

*2. Чикләүче: гына, генә, кына, кенә.*

*3. Сорау: -мы, -ме, -мыни, -мени.*

*4. Раслау: бит, ич, лабаса, ләбасә, ла, лә.*

*5. Үтенүне белдерүче: -чы, -че, -сана, -сәнә.*

*6. Инкарьне, юклыкны белдерүче: һич, түгел.*

*7. Билгесезлек белдерүче: әллә, -дыр, -дер, -тыр, -тер.*

## ЫМЛЫК

***Ымлыклар** – кешенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын һәм ихтыярын белдерүче сүзләр. Алар шатлану, гаҗәпләнү, соклану, курку, каушау, искә төшерү, иркәләү, кызгану, хуплау, хупламау, җирәнү, кайгы уртаклашу, үпкәләү һ.б. тойгылырны кыска формада белдерәләр: уф, ах, ай, ура, тфү, пес-пес, көш-көш, ай-һай һ.б. <u>Аһ</u>, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине? (Г.Тукай)*

## МОДАЛЬ СҮЗЛӘР

*Сөйләүче күзлегеннән чыгып, әйтеләсе хәбәрнең дөреслек дәрәҗәсен белдерә торган сүзләр модаль сүзләр дип атала. Алар төрләнмиләр һәм үзгәрмиләр. Җөмләдә алар кереш сүз вазыйфасында йөриләр: ахрысы, бугай, әлбәттә, ихтимал, мөгаен, шаять, имеш, икән, дөрес, шөбһәсез, билгеле, чыннан да, чынлап та, булса кирәк һ.б. Модаль сүзләр мөмкинлек, фараз итү, ышанычсызлык, ышаныч, тәкъдим, шикләнү кебек модаль мәгънәләрне белдерәләр. Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, <u>ахрысы</u> (Г.Тукай). Ул килгән, <u>бугай</u>. <u>Әлбәттә</u>, шулай булырга тиеш.*

## СИНТАКСИС

*Сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән синтаксис дип атала.*

*Билгеле бер мәгънәгә ия булган аваз яки авазлар тезмәсе сүз дип атала. Үзара бәйләнешкә кергән ике яки берничә мөстәкыйль сүздән торган төзелмә сүзтезмә була. Сүзтезмә бер әйберне (затны, эшне, хәлне һ.б.) башка шуңа охшаш әйберләрдән аерып, төгәлрәк итеп атый: сәгать (сүз) – стена сәгате (сүзтезмә). Сүзтезмә ике өлештән тора. Әйберне, затны, эшне һ.б. турыдан-туры атаган сүз ияртүче сүз була. Иярүче сүз ияртүче сүздән сорау куеп билгеләнә: стена сәгате (нинди сәгать?).*

*Сөйләмдә сүзләр тезүле һәм ияртүле бәйләнештә булалар.*

1. *Тезүле бәйләнештә булганда сүзләр бер-берсенә буйсынмыйлар, ягъни бер сүз яки җөмлә икенче сүз яки җөмлә белән тигез хокуклы. Тезүле бәйләнеш тезү һәм каршы кую интонациясе һәм тезүче теркәгечләр ярдәмендә белдерелә. Ал, кызыл, ак, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр, һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр. (Г.Тукай) Бу җөмләдә*

*бәйләүче чара – тезү интонациясе. Тезүле бәйләнеш үзе генә сөйләм барлыкка китерә алмый. Шуңа күрә сүзләр ияртүле бәйләнешкә керәләр.*

2. *Ияртүле бәйләнеш булганда сүзләрнең берсе икенчесенә буйсынып, аны ачыклап килә: берсе – ияртүче, икенчесе – ияртүче. Урмандагы агачлар да ямь-яшел яфрак ярды.*

*Ияртүле бәйләнешкә кергән сүзләр өч төрле мөнәсәбәттә булырга мөмкин.*

1. *Ачыклаулы мөнәсәбәт булганда, бер сүз икенче сүзне ачыклап килә: кышкы көн, унынчы яшь.*
2. *Хәбәрлекле мөнәсәбәт булганда, бер сүз икенче сүз турында хәбәр итә. Бу очракта җөмлә барлыкка килә: Әни сөйли. Көн аяз.*
3. *Аныклаулы мөнәсәбәт булганда, аныклагычлар барлыкка килә: Сагыналар аны – чабыш атын... (Зөлфәт)*

**Сүзтезмәләргә синтаксик анализ ясау**

1. *Җөмләдән сүзтезмәне аерып алырга.*
2. *Сүзтезмәнең төзелешен тикшерергә: иярүче һәм ияртүче сүзләрне күрсәтергә, аларның нинди сүз төркемнәре белән белдерелүен әйтергә, бер-берсенә нинди чаралар ярдәмендә бәйләнүләрен аңлатырга.*
3. *Иярүче сүз белән ияртүче сүз арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен ачыкларга.*

## ҖӨМЛӘ

*Тәмамланган интонация белән әйтелеп, уй-фикерне хәбәр итә торган сүз яки сүзләр тезмәсе җөмлә дип атала.*

*Гади җөмлә бер генә җөмләдән, кушма җөмлә ике яки берничә җөмләдән тора. Әйтү максаты ягыннан җөмләләрне хикәя, сорау, боерык җөмләләргә бүләләр.*

*Хикәя җөмләләр тыныч, салмак әйтелә; эш-хәл турында хәбәр итә. Гадәттә ул хәбәр белән тәмамлана: Шомырт чәчәк аткан.*

*Сорау җөмлә һәрвакыт сорау интонациясе белән әйтелә һәм сорау алмашлыклары, сорау кисәкчәсе (-мы, -ме) ярдәмендә ясала: Синең барлык уку әсбапларың да бармы?*

*Сөйләүченең берәр эшне башкарырга яки аннан тыелырга кушуны белдергән җөмлә боерык җөмлә була:*

*Әйдә чап, кучер, Казанга,*
*Атларың ку, на-на-на!*
*(Г.Тукай)*

*Көчле тойгы кушып әйтелгән җөмләләр тойгылы җөмлә дип атала. Алар шатлану, соклану, курку, шикләнү, ис китү, үкенү, теләк, ниятләү, икеләнү кебек тойгыларны белдерәләр: Эх, бергә уйныйбыз, кыш көненә туймыйбыз!*

**Җөмләнең баш кисәкләре**

***Ия – җөмләдә баш килештәге сүз белән белдерелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган бәйсез кисәк, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә. Ия ике төрле була: гади ия, тезмә ия.***

***Бер генә сүз белән бирелгән ия гади ия (Без мәктәптә укыйбыз), тезмә сүз белән бирелгәне тезмә ия (Быел мук җиләге яхшы уңган) була.***

***Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа буйсына торган баш кисәге хәбәр була. Барлык сүз төркемнәре дә хәбәр булып килә ала. Бер генә сүз белән белдерелгән хәбәр гади хәбәр була: Болында күп төрле чәчәкләр үсә. Берничә сүз белән белдерелгән хәбәрне кушма хәбәр дип йөртәләр: Җир язга чаклы йокыга талган. (Г.Тукай).***

## Җөмләнең иярчен кисәкләре

***Аергыч – исемне ачыклап килгән теләсә нинди сүз. Барлык сүз төркемнәре дә аергыч булып килә алалар (исемне ачыклап килгән очракта). Сораулары: нинди? кайсы? кайдагы? ничә? ничәнче? кемнең? нәрсәнең? Аергыч белән ачыкланган сүз аерылмыш була. Халык батыр уллар үстерә. (Ш.Галиев)***

***Эш-хәрәкәт белдерүче сүзгә (фигыльгә) ияреп килгән һәм аның үтәлүенә бәйле предметны, затны күрсәткән иярчен кисәк тәмамлык дип атала. Сораулары: кемгә? нәрсәгә? кемнән? нәрсәдән? кемне? нәрсәне? кем белән? нәрсә белән? ничәне? ничәдән? Малайлар көчле җәнлекләрне ярата.***

***Төшем килешендәге исем яки исем мәгънәсендәге сүз белән белдерелгән тәмамлык туры тәмамлык була. Гали хатны укып чыкты.***

***Башка формалар белән белдерелгән тәмамлыклар кыек тәмамлык дип аталалар.***

***Хәл җөмләдә эш яки хәлнең кайда, ничек, кайчан, нинди шартларда үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә торган иярчен кисәк. Сораулары: кайда? ничек? кайчан? ник? ни өчен? нилектән? никадәр? ничә тапкыр? нишләсә? ни булса да?***

***Мәгънәсе һәм бәйләү чаралары буенча хәлләр 8 төркемчәгә бүленәләр: урын хәле (кайда? кая? кайдан?); вакыт хәле (кайчан? кайчанга чаклы? кайчаннан бирле?); рәвеш хәле (ничек? ни рәвешле?); күләм-чама хәлләре (күпме? күпмегә? күпмедән? никадәр? ничә тапкыр? ни дәрәҗәдә?); сәбәп хәле (ник? нигә? нилектән? ни сәбәпле? ни өчен? ни (нәрсә) аркасында?); максат хәле (ни өчен? нигә? нинди максат белән?); шарт хәле (нишләсә? нинди шартта?); кире хәл (нишләсә дә? нәрсәгә карамастан?).***

***Үзләре бәйләнгән җөмлә кисәгеннән ераклашкан һәм ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган хәлләр аерымланалар. Алар башка җөмлә кисәкләреннән өтер белән аерылалар. Гадәттә вакыт, рәвеш, сәбәп, максат, шарт, кире хәлләр аерымлана.***

*Җөмлә башында килгән һәм урын-вакыт рәвешләре белән белдерелгән вакыт һәм урын хәлләре аерымланмыйлар. Бераздан йөзе аз гына алсулана төшкән ханым бүлмәдән чыкты.*

*Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган кисәк аныклагыч дип атала.*

*Мин озаттым аны сугышка,*
*Йөрәгемнең сүнмәс кояшын. (М.Җәлил)*

**Җөмләнең модаль кисәкләре**

*Эндәш сүзләр – сөйләм аңа төбәлгән сүзне белдерүче кисәк. Кеше исемнәре, табигать күренешләре, хайваннар, кошларны, төрле предметларны атаучы сүзләр дә эндәш сүзләр була алалар.*

*И сабыйлар, эшләгез сез!*
*Иң мөкатдәс нәрсә эш. (Г. Тукай)*

*Эндәш сүзләр җөмләнең төрле урыннарында киләләр һәм өтер белән аерылалар.*

Тылсымлы әкиятләр хәтердә кала торган традицион башлам белән башланып китә: “Борын-борын заманда, кара урман, калын таулар артында...” Вакыйгалар нигездә өч тапкыр кабатлана. Батырның тышкы кыяфәте, аеруча көче арттырып, төрле чамасыз гиперболалар аша сурәтләнә: “Чамасыз да гәүдәле, чамасыз да көчле булган, ди, ул җегет. Күрешим дисә, кешенең кулын имгәткән, атланыйм дисә, атның билен сындарган, көрәшләрдә моңа бытыр чыкмаган” (“Турай батыр”). Мондый әкиятләрдә күпсанлы тылсымлы хайваннар, кошлар, предметлар әкият батырына ярдәмгә килә. Аеруча ат образы еш очрый: ул канатлы акбүзат, яки җил җитмәс җирән бия дип сыйфатлана. Монардан тыш сәмруг кош, күгәрчен, тутый кошлар да геройның ярдәмчеләре була. Тылсымлы көзге, тылсымлы тарак, тылсымлы курай һ.б. шундый предметлар әкият батырына дошманнардан котылырга ярдәм итә.

**Тормыш-көнкүреш әкиятләре** күпкә аңлаешлырак, гадиерәк, чөнки алардагы вакыйгалар тормышка якынрак тора. Татар халкында киң татаралган «Бай белән ярлы», «Саран белән юмарт», «Өч кыз», «Васыят», “Зирәк карт” кебек әкиятләр ***гыйбрәтле әкиятләр*** дип йөртелә, Аларда нәсыйхәт (нравоучение), өйрәтү беренче планга чыга. Ләкин ул читләп әйтү, киная (иносказание) аша җиткерелә.

Икенче төркем әкиятләрне ***маҗаралы әкиятләр*** дип атыйлар. Мәс. “Патша һәм карак”, “Хәйләкәр Таз”, “Патша кияве солдат” әкиятләре шундыйлар. Мондый әкиятләрдә маҗаралар җир тормышы белән бәйләнгән.

Тормыш-көнкүреш әкиятләренең тагын бер төркемен ***юмористик әкиятләр*** алып тора. “Хәйләкәр патша”, “Юаш кияү”, “Алдар” дигән әкиятләр шундыйларга керә. Алар эчтәлекләре белән мәзәкләргә якын, максаты – кешенең аерым кимчелекләрен фаш итү, алардан җиңелчә генә көлү.

Сатирик әкиятләр исә ачы көлү, аеруча халыкны изеп яшәүче өстен катлау вәкилләренең саранлыгын, явызлыгын, үзен башкалардан өстен тотуын фаш итеп сөйләнгән әкиятләр байтак. “Абага чәчәге”, “Тапкыр кыз” “Кыю Шомбай” әкиятләре шундый.

Әкиятләр – сүз сәнгатенең аеруча киң таралган һәм үзенчәлекле бер төре. Аларда тормыштагы аерым хәлләргә, кешеләрнең аерым сыйфатларына мөнәсәбәт, тылсым көче белән тормышны җиңеләйтергә омтылыш, тирә-якка, хаваннанар дөньясына караш чагылыш таба. Әкиятләрдә халыкның тел байлыгы, сүз уйнату, гыйбрәтле сүз төзмәләре, мәкаль-әйтемнәр, хәтта табышмаклар да очрый.

Халык әкиятләре бүгенге көндә тәрбияви максатлардан чыгып файдаланыла. Ул баланы рухи һәм физик яктан чыныктыру максатын башкара, акыллы, зирәк, тапкыр, кешелекле, ярдәмчел булырга өйрәтә.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек/ Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2002.

2. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты (Әкиятләр). – Казан, 1967
3. Исламов Ф. Мәктәптә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнү.– Казан, 1988.-Б.14-36.
4. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1том. – Казан, 1977.
5. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 2 том. – Казан, 1978.
6. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 3 том. – Казан, 1981.
7. Яшәгән ди, булган ди: Әкиятләр. – Казан, 2000.
8. Татар халык әкиятләре / Төз.- Х.Ярми, Х. Гатина. – Казан, 1999.
9. Иртешкә сәяхәт / Төз. Мөхәммәт Садри. – Казан, 1989.
10. Көмеш сылу. Әкиятләр. – Казан, 1992.
11. Ленский Марк. Әсхәт һәм урман кызы (Себертатар легендалары мотивлары буенча). – Казан, 1996.

## Афористик (кыска) жанр

Афоризм – грек теленнән – әйтелгән сүз, әйтем дигән мәгънәне аңлата. Фольклордан аермалы буларак, аның авторы билгеле була. Афоризм – билгеле бер автор, галим, язучы, философ тарафыннан камил, төзек җөмлә белән әйтелгән, тирән фикергә, кәтелмәгән эчтәлеккә ия булган сүзләр тезмәсе. Афоризмнарны хикмәтле сүз яки канатлы сүз дип тә атыйлар. (Мәс. “Сүз чыгар галимнәрдән хикмәт белән” М.Акмулла).

Афористик (яки кыска жанр – малый жанр) жанр төренә халык иҗатының мәкаль, әйтем, табышмаклары керә.

Нәкый Исәнбәт мәкальләргә түбәндәге билгеләмә бирә: “Мәкаль – сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри мисал урынында әйтелеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәре”. Мәкаль һәм әйтемнәр халык иҗаты әсәрләре дип саналса да, нигездә аерым кеше тарафыннан оста итеп әйтелгән сүз ул, ләкин вакытлар үтеп, алар телдә камилләшә барган һәм авторын югалтып, халык гыйбарәсенә әверелгән. Мәкаль формасын алган хикмәтле сүзтөзмәләрне әкиятләр, дастаннар, халык җырлары эчендә дә очратырга мөмкин.

Мәкальләрнең яшь буынны, гомумән халыкны әхлакый тәрбияләүдә роле аеруча зур. Тематик төркемнәргә бүлгәндә дә, кешенең рухи сыйфатларына, холык-фигыленә (характер), әдәп-әхлакка караган төркемнәр аерыла. (“Батырлык кыяфәттә түгел, йөрәктә”) Болардан тыш мәкаль-әйтемнәрнең уку-белем алу, акыллы яки надан булу, хезмәт һәм ял, тырышлык һәм ялкаулык кебек тематик төркемнәре бар. (“Акылсызга әйткән сүз – агып киткән су кебек, акыллыга әйткән сүз – кулга кунган кош кебек”). Тыйнаклык, сабырлык, юмартлык кебек сыйфатларны мактап әйтелгән мәкалҗ-әйтемнәр дә халык телендә бик күп. (“Сабыр иткән – морадына ирешкән”).

Хикмәтле, тирән фикерле мәкальләр җитди фәлсәфи фикер нәтиҗәсендә туа. Бик борынгыдан килгән бу төр фольклор әсәрләрендә халыкның акылы, тормыш тәҗрибәсе тупланган, тормыштагы вакыйгаларга бәя бирү дә урын алган.

Әйтемнәр кайбер сыйфатлары белән мәкальләргә якын тора, аерым җыентыкларда бу ике әсәрне (мәкаль-әйтем дип) бергә бирү очраклары да еш

була. Мәкаль шикелле үк әйтемгә дә текстның тотрыклы булуы хас, ул да сөйләмне сәнгатьчә бизәү, аның эмоциональ көчен арттыру өчен хезмәт итә. Әйтемнәрнең формасы, күләме дә, функцияләре дә гадирәк, алар гадәттә кыска гына бер җөмләдән тора. Әйтемнәрдә мәкальләрдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә чыгару булмый. (Мәс. “Ай күрде, кояш алды”, “Ничә җәйләр, ничә кышлар”, “Кызыл кар яугач”). Әйтем – сөйләмнең билгеле бер өлеше, кыйпылчыгы гына, чөнки аерым кулланылганда аларның мәгънәсе аңлашылып та бетмәскә мөмкин. Шуңа күрә әйтемнәрне кирәк урында гына кулланырга кирәк, ул контекстан гына аңлашыла. Еш кына әйтемнәрнең күчерелмә мәгънәсен аңлау өчен, аларның чыганагын, нинди мәзәк, мәсәл, тарихи яки көнкүреш вакыйгасы нигезендә барлыкка килүен ачыкларга туры килә. Мәс. “Абага чәчәк атканда” дигән әйтемнең мәгънәсен аңлау өчен “Абага чәчәге” экиятен белү кирәк. Шуннын чыгып, бу әйтемдә беркайчан да булмас хәл, яки бик-бик сирәк була торган хәл турында сөйләнгәне аңлашыла.

Болардан тыш афористик жанрга ***канатлы сүзләр, юраулар, алкышлар*** (изге теләкләр) да керә.

## Табышмаклар

Табышмаклар халыкның абстракт фикерләве нәтиҗәсендә туган фольклор әсәре. Аның килеп чыгышын галимнән “яшерен тел” яки табу сүзләр белән аңлаталар. Табу сүзләр дип, билгеле бер шартларда исемнәрен турыдан-туры әйтергә ярамаган сүзләр аталган. Аеруча ауга чыгар алдыннан аучылар киекләрнең (үзләре ауга чыга торган җанварларның) исемен атамаска тырышканнар. Шул рәвешле алмаш (икенче) исемнәр барлыкка килгән. Мәс. Аюны – урман хуҗасы, карт яки бабай дип атау хәзер дә еш очрый. Еланны – таяк яки каеш, таш дип атау бүген дә дәвам итә.

Табышмаклар башка үзенә якын әсәрләрдән аермалы буларак, мәҗбүри рәвештә ике мөстәкыйль өлештән – табышмак текстыннан һәм җаваптан тора. Табышмаклар чәчмә формада да, ике, өч, дүрт юллы шигырь формасында да була.

Табышмаклар өч зур төркемгә бүлек карала: ***метафорик табышмаклар, сорау һәм арифметик табышмаклар.***

***Метафорик табышмаклар*** иң зур төркемне тәшкил итә. Н.Исәнбәт метафора сүзен “алмаштыру” дип атый. Мәс. “Тау аркылы ук аттым, аткан саен югалттым” – яшен ату күренеше ук ату күренеше белән алмаштырыла. Табышмакларда еш очрый торган ***аллегорияне*** галим “кинаялэп сөйләү” дип аңлата. Аллегориянең асылы – абстракт бер фикерне яисә төшенчәне чынбарлыктагы конкрет бер күренеш яки әйбер (предмет) белән алыштыру. Мәс. “Ялган” дигән төшенчә табышмакта: “Сөрмәгән җир өстендә,/ Үсмәгән иген астында,/ Тумаган куян йөгерә” дип бирелә.

Метафорик табышмакларда еш очрый торган тагын бер шигъри алым – ***чагыштыру***. Бу очракта бер күренеш яки төшенчә икенчесе белән чагыштырыла. (Мәс. “Үзе яшел чирәмдәй/, Койрыгы чиккән келәмдәй/, Чук-чуклы калфак кигән/, Безгә ерактан килгән.” – Тутый кош.)

Шулай ук табышмаклар ***метонимия*** ярдәмендә дә ясала. Бу очракта әйбер яки күренеш ниндидер эчкебәйләнеше булган икенче бер сүз белән атала. Мәс.: “Тишек тимергә каен үскән” – балта сабы.

Еш кына метафорик табышмакларда авыз иjaртемнәре дә кулланыла.

Татар фольклорында сорау табышмакларының саны бик аз. Боларның төп үзенчәлеге сораугa дөрес җавап бирү түгел, ә шул сорауның эчтәлеген дөрес аңлауда. Сорау сүзнең күп мәгънәле булуына корылган, сорауның мәгънәсен аңламаганда, аңа җавап та табып булмый. Мәс.: “Нинди савыттан эчеп булмый” – җавап: буш савыттан.

***Арифметик табышмакларга*** сәер яңгыраш, гадәти булмаган хәлләр хас. (“Бер имәндә өч ботак, ботак чаен өч алма, барлыгы ничә алма” – җавабы: имәндә агач үсми).

Табышмакларның эчтәлегендә халыкның конкүреше, тормышы, яшәү рәвеше чагылыш таба. Көндәлек тормышта кешене кызыксындырган әйберләр турында гына табышмаклар туган. Бүгенге көндә табышмаклар тәрбияви-эстетик функция башкара. Балаларны зирәклеккә, күзәтүчән булырга, обстракт фикер йөртә белергә өйрәтә.

***Өстәмә әдәбият:***


1. ***Аз сүз белән күпне әйт // Мәгариф, 1999. - № 5.***
2. ***Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты / Мәкаль-әйтемнәр. – Казан, 1967.***
3. ***Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. 3 томда. – Казан, 1 том – 1959; 2 том – 1964; 3 том - 1967.***
4. ***Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры / Җыючы Н.Исәнбәт. – Казан, 1989.***
5. ***Исламов Ф. Мәктәптә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнү.– Казан, 1988.- Б.57-67.***
6. ***Халыкның күңел җимешләре // Мәгариф, 1995. - №6.***
7. ***Татар халык иҗаты. Табышмаклар. – Казан. – 1977.***
8. ***Исламов Ф. Мәктәптә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнү.– Казан, 1988.- Б.67-76.***
9. ***Үсемлекләр турында табышмаклар // Мәгариф, 1992. - № 6. – Б.43***
10. ***Нәрсә соң ул, кем белә? // Мәгариф, 1992. - № 4.***
11. ***Алма-салма-чалма // Мәгариф, 1993. - №1. – Б.26.***
12. ***Табышмак әйтәм, тап // Мәгариф, 1999. - № 5. – Б.77.***


## Йола фольклоры

Борынгы заманда кеше тормышында төрле ышанулар, мифологик карашлар, соңрак чорда гореф-гадәтләр формалашкан. Кешедә үзенең киләчәге турында уйлау, аңа уңай йогынты ясау теләге туган.

Кешеләрнең (гаилә, ыгу, токым) тормышында иң җитди вакытларында үткәрелә торган традиөион гамәлләр йола дип атала.

Бүгенге көндә йола фольклоры халыкның милли гореф-гадәтләрен, йола-традицияләрен, бәйрәмнәрен үз өченә ала. Икенче төрле халык драмасы дип

аталган бу жанр татар фольклорының катлаулы һәм кызыклы төркеме. Фольклорның бу төркеме халыкның яшәү рәвеше, җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту нормалары белән дә тыгыз бәйләнгән. Теләсә нинди йола үткәрүнең дә нигезендә уңыш, исәнлек, мул тормыш, бәхетле киләчәк теләү ята:

Йола фольклоры үзенчәлекләре, үткәрелү максаты буенча берничә төркемгә бүленә:

- календарь йолалар;
- гаилә-көнкүреш йолалары;
- дини йолалар.

Календарь йолалар ел фасылы, ягъни халык календаре белән бәйләнгән. Аларның традицион үткәрү вакыты бар. Татар халкында ел вакытлары белән бәйрәмнәр күп. Алар нигездә яз башына – табигатьнең кышкы йокыдан уянган, яңарган вакытына; һәм көз көннәренә – уңыш өлгергән чакка, муллык вакытына туры килә. “Сабантуй”, “Карга боткасы”, “Әмәл” (“Нәүрүз”), “Боз озату” кебек йолаларның нигезендә халыкның яз җитүгә шатлануы, өмете, шуның белән бәйле рәвештә теләк теләве ята. Яңа елны каршылау белән бәйле Нәүрүз бәйрәме – 21 мартта (яз башындагы көн һәм төннең озынлыгы тигезләшкән көн) Шәрыкъ илләрендә, шул исәптән Россиянең төрки халыкларында да уздырылган. (Нәүрүз – фарсы-таҗик телләрендә *Яңа көн* мәгүнәсен белдергән). Бәйрәм вакытында Яңа елны каршалау җырлары башкарылган, теләкләр әйтелгән. 18 гасырлан башлап татарларда да Яңа елны каршы алу Юлиан календаре нигезендә декабрҗ аенда үткәрелә һәм Нардуган исеме белән аталып йөртелә башлаган. Бу көннәрдә теләкләр теләнгән, уеннар башкарылган, фал ачу (гадания) үткәрелгән.

Язгы эшләр белән бәйле бәйрәмнәрнең иң зурысы – Сабантуй. Бу бәйрәмнең бик борынга варианты төрле этаплардан торган: балаларның өйдән-өйгә кереп җыйган ярмалардан ботка пешерү; балаларның буялган йомырка җыюы; атка атланган егетләрнең йомырка җыюы һүм елга буенда яки урманда сыйлануы; төрле киемнәргә киенгән ирләрнең йомырка җыюы; Сабантуйга бүләкләр җыю; ярышлар уздыру; яшҗләрнең кичке күңел ачулары.

Икенче вариант гадиерәк: мәйдан бәйрәменә 10 көн кала ат чабышлары үткәрү; балаларның буялган йомырка җыюы; мәйдан; яшҗләрнең кичке күңел ачулары.

Бүгенге көннәрдә Сабантуй үзенең борынгы билгеләрен югалтып, күңел ачу бәйрәме төсен ала.

Өмәләр – йола фольклорының календарь йолалар һәм гаилә-көнкүреш йолалары арасында торучы жанр. Өмәләрнең төп үзенчәлеге – аның хуҗалык эшләре белән бәйле булуында. Өмәләр аерым ел вакыты белән бәйле рәвештә үткәрелә. Мәсәлән, каз өмәсе, өй күтәрү өмәсе, киндер сугу, печән җыю өмәсе һ.б.

Гаилә-көнкүреш йолалары кеше тормышында булган иң җаваплы чорлар белән бәйләнгән. Ул: туу, мөстәкыйль тормыш кору һәм кешенең үлеме белән бәйләнгән йолаларны үз эченә ала.

Болар арасында иң кызыклы һәм катлаулысы – туй йоласы. Ул үзе берничә этаптан тора: ярәшү, никах, туй, күч күчерү.

Болардан тыш гаилә-конкүреш йолаларына өй туе (яңа өй төзү белән бәйле) , аулак өй (кызларның бер өйдә җыелып ял итүе), каз өмәсе (көз көне казлар өлгерәч бергәләп казлар йөлку белән бәйле), уртак аш, исем кушу (яңа туган балага исем кушу белән бәйле йолалар), кузайтын (ерак юлдан кайткан кеше хөрмәтерә үткәрелгән аш) һ.б. керә.

Милли йолалар җәмгыять вәкилләрен тәрбияләү, күп гасырлар буенча кабул ителгән "язылмаган" кануннар ролен башкара, яшәешне билгеле бер тәртипкә салу максатын тормышка ашыра.

***Өстәмә әдәбият:***


1. ***Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан, 2001.***
2. ***Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. – Казан, 1992.***
3. ***Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан, 1995.***
4. ***Ислам йолалары. – Казан, 1992.***
5. ***Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан, 1992.***
6. ***Урманче Ф. Татар халык иҗаты. – Казан, 2002.***
7. ***Мөхәммәтҗанов Р. Ел фасылларына бәйле йолалар һәм җырлар // Казан утлары. – 1992. - № 1.***
8. ***Нәүрүз // Яңарыш, 1996. – 4 сан.***


## Легендалар һәм риваятьләр

Ерак заманнардан безнең көннәргә кадәр килеп җиткән фольклор җанрлары арасында иҗтимагый әһәмияте ягыннан беренче урынны халык эпосы алып тора. Шулардан риваятьләр һәм легендалар аеруча зур игътибарга лаек. Шулай булса да бүгенге фольклористика фәнендә бу ике җанрның конкрет билгеләмәсе юк. Ләкин галимнәр аларны кайбер билгеләре буенча аеруны тәкъдим итәләр. Танылган галимнәр В.Я. Пропп, В.П. Аникин һ.б. фольклорчылар фикеренчә риваятьнең кайбер үзенчәлекләре төгәл билгеле. Барыннан да элек риваять тарихта булган һәм халык күңелендә яхшы сакланып калган вакыйгалар, үткән заманда яшәгән тарихи шәхесләр, борынгы шәһәрләр, авыллар, таулар, елгалар, күлләр, истәлекле урыннар, аларның килеп чыгышы хакында сөйли. Тарихи вакыйгаларны яки шәхесләрне үзе күргән кеше сөйләгән очракта, бу әсәр риваять була алмый. Риваятьнең эчтәлеге аның сөйләү вакытыннан ерак торырга тиеш. Шулай ук, риваять тарихи вакыйгаларның башлану, оешу, булу вакытын, шартларын, сәбәбен күрсәтергә тиеш. Димәк, ***риваять*** – халыкта киң таралган эпик хикәя; ул тарихта булган конкрет вакыйгалар, тормыш хәлләре, фактлар, тарихи шәхесләр, шәһәр, авыл һәм башка урыннар белән бәйле мәгълуматларны һәркем ышанырдай итеп тасвирлауга нигезләнә.

Халык прозасының бу төр әсәрләре нигездә ике төркемгә: ***тарихи*** һәм ***топонимик*** риваятьләргә бүленә.

Риваятьләрдән аермалы буларак, ***легендаларда*** уйдырма шактый киң кулланыла. Бу уйдырма дини карашлар, күп очракта ислам идеологиясе һәм мифологиясе, шулай ук халыкның тормышка ашмас соөиаль-утопик хыяллары

белән бәйләнгән була. Шул үзенчәлекләренә карап, легендалар да ике төркемгә: ***дини*** һәм ***соөиаль-утопик*** ленендаларга бүлеп йөртелә.

Себер татарлары фольклорында атаклы галим Николай Федорович Катанов тарафыннан язып калдырылган һәм Тубыл дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы (Тобольский государственный историко-архитектурный музей-заповедник) архивларында саклана торган «Тубыл татарларының көчле патша Аксак Тимер турында риваятьләре” («Предания тобольских татар о грозном царе Тамерлане»), “Тубыл татарларының Мөхәммәт өммәтеннән дин таратучыларның Искергә килүе турында риваятьләре” («Предания тобольских татар о прибытии Мухамедданских проповедников в г. Искер»), “Тубыл татарларының кыргыз халкының килеп чыгышы турында риваятьләре” («Предания тобольских татар о происхождении киргизского народа»), “Тубыл татарларының Күчем һәм Ермак турында риваятьләре” («Предания тобольских татар о Кучуме и Ермаке») һ.б. риваятҗләр бар.

Бу яктан караланда Себергә ислам динен таратырга килгән шәехләр исемнәре белән бәйле риваятьләр аеруча игътибарга лаеклы. Н.Ф.Катанов язып калдырган һәм 1903 елда Казан университетының гыйльми язмаларында («Ученые записки Казанского университета»), ә 1904 елда Тубыл губерна музее елъязмасында («Ежегодник Тобольского губернского музея», 14 выпуск) бастырылган “Шәех Багаветдин эшен дәвам иттерүчеләрнең Көнбатыш Себер халкы арасында уздырган дин өчен көрәше” («О религиозных войнах учеников шейха Багауддина против инородцев Западной Сибири») мәкаләсендә 29 астана – изге каберлекләр искә алына.

Бүгенге көнгә кадәр шәехләр исемнәре, алар күмелгән җир – астаналар белән бәйле күпсанлы риваятьләр һәм легендалар саклана. Гомерен халык арасында йөреп, авыз иҗаты әсәрләрен теркәүгә багышлаган Әсхат Ниязов тарафыннан мондый әсәрләрнең төрле вариантлары язып калдырылган. Мисәлән аның тарафыннан «Писәләй-шык пелгән эшләре» («Деяния, которые мог совершить шейх Бизелей») легендасында бу шәехнең белемле, гайре көчле кеше булуы турында сөйләнә: «Писәләй-шык эшгәрә угымышлы әүлия, сигырцы булган имеш. Ул кешеләрне төрле аурулартан төсәтә алган һәм пәриләргә, шайтаннарга печән чаптырткан, иләк пелән агац мүцкәгә су ташытган, комнан арган та иштергән. Шәех үлгәц, кешеләр аны олылап күмгәннәр. Хәзерге көнтә тә Кайнаул авылыннан ерак түгел «Изге йер» дигән йир бар. Шунда кирбецтән өелгән астананы йакшылар йаткан йер тип йөртәтләр».

***Ә. Ниязов әйтүе буенча, халык бу урында изгеләр рухына дога кыла һәм көмеш акча калдыра: «Монта кеше дога кылырга киләте, киртмәләрнең алтты мөйәшендә көмеш акча калтырат».***

Халык астаналарны изге урын дип саный һәм монда яман уйлар, яман сүзләр белән килүне тыя: «…пер урыс атай-сатай йаманныкка алты мөешле киртмәне үртәпейепте. Игенце көнне үк ул урыс сергелтәк пулып аурып китепте, шуннан пер ай эцентә үлеп тә китепте. Ул ук йәйтә паллары пер-переннән суң үлеп китәтләр. Ә пер паласы ике көн тартышып йатканнан суң,

кешеләргә пылай тип әйтепте: «Песнең атапыс эшгәрә йуан йалгышлык кылты, пашгаларга та әйтең, инте ицкем алай кыйланмасын»,- тип».

Җыелган материаллар арасында астаналарны җимергән, җирләрен сөреп ташлаган кешеләр язмышы хакында сөйләнгәннәре дә бар. Бу очракта алар кичектергесез җәза алганнар: я каты авыруга дучар булганнар, я тиз арада үлеп үк киткәннәр. Мондый очракларда легендаларда астаналарның “хуҗалары” башка, тынычрак урынга күчеп китәләр дип әйтелә.

Н.Ф.Катанова тәрҗемә иткән язмаларда да бу урыннарны борчымаска, сакларга киңәш ителә: «Покорнейше просим, чтобы святые могилы оберегались неукоснительно… для того чтоб шейхи не разгневались на них и чтобы не осрамили ни их, ни потомства их!» [Катанов 1904]. Астаналарның тарихын өйрәнүче Рахимов шундый фикерне яза: «Почитание шейхов и изучение их жития, паломничество к могилам миссионеров, институт хранителей мавзолеев, поучительные истории в фольклоре сибирских татар, схожие по стилю и сюжету сказаниями странствующих шейхов, сохранившуюся даже после их смерти, вера в сновидения, как в мост между мирским и духовным, наставления – адабы являются связующим звеном суфизма и традиционного ислама сибирских татар» [Рахимов 2006: 29].

Себер татарларында шулай ук ерак тарихлардан килгән проза әсәрләре – топонимик риваятьләр һәм легендалар да саклана. Халык телендә сакланып калган күпсанлы материалларда себер-татар авылларының тарихы, килеп чыгышы турында кызыклы фикерләр тупланган. Аларның кайберләрендә тарихи-документаль расланган фикерләр, кайберләрендә тарих турында поэтик күзаллау чагылыш таба. Тубыл районының Вәчир, Лаемтамак, Нешшә, Носкы, Вагай районының Супра, Ешаер, Катангуй, Ялутор районыннан Атъял авыллары, Омск өлкәсенең Ишемтамак районы Тюрметяк, Ашеван авыллары исемнәре белән бәйле риваять һәм легендалар кызыклы.

Риваятьләрдән аермалы буларак, легендаларда уйдырма – ул художество чарасы түгел, ә аның эчтәлеге. Мәсәлән, Ә Ниязов тарафыннан язып алынган себертатар әсәре “Яшел кызлар” («Зеленые девушки») легенда дип каралса, “Өч йөз баш имәс кызлар көрәше” («О бунте трехсот непокорных девушек») риваять дип исәпләнә ала.

**Өстәмә әдәбият:**


1. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2002.
2. Гилязутдинов С.М. Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности. – Казань, 2000.


## Халык җырлары

Җырлар – халык иҗатының иң киң таралган бер төркеме. Халкыбызның күңел кичерешләрен, тормышка һәм анда булган вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдергән, аерым көй-моң белән башкарыла торган, лирик характердагы, шигъри формадагы әсәрләр җырлар дип атала. Алар турында халкыбызның талантлы шагыйре: “Халык җырлары халык күңеленең мәңге тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушан көзгеседер”,- дип яза.

Эчтәлеге, яшәү һәм кулланылу даирәсен исәпкә алып, халык җырлары тарихи, лирик, уен-бию җырларына, такмаклар, кысла җырлар төркемнәренә бүлеп карала.

***Тарихи җырлар*** күпсанлы түгел, аларны бәетләрдән аерып өйрәнү дә әле ХХ гасырның икенче яртысында гына башланды. Ләкин алар халыкның таризхын, тарихта булган шәхесләрне чагылдыру ягыннан әһәмиятле. Шундыйлардан, ерак тарихларга караган, "Болгар иленең кызлары", "Болгар ятимәләре", "Тоткын Сөембикә җыруы", "Салават", Бәхтияр Канкаев", "Көзге ачы җилләрдә" һ.б. җырлар билгеле.

***Лирик җырлар*** төркеменә тарихи вакыйгаларга һәм йолаларга бәйле булмаган җырлар керә. Тематикасы буенча алар күп төрле: туган ил, туган җир турында; хатын-кыз язмышы, сөю-мәхәббәт турында, дуслык-туганлык турында, мәҗлес җырлары, шаян эчтәлекле җырлар киң таралган.

***Лирик озын җырларда*** халыкның күңел моңы, бөтен кичерешләре аеруча киң чагылыш таба. "Кара урман", "Бөдрә тал", "Салкын чишмә", "Каз канаты", "Зәңгәр шәл" шундыйлардан. Татар халык җырларныда, гарәттә, баштагы ике юл табигатҗтәге берәр күренешне чагылдырса, соңгы ике юлда лирик геройның рухи халәте бирелә.

Уен-бию җырлары һәм такмаклар халыкның күңел ачу йолалары белән бәйле. Җыр, музыка, бию белән аралашкан уеннарның үзенә караган билгеле бер көе-җыры булган. Күп очракта мондый уеннар җыр исеме белән дә аталып йөртелгән.

В.В. Радловның «Үрнәкләр…», («Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи») хезмәтенең IY томында себер татарлары арасында тупланган 29 җыр тексты да теркәлгән. Шуларның бише җыючы тарафыннан бәет дип аталган. Бүгенге фолҗклористикада бәетләр сюҗетында вакыйгалар булуы белән характерлана. Бу үрнәкләрдә дә беркүпме вакыйгалалак чагылыш таба, мәсәлән:

«Золым бел***ә***н аердылар,
кара к***ү***зем, илла***һ***и»
«алыстан карап к***ү***рен***ә/***
баструкны***ң*** пиекл***ә***й кашлары»

Монда тупланган 10 җырны («Күчем», «Ху***җ***аш», «Атулы батыр», «Мырза дус», «С***ә***ет», «Ак Бога», «***Ә***бел Касыйм» һәм башкалар) тарихи җырлар төркеменә кертеп карала ала.

«Бурихан» дип аталган җыр В.В.Радлов тарафыннан Саускан һәм Ишем Тамак авылларында язып алынган. ХХ гасырда галимнәр бу җырның төрле вариантларын Вагай районының Юрмы, К***ә***еш, Кундан, Тубыл районының Лаймы, Лаемтамак, К***ү***кр***ә***нде авылларныда язып алына. Бу җырлар халык тарихы, этнографиясе, теле буенча да кызыклы материал булып тора.

Мин ***ү***лс***ә***м, табутымны такта куе***ң***…
Й***ө***земне кыбла сары ацык куе***ң***.

Йола җырларыннан бу җыентыкта Р***ә***гес авылыннан язып алынган «Кия***ү*** йыр» һәм «***Үлә******ң*** даш» теркәлгән. Әле йөз елдан соң оештырылган экспедиөияләрдә дә Күкрәнде авылында туй вакытында кулланыла торган

«Кияү йыр» язып алынган. «Шәмчырак» җыры туйны каршы алу вакытында кулланылган:

Шәмчыракның янганындин
Янмаганы яктырак.
Бивафа яр булганиндин
Булмаганы яхшырак.
Сән килереңне белмәдем,
Чыгып юлга тормадым.
Тотылып тора минем телем,
Хуш килепсез, димәдем.

Шул рәвешле җырларда халыкның яшәү-тормыш итү белән бәйле булган хис-кичерешләре, куңел халәте чагылыш таба.

**Өстәмә әдәбият:**


1. Татар халык җырлары. – Казан: Таткитнәшр., 1991.
2. Халкымның күңел җимешләре // Мәгариф, 1995. - №6.
3. ***Миңнуллин К. Җырның ертыгы юк... // Казан утлары, 2001.- №7. - Б.184-189.***
4. ***Татар халык җырлары. Казан, 1991.***
5. ***Исламов Ф. Мәктәптә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнү. – Казан, 1988. – 36-56***
6. ***Миңнуллин К. Җырларда лирик эндәшләр // Мәгариф.-2001.- №5.- Б.12-13.***
7. ***Тарихи һәм лирик җырлар. (Кереш мәкалә: И.Надиров). Казан, 1988.***
8. ***Йола һәм уен җырлары. (Кереш мәкалә: И.Надиров). Казан, 1980;***




## Примерные вопросы для докладов, выступлений учащихся по результатам кружковой работы по теме «Татарское устное народное творчество»

1. ***Халыкның сүз сәнгате буларак фольклор, иҗат ителү һәм яшәү характеры.***
2. ***Халык драмасы жанрының үзенчәлеге. Календарь йолалары, аларның төрләре, үткәрү максатлары, яшәү рәвеше. Гаилә-көнкүреш йолалары, аларның төрләре. Йолаларның кеше тормышындагы роле.***
3. ***Халык тормышында дини йолалар, аларның килеп чыгышы. Аларның дини тәрбия бирүдәге роле.***
4. ***Риваять һәм легендалар, жанрга характеристика. Аларда чынбарлык һәм уйдырма бәйләнеше. Җирле легенда-риваятьләр.***
5. ***Халык иҗатының киң таралган жанры буларак әкиятләр. Аларның аллегорик характеры, композиөион төзелеш үзенчәлеге, тематик төркемчәләре. Әкиятләрдә халык идеалы чагылышы.***
6. ***Кече жанр әсәрләре, аларның төп үзенчәлекләре, эстетик функциясе, поэтикасы. Табышмакларның жанр үзенчәлекләре, төркемнәре. Табышмакларның бала тәрбияләүдәге роле.***
7. ***Лирик һәм лиро-эпик жанр әсәрләре. Тарихи, лирик, уен-бию җырлары, аларның жанр үзенчәлеге. Җырларда эмоциональлек, образлылык. Кыска җырлар, бию такмаклары, аларның жанр үзенчәлеге, көй белән бәйләнеше. Кыска җырларның тематик төркемнәре, поэтикасы.***
8. ***Бәетләр, аларных жанр үзенчәлеге, лиро-эпик характеры, кеше психологиясе чагылышы. Шәхси бәетләр, тарихи һәм хәрби бәетләр. Бәет һәм мөнәҗәтләрнең жанр үзенчәлеге, охшаш һәм аермалы яклары. Аларда тормыш мәгънәсе турында уйланулар, халык тарихының чагылышы.***
9. ***Балалар фольклоры, аларның иҗат ителү һәм яшәү рәвеше. Уеннар: сүзле, хәрәкәтле һәм җырлы-биюле уеннарның бала тәрбияләүдәге роле.***
10. ***Татар халык иҗатын өйрәнүнең әһәмияте, аның халык телен, тарихын, дөньяга карашларын чагылдыру ягыннан кыйммәте. Халык педагогикасының нигезе буларак, фольклорның тәрбияви әһәмияте.***

## Практическая часть организации работы кружка по изучению устного народного творчества

***Проведение кружковой работы, направленной на знакомство учащихся с устным творчеством родного народа предполагает также сбор (запись) фольклорного материала, для практического ознакомления с богатством народного творчества местного татарского населения.***

***Сбор фольклорного материала предполагает три основных этапа работы: подготовку, сбор материалов, подведение итогов.***

***Подготовительная работа. Перед непосредственным сбором фольклорного материала проводится подготовительная работа. Нужно учитывать, что сбор (фиксация) услышанного материала – это серьезная***

***работа. Практическую работу можно провести как по месту жительства учащихся без непосредственного участия руководителей, а также с выездом в соседние селения под руководством учителя – руководителя кружка. Поэтому очень важна подготовительная работа. Учитель заранее сообщает учащимся о предстоящей практической работе, знакомит их с целью и задачами фольклорной практики. (По возможности учителем показывается и анализируется фольклорные альбомы, собранные и оформленные другими учащимися или же преподавателем.)***

***Преподавателем особое внимание уделяется на то, что фольклорный материал, собранный учащимися должен отражать весь жанровый состав устного народного творчества. Для этого можно разделить учащихся на несколько подгрупп, и каждому дать определенное задание по сбору материалов. Умение выделять особенности того или иного жанра, помогут учащимся провести правильную классификацию самостоятельно собранного материала. Перед выездом на фольклорную практику руководителю практики следует обратить внимание студентов на следующее: на фольклор сибирских татар чувствуется влияние культуры народов Севера, что является особенностью местного народного творчества. Такие обряды как «Кыз уйнату» - изгнание злых духов, некоторые элементы свадебного обряда, встречи весны и др. Сохранили некоторые особенности фольклора, присущие только сибирским татарам. Такие обычаи как «кузайтын» - праздник, организованный в честь приезда кого-либо с дальней дороги, легенды и предания о шейхах, сподвижниках Ислама, о местах их захоронения (Астана) также является особенностью сибирско-татарского фольклора.***

***Проведение практики. На этом этапе работы самая главная задача – в непосредственном общении с носителями устного народного поэтического богатства, углубить теоретические знания учащегося по фольклору, формировать умения и навыки собирательской работы.***

***Для успешного проведения записи фольклорного материала учащимся предлагаются вопросы, зафиксированные в данной программе. Вопросы сформулированы с учетом современного бытования устного народного творчества. Различные жанры фольклора в разных местностях сохранились в неодинаковой степени. Поэтому, определяя современное состояние фольклорной традиции, учащимся рекомендуется выяснить вопрос, активно ли в настоящее время бытует записываемое произведение или же оно сохранилось только в памяти данного собеседника. Необходимо всегда помнить, что сказители и певцы не всегда знают научную классификацию фольклора и их научное название. Поэтому вопросы должны задаватся в такой форме, чтобы собеседник их понимал, чтобы вопросы подсказывали ему детали содержания или сферу бытования фольклорного произведения.Пользуясь программой, необходимо помнить, что расположение в ней вопросов не определяет полностью порядка работы собирателя с исполнителем. В процессе работы могут возникнуть новые интересные вопросы.***

***Подведение итогов работы. Собранный фольклорный материал классифицируется по жанрам, оформляется и в виде альбома или альбома. Подведение итогов кружковой работы можно провести в виде постановки какого-либо праздника, традиции или же в виде вечера народных песен, сказок, пословиц и поговорок и др.***

## Методика собирания фольклора

***При собирании фольклора нужно знать определнные правила, соблюдение которых значительно облегчает работу собирателя, делает ее более успешной. Но значение методики собирателя фольклора не исключает личной инициативы собирателя.***

***Одно из основных правил собирателя-фольклориста – заранее узнавать о том, какие талантливые исполнители, знатоки устного народного творчества живут в деревне. При собрании фольклора существует хорошее правило: обращаться за сведениями о талантливых исполнителях к учителям, к руководителям художественной самодеятельности, к клубным работникам. Нередко они сами собирают местный фольклор, запсиывают в альбомы.***

***Чем талантливее певец или сказитель, тем охотнее он делится своим искусством с собирателями. Но невсегда талантливые исполнителди сразу же охотно соглашаются поделиться своим знанием фольклора. Причины отказов могут быть самые разнообразные, например отрицательное отношение к фольклору в семье, насмешливые взгляды детей, внуков нередко могут быть причиной молчания таланта.***

***Одним из правил работы собирателя является требование не злоупотреблять временем и физическими возможностями исполнителей. Надо стремиться по возможности не отрывать их от повседневных дел, договариваться об удобном и лучшем для них времени запаиси. Для установления хороших контактов со сказителем или певцом не следует начинать беседу с прямых вопросов о фольклоре. Нужно завоевать доверие, начиная беседу о том, что больше всего интересует данного исполнителя, учитывая женскую, мужскую психологию, психологию деревенского жителя. Разговор с исполнителем непосредственно о фольклоре можно начинать по-разному, это зависит от многих причин – и от возраста и настроения сказителя, и от умения общаться собирателя, и от того, какая фольклорная традиция сохранилась в данной местности.***

***При собрании фольклора есть одно общее правило: запись фольклора необходимо начинать с просьбы к исполнителям рассакзать или спеть их самые любимые произведения. Важную роль играет и то, как собиратель формулирует вопросы. Наукообразность задаваемых вопросов – одна из самых частых ошибок начинающих фольклористов. Вопросы должны быть заданы в такой форме, чтобы исполнитель, с одной стороны, их понял, с другой – чтобы они подсказывали ему детали содержания или сферу бытования фольклорного произведения.***

***Основным требованием фольклористики является запись всех фольклорных произведений, т.е. записывать не только редкие тексты фольклорных произведений, но и уже известные науке тексты. Вариативность данного произведения для науки имеет тоже большое значение. Следующее требование методики записи фольклорных произведений – записывать фольклор только в момент его исполнения, нарушением является фиксация фольклорных произведений по памяти. Нельзя прерывать информанта, задавать вопросы во время исполнения произведения. Все вопросы по тесту задаются после исполнения.***

***Основные требования к записи фольклора.***

***Точность – одоно из главных качеств любой записи фольклорного произведения. Никакого домысливания, редактирования фольклорного произведения собиратель не должен допускать. Запись фольклорных произведений должны сохранять некоторые диалектные черты. Олсновной признак, определяющий необходимость записи той или иной диалектной черты в тексте – её поэтическая значимость. Нужно обязательно отмечать синтаксические и лексические диалектные черты, фиксировать ударения в диалектных словах.***

## Оформление фольклорных записей

***Записи фольклорных произведений должны формляться в зависимости от их жанровой и видовой принадлежности.***

***Каждый текст сторго паспортизируется. Паспортизация предполагает наличие следующих данных:***

- ***От кого записано произведение (ФИО).***
- ***Национальность исполнителя.***
- ***Возраст исполнителя, год его рождения.***
- ***Место рождения, откуда родом родители.***
- ***Образование.***
- ***Профессия.***
- ***Место записи произведения ( название деревни, района, области)***
- ***Кем записано произведение, дата записи.***

***Научную ценность представляют собой также небольшие очерки-рассказы, в которых дается историко-этнографическая характеристика тех мест, в которых проводится практика.***

## Программа

### Тема I. Народные обряды // Йола фольклоры

1. ***Ел фасылларына бәйле нинди йола-бәйрәмнәр үткәрелгән?***
2. ***Нәүрүз бәйрәме үткәрелгәнме, икече исеме бармы (әмәл, садака, көлчән)? Кайчан, ничек үткәрелгән? Кемнәр катнашкан? Җырлар такмаклар әйтелгәнме? Әйтүчеләргә бүләк бирлгәнме?***

3. *Нардуган (яңа елны каршылау) ничек үткән, анда кемнәр катнашкан, нинди теләкләр теләнгән? Фал ачулар (гадания) булганмы? Ул ничек үткәрелгән?*
4. *Язны каршылау йоласы булганмы? Ул ничек аталган, ничек, нинди максат белән үткәрелгән? Бозлар озату булганмы, бозга учак кабызып җибәрү курчак салып җибәрү (авырулардан котылу өчен) булганмы, ул ничек башкарылган?*
5. *Сабантуй бәйрәме ничек үткәрелгән, нинди әзерлек үткәрелгән? (чакыру, бүләк җыю). Нинди Сабантуй ярышлары булган, аларда кемнәр катнашкан? Нинди бүләкләр бирелгән? Нинди аерым йолалар үткәрелгән?*
6. *Сабанга чәчү, җир сөрү, хәйваннарны беренче тапкыр көтүгә чыгару алдыннан нинди йолалар үткәрелгән?*
7. *Яз башында елга буенда, тау битендә уеннар, әйлән-бәйлән (хоровод) үткәрелгәнме, алар ничек дип аталган? Аерым әйлән-бәйлән җырлары булганмы?*
8. *Карга боткасы, яңгыр теләү, көләүләр үткәрелгәнме, ничек оештырылган? Кемнәр, ничек катнашкан? Нинди сүзләр, хәрәкәтләр башкарылган?*
9. *Каз өмәсе, уңыш бәйрәмнәре үткәрелгәнме? Ничек, кайчан үткәрелгән? Икенче төрле атамасы булганмы?*
10. *Кич утырулар, кызлар җыелып аулак өй үткәрүләр булганмы? Кайчан, ничек оештырылган?*
11. *Календарьгә (ел фасылларына) бәйле тагын нинди бәйрәмнәр үткәрелгән, ничек?*
12. *Гаилә-көнкүреш йолаларыннан нинди ләре үткәрелгән? Балага исем кушу ничек үткәрелгән, нинди мәгънәле исемнәр кушылган? Балага, әнисенә бүләк бирү, теләк теләү булганмы?*
13. *Туй йоласы ничек үткәрелгән? Кыз сорау (теләү), килешү, никах ничек, кайчан үткәрелгән? Кызны сорарга килүчеләр, кызның, егетнең дуслары (свидетельләр) ничек аталган? Туй кем ягында, ничек үткәрелгән, күч күчерү, кыз озату, килен төшерү ничек булган? Яр-яр җырлары, туй җырлары, кода-кодагый җырлары булганмы?*
14. *Рекрулар (солдатка китүчеләр) өчен аерым йола фольклоры булганмы? Нинди йолалар, җырлар башкарылган?*
15. *Өй котлау, өмәләр үткәрелгәнме, ничек? Нинди теләкләр әйтелгән, җырлар башкарылган?*
16. *Дини йолалар үткәрелгәнме? Ничек үткәрелгән, нинди максат белән? Кеше күмү белән бәйле йолалар бармы, алар ничек башкарылган?*

## Тема II. Загаворы // Ырымнар

1. *Ырымнар икенче төрле ничек аталган? Авылда ырымнар белүче кеше булганмы? Нинди ырымнар булган: халык медицинасына бәйләе, аучылар, балыкчылар куллана торган ырымнар кайчан, ничек үткәрелгән?*

2. *Календарь, гаилә-көнкүреш йолаларына бәйле үткәрелә торган ырымнар бармы? Кара, ак ырымнар булганмы, алар нәрсәне аңлаткан? Кайчан, нинди максат белән үткәрелгән?*

## Тема III. Сказки // Әкиятләр

1. *Сөйләүчеләр әкиятне ничек дип атыйлар (йомак, сөйләк һ.б.)? Әкият сөйләүче бу әкиятне кемнәрдән ишеткән? Әкият сөйләүнең үзенчәлекләре бармы?*
2. *Хайваннар турында, тылсымлы, көнкүреш әкиятләренең кайсысы күбрәк?*
3. *Бу әкиятләрне сөйләүче кемнәргә булса да сөйлиме, аның белән кызыксынучы бармы?*

## Тема IY. Легенды, предания // Легендалар, риваятьләр

1. *Какие легенды и предания бытуют в данной местности?*
2. *Авыл исеме, аның килеп чыгышы турында легенда, риваятьләр бармы, алар ниди вариантларда сөйләнә?*
3. *Авылда шәехләр, асталанар турында риваятьләр бармы?*
4. *Тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр турында риваятьләр?*

## Тема Y. Баиты, мунаджаты // Бәетләр, мөнҗәтләр

1. *Авылда бәетләр, мөнәҗәтләр белүче кеше бармы? Бу фольклор әсәре ничек һәм кайда башкарылган?*
2. *Элеккеге бәет-мөнәҗәтләрне хәтерләүчеләр яки хәзерге көндә бәет иҗат итүчеләр бармы?*
3. *Күбрәк нинди бәет чыгарылган: шәхси, тарихи, хәрби һ.б.?*
4. *Мөнәҗәтләр белүче бармы, алар бәетләрдән ни белән аерыла? Мөнәҗәтләрне кайчан, ничек башкарганнар? Бәет-мөнәҗәтләрне сөйләүчеләрнең әсәр эчтәлегенә мөнәсәбәте ничек?*

## Тема YI. Песни // Халык җырлары

1. *Халык җырлары нинди шартларда, кайчан, ничек башкарылдган?*
2. *Җырларның ниди тамалары бик популяр булган?*
3. *Уен-биюю җырлары бармы? Уеннар вакытында җырлар башкарылганмы?*
4. *Лирик озын җырлар, тарихи җырлар саклангамы?*
5. *Сугы, көрәш турында халык җырлары булганмы?*
6. *Кыска җырлар (частушки) нинди көйгә башкарылган, кыска җырлар кайчан (нинди бәйрәмнәр, уеннар, кич утыру вакытында) башкарылган? Кара-каршы кыска җырлар әйтешү булганмы?*

## Тема YII. Детский фольклор // Балалар фольклоры

1. *Кечкенә балаларга багышлап олылар нинди фольклор әсәрләре чыгаралар, башкаралар? Бишек җырлары бармы?*
2. *Балаларның үзләре башкара торган фольклор әсәрләре бармы?*
3. *Нинди йолалар үтәү вакытында, бәйрәмнәрдә балалар катнашкан?*
4. *Нинди теләкләр (яңгыр теләү), үртәвечләр (дразнилки), тизәйткечләр (скороговорки) булган?*
5. *Нинди балалар уеннары, аларга карата нинди санамышлар (считалки) бар? Сүзле, җырлы, биюле уеннар, спорт уеннары бармы?*

6. ***Хәзерге көндә балалар фольклоры сакланганмы?***

### Тема YIII. Пословицы и поговорки // Мәкаль-әйтемнәр

1. ***Бу җиргә генә, себер татарларына гына хас мәкаль-әйтемнәр бармы? Аларның икенче атамасы юкмы?***
2. ***Мәкаль-әйтемнәрне телдә еш куллана торган оста телле кеше бармы? Мәкаль-әйтемнәр нинди вакытта, нинди максат белән әйтелә?***

### Тема IX. Загадки // Табышмаклар

1. ***Табышмаклар кайчан әйтелгән?***
2. ***Ике яки берничә җаваплы табышмаклар бармы? Киресенчә бер үк җаваплы берничә табышмак бармы?***
3. ***Табышмакларның халык телендә икенче атамасы бармы? (Йомак, тапмак)***

### Список рекомендуемой литературы


1. ***Балашов Д.М. Как собирить фольклор. – М., 1971.***
2. ***Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан, 2001.***
3. ***Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. – Казан, 1992.***
4. ***Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.–Казан, 1995.***
5. ***Бикмөхәммәт Р. Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре. – Казан, 1975.***
6. ***Гилязутдинов С.М. Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности. АКД. – Казань, 2000.-32с.***
7. ***Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. – Л., 1974.***
8. ***Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда / Әдәбият мәсьәләләре. 5Т. – Казан, 1980.***
9. ***Иртеш буена сәяхәт / Төз М.Садри. – Казан, 1983.***
10. ***Исәнбәт Н. Балалар дөньясы. – Казан, 1970.***
11. ***Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. – Казан, 1986.***
12. ***Исламов Ф. Мәктәптә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү. – Казан, 1988.***
13. ***Круглов Ю.Г. Методические указания к проведению фольклорной практики на филологических факультетах педагогических институтов. – М., 1977.***
14. ***Мәхмүтов Х. Фольклорда әдәп-әхлак мәсьәләләре. – Казан. 1995.***

15. ***Надиров И. Халык һәм җыр. – Казан, 1961.***
16. ***Насыйри К. Татар халкының ышанулары һәм йолалары. – Казан, 1975.***
17. ***Осталык тамырлары – халыкта // Казан утлары, 1991. - №3. - Б.153-156.***
18. ***Савушкина Н.И. О собирании фольклора. – М., 1974.***
19. ***Тукай Г. Халык әдәбияты. Әсәрләр. 3 том. – Казан, 1977.***
20. ***Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан, 1992.***
21. ***Урманчиев Ф. Халык авазы. – Казан, 1992.***
22. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2002.
23. ***Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан, 1967.***
24. ***Яхин А., Мәһдиев М. Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан, 1982.***


# СБОРНИК ПРОГРАММ И МЕТОДИЧЕСКИХ ПОСОБИЙ ДЛЯ ШКОЛ ТЮМЕНСКОГО РЕГИОНА С ЭТНОКУЛЬТУРНЫМ КОМПОНЕНТОМ ОБРАЗОВАНИЯ


*Садыков Клим Султанович*
*Сайфулина Флера Сагитовна*
*Хасанова Миляуша Сахретдиновна*



Сборник предназначен для учителей родного (татарского) языка и литературы средних общеобразовательных и основных школ Тюменского региона с этнокультурным компонентом образования / составители К.С.Садыков, Ф.С.Сайфулина, М.С. Хасанова. – Тобольск: Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева, 2009.

Лицензия на издательскую деятельность
ЛР №040287 от 25 июля 1997 года

Отпечатано с оригинал-макета. Подписано в печать
Формат 60х84 1/16 Усл.печ.л. 12.5 Тираж 500 экз. Заказ №

Печать, брошюровка и переплет минитипографии
Тобольского государственного педагогического института им. Д.И.Менделеева
6261150, г. Тобольск, ул. Знаменского, 58